**Әнәс Хәсәнов**

# Минем сандугачларым

***Поэма, шигырьләр, хикәяләр***

*Казан*
*Татарстан китап нәшрияты*
*2005*

УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2 Рос=Тат)6
Х 91

**Хәсәнов Әнәс**

Минем сандугачларым: Поэма, шигырьләр, хикәяләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. — 143 б.

Әнәс Хәсәновның бу китабында соңгы елларда иҗат иткән шигырьләре, поэмасы һәм хикәяләре урын алды. Әдип үзенең туган ягы, аның эчкерсез күңелле кешеләре турында яратып, сагыну хисләре белән яза.

ISBN 5-298-04146-9
© Татарстан китап нәшрияты, 2005
© Әнәс Хәсәнов, 2005

# I

# Минем сандугачларым

*(Поэма)*

## Чалгы моңы

Мортаза карт чалгы чүки,
Тезләнгән дә чирәмгә,
Бер елмая, бер көрсенә —
Уе китә тирәнгә.

Хәтеренә килә бугай
Печән чапкан чаклары,
Ул яшьтән үк менә шулай
Бик күп чалгы таптады.

Яшьли күңел алга чаба,
Яңалыкка куана.
Олыларның күңелләре
Хәтер белән юана.

Чал Идел сулары сыман,
Гомерләр аккан-киткән.
Хәтер төеннәрен барлап
Чишәргә вакыт җиткән.

Кайда калган шау-гөр килеп
Печәнгә төшкән көннәр.
Ай нурында оялып кына
Вәгъдә бирешкән төннәр.

Печән уңган — билдән, куе
(Хәзерге печән түгел).
Чалгы чүкергә тотынса,
Уйнаклап ала күңел.

Көне буе чалгы селтәп,
Билләр каткан бер кичне
Зәмзәмия шиккә салды —
Без соң, җаным, беришме?

Сезнең әнә бер көтү мал,
Йортыгыз да бик таза.
Безнең инде искерә шул,
Мин бик куркам, Мортаза —

Атаң-анаң ул тиң түгел,
Догабыз юк, димәсме?
Чәчәк ата дип торганда
Гөлгә кырау тимәсме?

— Әйтче өзеп, Зәмзәмия,
Син мине… сөясеңме?
Шулай булгач, урынсызга
Көйрисең, көясеңме?

Син бит минем сөенечем,
Сипкелең дә сөйкемле.
Синнән башка яши алмам,
Гел үләрмен шикелле.

Минекеләр риза булыр…
Синекеләр булмаса,
Тәвәккәллим, урлыйм сине.
— Урла, урла, Мортаза.

— Алайса кил, куанычым,
Битеңнән бер пәп итим?
— Өлгерерсең, юләрләнмә…
— Пәп итми ни хәл итим.

…Мортаза карт чалгы кайрый,
Таныш эш ялыктырмый.
Тирләсә дә, кәләпүшен
Башыннан салып тормый.

Тезелешеп казлар кебек,
Печән чапкан вакытлар,
Кая китте тегәрҗептәй
Ятып калган пакуслар?

Кайда калды болындагы
Хатын-кыз тавышлары?
Сөеп туймаган яшьлекнең
Кавышу-табышлары.

Күңелгә ник сагыш керә,
Чалгы моңыннан микән?
…Балалар да таралышты…
Ә карчык кая киткән?

— Тамак кипте, карале, дим,
Зәмзәмия, сиңа әйтәм,
Самавырыңны яңарт, дим,
Чәй, чәй эчик, мин әйтәм.

Юк, юк, тукта, Зәмзәмбану,
Утыр әле, карчыгым.
Мин кайрыйм, ә син тыңлап тор
Безнең чор — чалгы моңын.

Әнә бит, әнә болыннар,
Пар бөрки елга суы,
Әнә бит безнең туебыз,
Әнә улыбыз туе.

Менә бит, менә генә бит
Каенлык, җиләкләре.
Оныгыбыз җилкәсендә
Алмалы чиләкләре.

Әнә бит урман, имәнлек,
Без яраткан юкәләр…
…Һәй, гомерләр, һәй, бу еллар
Сиздерми дә үтәләр.

Әнә безнең куышыбыз —
Печән түгел, усак йорт.
Трудкөнгә алган икмәк:
«Әз бирделәр, карап тот».

— Зәмзәмбану, йә, йә инде,
Сөрт инде күзләреңне.
Мәңге-мәңге онытасым юк
Хушлашу сүзләреңне:

— Мортаза, дим, куанычым,
Җиңеп кайт син дошманны.
Ходай кушса, сау булырсың,
Тик үтә мин кушканны.

Безне уйла, илне уйла,
Авырлыклар килгәндә,
Дигән идең елый-елый,
Хушлашып кул биргәндә.

— Исеңдә тот, без гел сине
Бик сагынып көтәрбез.
Сугыш бетәр, чөкердәшеп
Озын гомер итәрбез.

Рәхмәт, карчык, рәнҗешмичә
Уздык гомер юлларын.
Байлык та бар — җырдагыча —
Җыйдык хезмәт елларын.

…Мортаза карт чалгы кайрый,
Чалгысы чыңлап тора.
Чалгыдан иңә үзгә моң,
Карчыгы тыңлап тора.

Син дә, укучым, Ходайдан
Бәхетле гомер сора.

# Сандугачлар кич утыра

Яшьли күңел алга чаба,
Яңалыкка куана,
Олыларның күңелләре
Хәтер белән юана,

Дигән идек без алдарак,
Исбатларга кирәкме?
Картлык көндә хәтер белән
Юанучы сирәкме?

—Зәмзәмбану, — ди Мортаза, —
Әйттермә кабат-кабат,
Башлар җиңеләеп китәр,
Бар, дим, чәеңне яңарт.

— Бәй, үзең лә, сагышланып,
Хәтер йомгагын сүттең.
Сиңа ияреп, мин дә янә
Гомер сукмагын үттем.

—Юл, диген, юл… Бик олы юл
Булды ул безнең гомер.
Рәхәте дә, михнәте дә —
Әз булмады…

— Ә Себер!

— Демо...билиз… Аты корысын,
Әйталмыйм урыс сүзен.
Яраланып кайту белән,
Җиктем калхуз үгезен.

Ни булгандыр ул мескенгә,
Әле дә аңлый алмыйм…
Тәгәрәде дә үлде шул…
Мин киттем, елап калдың.

Судта, ай-һай, каты торды
Пал-на-мученный Әлим.
Аны җөпләп, өреп йөрде
Хәчтерүш актив Сәлим.

Син, ди, контр, дәүләт милкен
Әрәм-шәрәм итәсең!
Ничава, ди, төзәтерләр,
Өтермәгә китәсең.

Куян Салихы кушылды:
Атасы кулак иде!
Калхузны астан җимерә!
Кулаклар шулай инде!

— Мине алырга йөрде бит
Егет чакта… хәтерлә,
Булмагач, мин сиңа чыккач,
Оятын сатты хәмергә.

— Кыйналып, арып, таушалып,
Тешсез кайттым Себердән,
Кочак җәеп каршыладың,
Син бит, карчык, бер дигән.

Эһе-һе-һе! Сиңа инде
Ничә тулды?
— Унсигез!
— Маладис, синең карахтыр
Кызларныкына тигез.

Булмаса, утыр яныма,
Чукынмас самавырың!
Бер яшьлектә, бер картлыкта,
Кая әле ыштан бавың?

—Иһи-һи-һи, мәхәббәтсез,
Кеше ишетсен тагын,
Карале моны… валлаһи…
Менә чәй, кипкән кавын.

— Йә инде, йә, шаярдым ла,

Беләсең ич, ышанма.
Аннары бит… утыз еллап
Бау такмыйлар ыштанга.

— Ә син аны каян белдең?
—Белдем инде… берәүдән,
Кем әйтте әле… Фәридәме,
Әллә шунда Гөләндәм?..

—Алайса, әнә чәеңне
Үзең кайнат бүгеннән.
Бик азынсаң, төштең-киттең
Караватның түреннән.

— Димәк, Щукарь карт әйтмешли,
Миңа отлуп бирәсең?
Алай булса, миңа кала
Коры сәке тирәсе?

Ялгыз ятсам, эшләр харап,
Мин куркам ич пәридән.
— Әй, шул телең… Бар алып кайт,
Иптәш булыр Фәридән.

—Тел дисең син, зәм-зәм суы,
Шөкер, ул бар. Булмаса,
Йә карга күтәреп китә,
Йә күңелне моң баса.

Шаяра белсәң, шаяру —
Күңелләргә таяныч.
Алла кушса, шаярышып,
Ахирәткә таярбыз.

— Әстәгъфирулла тәүбә!
Ахирәткә? Шаярып?
Амин дигән минутына
Туры килсә… йа Раббым!

Ярлыка күр бу бәндәңне,
Картлач саташа бугай…
Иман белән, дога белән
Күчәргә язсын Ходай.

Көфер сүзне иңеңдәге
Фәрештәң язып бара.
Ахирәттә шаяртырлар,
Бар әнә, ятып кара!

— Булды, бетте. Сүз шундый ул,
Күпертсәң, бик күперә,
Бассаң, басыла, беләмен,
Кайнарлыгы сүрелә.

Ярар, карчык… Балаларның
Хаты ник килми икән?
— Сәһлиядән килгән иде,
Исән-сау, эшлим, дигән.

— Онытканмын… Кече улы

Укырга керде микән?
Теге ташбаш, Рафигы, дим,
Аерылып йөрми микән?

— Кай арада туалар да
Кай арада үсәләр…
Сагынуга түзалсаң түз,
Түзмәсәң инде… әгәр…

Табадагы май сызган күк
Сызарга гына кала.
Шөгыль кирәк, шөгыль генә
Борчуны читкә кага.

Карале, син, Зәмзәмбану,
Чәйне куерак яса.
— Ярап торыр ла, атасы,
Аннары йокың кача.

— Ичмаса, Хәллә дә керми,
Нишләп ята бу Хәллә?
Кич утырырга керсеннәр,
Әйтеп чыгасың мәллә?

— Авырыксынып тора иде
Кичәдән үк, дим ләса.
— Менә шул-шул, шөгыль бетсә,
Авыру килә баса.

— Нишләп ул шөгыльсез булсын,
Шөгыле — итек кату.
Синең эш ул — караватта
Гасабиланып яту.

—Юкны лыгыр… Менә тагын
Юкны сөйлисең, хатын!
Бөтен дәртне сүндерәсең,
Каян килеп тик ятыйм.

Кичә энә су ташыдым,
Бүген карын көрәдем.
Менә хәзер терлекләргә
Печән салып керәмен.

Балаларга берәр сарык
Илтеп кайтасы булыр,
Сиңа мамык шәл алырмын,
Андый шәл тунга торыр.

— Юк әле, юк, үзеңә, дим,
Кәчтүм-чалбар бик кирәк.
Шәлем бар бит, ярап торыр…
— Синдәй хатын бик сирәк,

Куян Салихынамы соң
Синең кочакта яту.
— Ярар, искә алма шуны,
Эчеңә чыгар кату.

Гыйзелбанат нишли икән
Берьялгызы, и Хода?
Тигезлектән аермасын,
Ходайдан шуны сора.

Тиливизорда күптән жук
Карт-корыга чуртым да,
Сайлау җитсә, җөгерәләр
Санап адәм чутында.

Кабызыйм ла радионы —
Кичке концерт вакыты.
Тыңлыйк әле Әлфияне…
Кемдер ишек шакыймы?

— Иhи-hи-hи, менә рәхмәт,
Әйдә, узыгыз, күрше.
Кереп алырга тораек,
Бик hәйбәт булды, күрче.

Әйдә, әйдә, уз, Хәллә дус,
Хуш киләсез, чәй өсте.
Нурзирәгең көлеп тора —
Нур өстенә нур өсти.

Нурзирәк, әйдә, уз, дим ич,
Мактап йөрисез икән.
— Кәефләрегез ничек соң?
— Ходайга шөкер, исән.

— Чәй өлгерде, коймак кайнар,
Бу ни? Нәрсә күтәрдең?
— Печтек кенә бал иде бу…
— Зәмзәмбану, күрәмсең,

Болар тагын күчтәнәчле,
Сез бигрәк, прәме…
— Күрше хакы — Тәңре хакы,
Күрше — тормыш терәге.

Җүкә балы ул, Мортаза,
Салкын тисә, бик шифа.
Йөткергәләп йөрисең, дип,
Кызым әйтте, Минзифа.

— Салкын тисә, фронтта, дим,
Дәвасы шул — мәй иде.
— Онытыйк ла шул каhәрне,
Хәзер баллы чәй инде.

— Һай, хуш исле, hай, бик тәмле
Чәегез…
— Сәйлүн чәе!
— Менә каймак, кабыгыз, кап…
— Тәмле чәй — картлар мәе.

* * *

…И тигезлек, и тынычлык —
Картлыкның зур рәхәте.
Киң күңелле, рухи затлар
(Яусын Хода рәхмәте)

Кышкы кичтә, якты өйдә
Тыныч кына гәп кора.
Әңгәмәгә җылы өстәп,
Самавыр җырлап тора.

— Син, Хәллә дус, сөйләгән юк,
Маңгаеңдагы җөйләр
Шул Курскидан калдымы?..
Ул хәтәр булган, диләр.

— Әй, Мортаза, ул мәхшәрне
Искалу да куркыныч…
Нимесне тукмап туктат та
Впируд — безнең бурыч.

Дөнья яна… Чыдар хәл юк,
Тимер яңгыры коя.
Исемә килеп төшкәндә,
Йөрәк тасырдап куя.

Анда изелгән кешеме!
Янган-көйгән кешеме!
Танкы белән кеше изү
Шул соң кеше эшеме?!

Танкысына ут капканнар
Куырыла тимердә.
Үлалмый яткан бәндәләр
Кайнар тимер кимерә.

Ышык эзләп, шуыштым бер
Ватык танкы астына,
Аякларым чәрдәкләнгән,
Исән калсын баш кына.

Кыйпылчыклар, чебенмени,
Басты бөтен дөньяны.
Аңлый алмыйм, кайда кояш,
Кайда төньяк, көньягы.

Менә шунда маңгаема
Күсәк белән ордылар.
Очып киттем караңгыга,
Колагымда — быргылар.

Айныганда, ятам икән
Госпитальдә өч атна.
Маңгайдагы җәрәхәттән
Һаман әле кан сарка.

Бераз гына түбәнгәрәк
Эләккән булса мәгәр,
Осколкы, дим, беткән иде
Дөньяда минем сәфәр.

Ярый, рәхмәт, татар кызы
Анда кылды тәрбия.
Ходай язса, сугышта да
Табыла бит әүлия.

Сары сандугач баласы —
Исеме дә Сәрия.
Гомере булса, исән калса,
Ул гомерлек яр ие.

И карады, анам сыман,
Бастырды бит аякка.
Йөрәк тибешен тыңлап та,

Адымымны санап та.

Озын сүзнең кыскасы шул,
Җылап калды киткәндә,
Икенче кат очраштык без,
Рейхстагка җиткәндә.

Күкрәгенә пуля тиеп
Үтәли тишкән ие.
Иреннәре күм-күк булган,
Шатырдап кипкән ие.

— Хәллә абый, үләм, — диде, —
Язмыш бар ул, язмыш бар.
Ятып калам чит-ят җирдә...
Менә шундый язмышлар…

Исән-имин кала алсаң,
Син Сарманга бар әле.
Зәңгәр тауларына басып,
Сөеп аваз сал әле.

Менеп бас та Сарманымның
Иң биек бер тавына,
Минем өчен, Хәллә абый,
Сәлам бир Ватаныма.

Сәламеңне алган кызый
(Кызганыч, ул мин түгел)
Сиңа хәләл җефет булыр,
Шулай ди минем күңел…

Кызның саргайган йөзендә
Күләгәләр куышты...
Көч-хәл белән сүзе чыкты,
Бүлә-бүлә сулышын:

— Зинһар, җырла... Сарман җырын...
Әнием күз алдында...
Җаным биргән... минутларым...
Ташлап китмә... кал монда...

Моңлы чыкты минем җырым,
Сагынган булгангамы...
Белмим, язгы инеш сыман,
Күңелем тулгангамы...

Аның рәхмәтле карашы
Күз алдында әле дә.
Кулым кысып талпынды да
Китеп барды мәңгегә.

Сугышта ул адым саен
Үлем сагалап тора.
Әмма мондые җаныңны
Гомергә талап тора.

Урыны җәннәттә булсын...
Зәмзәмбану, Нурзирәк,
Еламагыз, аңа күптән
Яшь түгел, дога кирәк.

…Менә шулай алман җире

Йотып калды гүзәлне.
Үзем генә беләм ул чак
Үрсәләнеп түзгәнне.

Аннан соң да шактый әле
Мылтык җилкәм кимерде,
Кырык җиденең кышында
Калхуз камыт кигерде.

Иске шинель, гимначтурка —
Өстәге бөтен кием.
Ятып җыла — калхуз бирми
Хезмәткә сукыр тиен.

— Тукта, тукта, Хәлләкәем,
Безгә килгәндә синең
Кәчтүмең бик зәһәр иде,
Бик-бик кәлтәфи идең.

— Һе!
Сәриянең васыятен
Үтәргә дип баруга…
— Мине күргәч, телсез калдың,
Йөгердем шул даруга.

— Булды инде… Булды ул хәл, —
Яраларым хикмәте…
Бик тиз аякка бастырды
Синең кулың сихәте.

Кәчтүм, дисең… Күршенеке
Иде лә ул, Нурзирәк.
Сине алып кайтуыма,
Кертеп бирдем тизрәк.

Ул заманнар хәзер инде
Көндез күргән төш кебек…
Әй, әбиең каршы торды!
— Соң үзең торгач җебеп!

— Өлешемә тигән көмеш
Сарманда булган икән,
Менә шуннан алып кайттым
Чибәр кыз — менә дигән.

Без Сарманда тумасак та,
Сөйдек Сарман кызларын.
Дары базында дары бар,
Сөярбез әле тагын.

—Хи-хи-хи! Зәмзәмбану,
Кара бу дөя кошын,
Зурдан кубып сөйләшә бит…
—Яратмыйм чышын-пышын!

Беләсең бит, мин тәвәккәл,
Уйламый алдын-артын,
Бик булашсаң минем белән,
Яшь хатын алдым-кайттым.

— Син? Тәвәккәл? И Ярабби,
Кияү җегете килгән.
Яшь хатын белән нишләрсең,

Сыйпап җыларсың микән?

— Мортаза дус, кара моңа,
Карале бу хатынга,
Теле нинди! Минем тормыш
Себерсез дә каторга.

— Әй, Хәллә, син шаярып та
Искә алма Себерне.
Колыманың зәмһәрире
Күпме тормыш җимерде.

Күпме җаннар бер гөнаһсыз
Шул Себердә кыелды…
Мине өмет саклап калды,
Җан өметкә сыенды.

Ышанычым-таянычым
Җиңде шайтан таягын,
Зәмзәмбану, балаларым
Булды минем маягым.

* * *
— Минем күптән, Хәллә күрше,
Башта бер уй әйләнә:
Сакал җибәргә дим дә,
Зәмзәмбану бәйләнә.

— Сөбханалла! Бик күркәм эш,
Сакал бит ул — ир күрке.
— Син хуплагач, булды гына,
Вәт маладис син, күрше.

Түгәрәк кенә бер сакал
Күптән кирәк, минемчә.
—Туктагыз әле сез, картлар,
Уйламагыз җиңелчә.

Иске авыздан яңа сүз,
Мыек кына җитмәгән,
Тагын бер кат киңәшик, дим,
Ахирәткә китмәгән.

Кытыклыйдыр бит ул сакал,
Биткә тисә, диюем.
— Стенага борылып ятсаң,
Тимәс лә ул тиюен.

— Ие, сакал тимәсен дип,
Борылган ди берише!
Стенага карап ятсам,
Тынны кыса мүк исе!

— Сиңа сакал бер кирәкми,
Сиңа сакал нәстәгә?
Ак сакалын Гурьян йөртсен,
Ошар өчен Настәгә.

— Картларга аксакал, диләр,
Сакал — акыл билгесе.
— Акыл булса! Ә булмаса,
Ул чак кеше көлкесе.

Телевизор кабыздыңмы,

Сакаллар акыл сата.
Тормыш корырга өйрәтә,
Тыңласаң, башың ката.

Ә тормыш соң, тормыш үзе
Кайсы якка үзгәрә!
Шәһәр-авылы зар җылый,
Моңа ничек түзәргә?

— Туктале, карчык, туктале,
Тирәнгә кереп китмә.
Моңа сакал гаепleme?
Син аны хөкем итмә.

Чал сакал — гомер бизәге,
Тәҗрибә көзгесе.
Күпне күргән йөзгә өсти
Җылы килгән күз төсе.

— Сакаллы сабый булырсың,
Җибәрмәгәең тагын.
Бүген мин каршы торалмыйм,
Бүген бит көйле чагым.

— Менә, Хәллә дус, күрдеңме?
Нинди бит минем хатын!
Минем сүздән бер дә чыкмый,
Минем хатын — саф алтын.

* * *

— Мортаза дус, әйтим әле,
Картлар бик гаҗәпләнә:
Җомгага да килми, диләр,
Бар бит гыйбадәтханә.

Үзең мәчет, мәчет, диеп,
Күпме чаптың артыннан.
Төзеп бетергәч, нигәдер
Кермисең дә...
— Тартынам!

Әйе, мин дә җөрер идем,
Муллабыз мулла булса.
Хәчтерүш Сәлим малае,
Сәлим малае! Мулла!
Кичә йөрде вожак булып,
Партиядә сөйрәлеп.
Хәзер әнә ясин чыга,
Ярты-порты өйрәнеп.

Колһуалланы бутагач,
Соң шул мулла эшеме?
Гомер буе аералмады
Әче белән төчене.

Намазга утыруыма,
Уйларым китә читкә,
Хамелеон мулла булгач,

Аяк тартмый мәчеткә.

Әйе, мәчет — изге урын,
Шулай икән — кылайма.
Ике йөзле тәкъвалардан
Гөнаһ арта болай да.

Өйдә генә укысам да,
Ходайга барып җитәр.
Ходайга бит иман кирәк,
Иман, мәчеттән битәр.

## Сандугачлар мунча керә

Инде менә килеп җиткәч
Сүзебез бу урынга,
Сөйлик әле сезгә, дуслар,
Аз-маз мунча турында.

Сүзегездә яңалык юк,
Мунча, имеш, димәгез.
Мунча кергәч, чистарынып,
Яшәренеп китәбез.

— Шәһәр йортында ванна бар,
Ниемә безгә мунча? —
Диярсез сез. — Син мунчаны
Юкка мактама, куйса.

— Бәхәсләшүдән ни файда
Мунчага йөрмәсәгез,
Мунча рәхәтен ваннадан
Аера белмәсәгез.

— Шәһәрдә дә мунча бар ич, —
Диярсез, — кер дә юын,
Жәлләмичә, күпме кирәк
Агыз хөкүмәт суын.

— Их, егетләр, юк инде, юк...
Авыл мунчасы — мунча.
Карт сөякне назлыйм дисәң,
Тәнеңә кер дә кунса.

Мунча җәннәт — бик шәп яккач,
Ләүкәгә менеп яткач,
Парлап каен себеркесен,
Кызган ташка су аткач,

Колак пешә, йөрәк чатный,
Тәнне ялый алсу ут.
Мондый рәхәт ваннадамы?
Һич булалмый, булмый, юк!

Сөяк йомшап, җелегеңә
Сеңеп беткәч ләззәте.
Салкын әйрән эчеп куйсаң,
Тагын дөнья җәннәте.

Хәл алырга дүрт аяклап
Чыгып яткач... Син көлмә!
Пешкән кура җиләге син,
Бавы чишелгән көлтә.

Хәлләнгәч, тагын чабынгач,
Тормышка дәрт уяна,
Син хәзер һич үзең түгел,
Син бүтән кеше, яңа.

* * *

Безнең картлар гомер тату,
Дуслар, бертуган сыман,
Берсе якса, икенчесен
Калдырмый мунчасыннан.

Бүген рәхәт Мортазага,
Иркәләнә мунчада,
Карчыгы аркасын юа,
Җырлап тора мунчала.

— Бөтен тәнеңдә, Мортаза,
Яра, җәрәхәт эзе.
— Син сыйпагач, сызлавы, дим,
Бетә үзеннән-үзе.

— Тел бистәсе... кара моны...
Тернәкләнә түгелме?
Әллә теләгең бар инде?
— Кытыклагач күңелне!

Әйдә, әйдә, тизрәк, тиз,
Җайла шунда искечә...
Менә шулай... менә шулай...
Карчык түгел син, бичә.

...Карт сөякне шәпләп парлап,
Чабынып куллар талгач,
Картлар кайтыр юлга чыга,
Канәгатьләнеп калгач.

* * *

Бер атнадан Хәллә белән
Нурзирәге — күр әнә —
Мортаза яккан мунчада
Кич буе рәхәтләнә.

— Хәтерлимсең... иң беренче
Бергә мунча керүләр...
Чишенергә ояла-ояла
Кызарынып йөрүләр.

Чибәр иең! Нинди ие
Синең, карчык, түшләрең.
Яше-карты теләләе,
Чекерәйтеп күзләрен.

Хәзер инде... Күз тидеме,
Асылынып төштеләр.

— Сиңа әле дә кирәкме
Кабарынкы түшләләр?

Менә бик шәп себеркесе —
Мәтрүшкәле, иснәп ал.
Баш җуасым бар аннары.
Эшең булса, эшләп кал.

— Эш дип... Һе... эш... булмас ла ул,
Билләр дә чатнап тора.
Яшьлек узды. Адым саен
Картлык-эт саклап тора.

Юкка гына, картлык — этлек,
Димиләрдер халыкта.
Йөрәк әрни әрнүен дә,
Монда бар бит хаклык та.

— Ярар инде. Җүри генә
Әйттем кана, шаяртып.
Түш дисең ич. Түшне дә бит
Булмый икән кабартып.

## Кем бәхетле?

Гомер шулай матур гына
Агып яткан бер көнне,
Картларыма килеп керде
Яшүсмерләр төркеме.

Замана балалары шул,
Болар таптанып тормый,
Кыекламый, боргаламый,
Туп-туры бәреп сорый:

— Сез менә күркәм кешеләр
Бәхетлеме, түгелме?
Бәхет нәрсә дигән сорау
Борчый безнең күңелне.

Бәхет нәрсә ул, дибез дә
Бәхәс кыза үзара.
Бәхет бармы, әллә юкмы,
Булса, кая югала?

Авылдамы, шәһәрдәме,
Кайсы күргән бәхетне?
Ильяс әйтә: әнә бит, ди,
Хәллә бабай бәхетле.

Күкрәгендә орден-медаль
Балкып тора кигәндә,
Бөтен авыл соклана бит,
Бәйрәмнәргә килгәндә.

— Ә Мортаза бабайның соң!
— Дан ордены ни тора?

Ул бәхетле, ышанмасаң,
Әнә үзеннән сора!

— Роза әйтә: шәһәр ул, ди,
Бөтен бәхет оясы.
Орденсыз да, медальсез дә
Бик рәхәт, ди, дөньясы.

Авыл урамы ураммы?
Ул тоташ баткак кына,
Ә шәһәрдә урамнар бит
Ялт иткән асфальт кына.

Бәхет кошы юк ул, имеш...
Безнең кайсыбыз хаклы?
Бәхәсләрдән туеп беттек,
Ә сез менә кем яклы?!

Хәллә бабай тамак кыра —
Khe! («Күрше уяу бул!»)
— Мортаза бабагыз гына
Ерып чыкса чыгар шул.

— Соравыгыз, бер карасаң,
Четерекле икән лә.
Инде килеп, бер карасаң,
Бәхет нәстә дигәндә,

Бу сорауга, и оланнар,
Җавап бирү җиңел дә,
Тормыш юлын күзалласаң,
Ай-һай, шактый читен дә.

Ходай дөньяга кешене
Иман белән тудыра —
Ул бәхетле, ә менә кем
Шуннан читкә юлыга,

Тормышыннан ямь табалмый,
Көнчелектән интексә,
Канәгатьләнә белмәсә,
Хөсетлек басып китсә,

Ул инде менә бәхетсез —
Аның җокысы кача.
Җанын тутык корт кимерә,
Языкларга юл ача.

Бәхет нигезендә тәүфыйк,
Тәртип, инсафлык тагын.
Кем вөҗдан кушканын үти,
Иң бәхетле шул, наным.

Кайда яшәвеңә карап,
Ташып тормый ак бәхет.
Ничек яшәвеңә бәйле —
Гаделме синең кәсеп?

Бәхет — күңел тынычлыгы,
Кайгысыз үткән кичләр.
Мәхәббәт — бәхет-сәгадәт,
Бәхет ул — уртак хисләр.

Бәхет — кешегә шәфкатьлек,
Күңелнең киң колачы.
Бәхет — җан теләгән хезмәт,
Бәхет исәнлек тагы.

Намус кушканча яшәсәң,
Юлың булса туп-туры,
Йөзеңдә гел уйнап торыр
Мәңгегә бәхет нуры.

Бәхет ул — татулык, дуслык
Гаиләңдә, илеңдә.
Менә шулай ул — бәхетнең
Мең йөзе бар кимендә.

Йөрәк кушканны тыңласаң,
Акыл белән эш итсәң,
Юлың һәрвакыт уң булыр,
Бәхетең узмас читтән.

Менә, Хәллә, ничек бит, әй,
Яшьләр гел башка дисәң,
Мәгънәле уй-теләкләре,
Димәк, без әле исән.

Зарланмыйк әле яшьләрдән
Урынлы-урынсызга.
Бездән теләк бер, оланнар, —
Ак җәймә юлыгызга.

Мондый уйлар борчый икән,
Өметле сез, җегетләр.
Безнең халкыбызга кирәк
Менә сезнең кебекләр.

— Хәллә абзый, ник бик күпләр
Замана авыр, диләр?
Утлы суны яраталар,
Ә менә эш сөймиләр.

— Хәмер дигәндә, оланнар,
Ул бит хәсрәт баткагы —
Үз бәхетен җуеп бата
Адәми зат ахмагы.

Мәнфәгатьсез бәндәләргә
Дөнья кысан, ямьсез, тар...
Болганчык замана ул узар,
Һәрнәрсәнең чиге бар.

Су да гел болганчык тормый,
Бер чистара, сафлана.
Дөнья ул шулай, наным,

Дулый да матурлана.

* * *

Бу ышаныч каян дисәң,
Язылмаган канун бар.
Олы йөрәкләрдә яши
Иң гадел ул кануннар.

Кеше булырга өйрәтә
Минем сандугачларым.
Әхлак күзеннән бәяли
Яшәешнең бар ягын.

Хушлашырга вакыт җитте,
Каршы торса да йөрәк.
Әлегә, әйдә, хушлашыйк,
Озын гомер, кыска картлык,
Көтмәгән сөенеч, шатлык,
Исәнлек-саулык теләп.

## Шигырьләр

# Вөжданым — корыч калкан

## (Фашист төрмәсендә әңгәмә)

Сатмас егет илен алтын-көмешләргә,
Әгәр югалтмаса вөжданын;
Алтынны ул чүпкә санар,
Иң кыйммәтле күрер Ватанын.

*Абдулла Алиш*

Төшкә кердең, Мәшкел, дулкыннарың,
Ябырылып, ярны умыра.
Ә мин шунда адашканмын икән —
Җир тетрәтеп давыл котыра.

Кинәт кенә кургаш дулкыннардан
Гыйфрит чуртан өскә сикерә.
Ә тешләре! Штык икән моның,
Ерткыч сыман үзе үкерә.

Башың бетте бит, ди, хәзер сине
Кабып йотам, һич тә жәлләмим.
Гаебең зур рейх каршысында,
Хөкем шундый сиңа! Җәллад мин!

…Төшемме соң, әллә өнемме бу?
И Мәшкелем, сиңа үпкәлим…

Күңелемә чуен герләр астың —
Сиңа хәзер үги икән мин.

Төшләремә шулай кермәсәң соң —
Беләсең лә — бәгырь яралы.
Мин ышана идем кайтырбыз дип,
Очрашырбыз, гомер бар әле.

Мәшкел, Мәшкел! Мәшкел…

— Алиш, Алиш! Туктале син, егет,
Саташасың, димме, түгелме?
Явыз дошман нәкъ шуны тели бит —
Гарипләргә тели күңелне.

Мәшкел, димсең, әллә мөшкел, димсең,
Хәл мөшкел дә, рухың төшмәсен.
Хакыйкать бар, намус җир йөзендә,
Вөҗданнарга тутык күчмәсен.

— Сагындыра, Җәлил, сагындыра…
Кино тасмасыдай, гомерләр
Күз алдыннан мәңгелеккә шуа
Вакыйгалар, дуслар, шөгыльләр.

Мием кайный, кайнар кургаш сыман,
Тынгы бирми авыр уйларым.
Кичерерме мине нечкә билем,
Гафу итәр микән улларым?

Әйтмәсләрме әсир төшкән, диеп,
Буй биргән, дип, явыз дошманга,
Безне саткан, илен саткан, диеп,
Әверелгән куркак куштанга.

Ятсам-торсам, һаман күз алдымда
Ерак калган гүзәл Мәшкелем,
Балык тотып, юа, җиләк җыеп,
Балачактан шунда мәш килдем.

Мине көтә булыр изге анам,
Чиялекләр, гүзәл болында.
Ә мин менә тоткын, әсир бүген,
Язмышым да дошман кулында.

Сагындыра Көек — туган авыл,
Актай, Идел — изге Ватан бит.
Фашист яный миңа, Ватаныңны
Күмер итәм, изәм, ватам, дип.

Язучының, дустым, бар теләге —
Гүзәллеккә сусын уяту.
Безгә менә Ходай язган икән
Үлем көтеп, әрнеп тик яту.

Язылмыйча кала әкиятләр,

Хикәяләр, шигырь, повестьлар.
Язмыш биштәремдә минем хәзер
Йөз романлык кайнар азык бар.

— Бер уйласаң, Алиш, бу дөньяга
Кемнәр килеп, кемнәр китмәгән.
Тик мәңгегә кала каһарманнар —
Илен сөйгән, тезен чүкмәгән.

Тик ятмадык! Юк, юк! Әсирләрдә
Без кабыздык хөрлек нурлары.
Халык бакый, ә без халкыбызның
Саф вөжданлы тугры уллары.

Очкын чәчрәп, ялкын дөрләп каба!
Иманга тиң изге антыбыз
Яшь буынга рухи чаткы булыр,
Мәңге азат булыр халкыбыз.

— Ант дигәндә… Җәлил, дошман белсен
Бездә сыгылмас рух, көч барын.
Изге анам, илем, Ватан өчен
Корыч калкан — минем вөжданым.

# Әдипне сагыну

Алиш абый!

Сине сагына Көек, бик сагына
Эзең калган урман-тугайлар.
Киң кырларның зәңгәр күкләреннән
Сагыну җыры суза тургайлар.

Кайт син, Алиш, әйдә, кил табынга,
Халкым юмарт, сые әнә мул.
Күңел яраларын юам дисәң,
Актай суы — үзе шәраб ул.

Кайтыр җирең синең — изге илең,
Туган җирдә туган халкың бар.
Туп-туры кер, батыр, һәрбер йортка,
Шатлык белән каршы алырлар.

Алиш абый, сиңа олы рәхмәт,
Туган җирне мин дә нык сөям.
Моңа мине син бит, син өйрәттең,
Хөрмәт белән сиңа баш иям.

Синең васыять — безнең тормыш анты,
Синең каның безнең тамырда.
Изге исемең керде йөрәкләргә,
Ул мәңгегә шунда калыр да.

# Алиш авазы

Авылымның башын күккә чөйгән

Тау башына менеп утырып,
Хыял диңгезендә йөзгән Алиш,
Хәл җыярга менгәч, су кереп.

Эзләреннән аның мин дә менәм —
Күңел тарта, дәва һавасы.
Биеклектән шунда җанга иңә
Батыр якташ Алиш авазы:

Урманнарга барасызмы икән,
Болыннарга печән чабарга?
Их!
Очып кайтып, яңа печән исен
Туйганчы бер иснәп ятарга.

Урман юлы, арба көпчәгеннән
Сибелеп калган тузан исләре…
Шул тузан да кыйммәт хәзер миңа…
Ә кояшлы аяз кичләре!

Авылдашлар, үтенечем сезгә,
Чия, чикләвеккә барышлый,
Хәтерләгез әле, хәтерләгез
Тормыш сөйгән егет — Алишны.

Урманнарга кергәч, яңгыратып,
Алиштан да сәлам бирегез.
Безнең үлем сезнең тормыш өчен,
Хөрлек өчен, шуны белегез.

## Асылым

Мин бәхетле —
горурланыр кешем бар,
Бик яратып эшли торган эшем бар.
Хыялларымның яктысы, яме бар,
Ә ашаган ризыгымның тәме бар.

## Гомер агышы

Җил дә юк, яңгыр да, кич аяз,
Ә яфрак нигәдер коела.
Әйтерсең үзәктән өзелә —
Гомернең үткәне тоела.

## Чын хакыйкать

Сабыр төбе — сары алтын, диләр дә,
Җиңелдер ул бары тик шул сөйләргә.
Тәңгәл килсә сабырлык һәм тыйнаклык,
Шундадыр ул чын хакыйкать, чын хаклык.

## Дога кирәк

Яшеллекне сагынабыз кышын,

Җәен төшкә ап-ак карлар керә.
Исәннәргә бары да якын, тансык,
Ә мәрхүмгә? Уйламыйбыз бер дә —
Дога кирәк әрвахларга, дога,
Ни өчен бу хәтерләрдән чыга?

## Истәлеккә әрнү калган

Болгарымда — Спас.
Тарих — Остаз,
Гыйбрәткәме, әллә
Михнәткәме,
Мәчет ташларыннан
Чиркәү салган.
Хәтерлегә мирас —
Мәңге әрнү калган.
...Ә бу хәлдән кемнәр
Сабак алган?

## Фани дөнья

Гамәлләр — гомергә тәрәзә,
Мәхәббәт — йөрәктәге рәшә.
Әтисез гаилә — җил капка,
Үксезне хөрмәтләп кем дәшә?

Ераклык — офыкның туганы,
Эчкече — хәмере корбаны.
Ялгызлык — тар ләхет мисалы,
Сагалый һәрдаим инсанны.

Язмышың — ач козгын, карчыга,
Чукырга атлыга каршыңа,
Ә кеше сизенми, шөгыльдә
Каядыр ашыга, ашкына.

## Яңа каза

Телебезгә тагын килде яңа каза —
Һәркем хәзер тел турында шигырь яза:
«Халкым телен мин бик сөям, бик яратам» —
Купшы сүзләр кибәк кенә, бер карасаң.
Әй, шагыйрьләр! Сөймәгез сез ана телен,
Иҗатыгыз җырлап торсын гүзәллеген,
Телебезнең илаһи зур, рухи серен.

## Менә сиңа мә!

Сәхнә тулы кендек, кендек...
Сәнгать ни хәлдә бит, ә!
Сәхнәдә хәзер җыр түгел,
Кендек тантана итә.

## Көз

Саргайган үләннәр, күшеккән,
Карына, бозына күнеккән.
Тик каен яфрагы дерелди,
Мәңгегә яшәргә сер эзли.

Ялгыз карт сукмакта хәл җыя,
Иңенә ишелгән тау-кыя.
Чуалган хәтере — ярасы:
Сагындым, кайт инде, анасы...

## Күңеленә биклә

Шәфкатьле бул, дип язылган Коръәндә,
Шуны биклә күңеленә, и бәндә.
Миһербансыз була калса күңелең,
Онытма син, кеше — кеше түгелен.

## Сары май

Чирәмдә бәбкәләр пипелди,
Урамда ямь-яшел яз исе.
Хыялым — гомерем ал таңын
Кайтарып, кочаклап йөрисе.

## Сабак

Тау башында имән
Беркөн болай дигән:
— Мин бит синең түбәң,
Ә син миннән түбән.

Тау тетрәнеп киткән —
Башын күккә чөйгән.
Менә хәзер имән
Масаяла микән?

Мәтәлгән ул аска.
Хәле мөшкел, бакса,
Үз башына җиткән —
Инде утын икән.

## Бәхет канаты

Үсемлекнең яшәү көче — тамырдан,
Кеше бәхете канаты — сабырдан;
Тамыр җәйсә сары алтын холкында,
Тыныч тормыш хөкем сөрер йортында.

## Яшьтәшләр

Сиңа, яшь дус, әле унбиш кенә,

Дүрт кат унбиш миңа күптәннән.
Ә йөрәгем ярсу синекедәй,
Мәхәббәтле язлар көткәннән.

Без — яшьтәшләр, ал таң кабызып йөрү —
Безнең бөек уртак эшебез.
Тормыш гүзәллеген таба белгән,
Шашып сөя белгән кеше без.

# Тормыш

Кичә генә бәйрәм иде,
Бик рәхәт иде чыршыга.
Биеп торды, һәй шат иде
Тирәсендәге чыр-чуга.

Бүген менә аунап ята,
Һәркем аны таптап үтә.
...Шуны күреп ятим карчык
Бертуктаусыз яшен сөртә.

# Замана

Көчленеке замана.
*Әйтем*

Яңача яшибез, ирекле,
Сыйныфлар килеште беркөнне —
Миллерга, Чубайга бар байлык,
Гобәйгә — заводлар төтене.

Бик дуслар без хәзер, ирекле,
Хуҗасы һәр кеше милекнең.
Үзмилек колачын җәйгәндә,
Зынҗыры шыкырдый ирекнең.

# Күнегәбез түгелме?

Чечня... Беслан, Урус-Мартан... Ерактан
шома гына уза болар колактан.
Ә бу җирдә күпме кан-яшь түгелде,
ерткычлыкка күнегәбез түгелме?

# Нишләдек без?

Шул ук кояш өстә,
ай да шул ук,
күк гөмбәзе шул ук — үзгәрми.
Кеше үзгә, әхлак-рухы үзгә,
нишләдек соң без, дип, кем әрни?

# Зәңгәр экран ничек түзә…

Кайчан карама,

ул сөйли,
кыяфәт шәп,
йөзе тук.
Айлар сөйли,
еллар сөйли,
адәм рәтле
сүзе юк.

## Яңа бай

Юкә агачыннан көлә
Түргә элгән чабата:
Без соң нинди туган булыйк,
Уйлый-уйлый баш ката?
Шөшледән барып сора, дип
Ярып салды юкә дә,
Синең кебекне ул ясый,
Бик мактансаң, сүтә дә.

## Шик

Кеше бик күп лә ул,
вөждан сирәк,
оятны читкә ташламыйбызмы?
Ипи ашасаң да,
вөждан кирәк —
кешенекен ашамыйбызмы?

## Пар ат

Намус белән кайнар йөрәк
Булды минем пар атым.
Бик күпләргә гашыйк булдым,
Берне генә яраттым.

## Ялгыш

Игән башны кылыч кисми, диеп,
Борынгылар ник ялгышкан икән?
Бөгелгәннәр тапталган да үлгән,
Ә горурлар тарихта гел исән.

## Яз килгәнне көтим микән...

Урамда кыш,
Күңелем буш.
Тәрәзәмнән кояш киткән,
Сагынудан дымлы керфек
Күптән инде кипми, иркәм.
Язылмаган хатларыңны
Сабыр җыеп көтим микән,
Йөрәгемне учка кысып,
Язга каршы китим микән...

## Милли идея

Милли идеянең ни икәнен
Белим дисәң, татар улының
Җырларында күреп таң каласың
Бакыйлыгын халык рухының.

Илһам җыры, Илһам моңнары бит
Милли идеябез көзгесе.
Халкыбызның рухи асылының,
Әхлагының алтын өлгесе.

## Кызык бу дөнья

Кызык бу дөнья —
шәфкатьсезләр, эшлексезләр
рәхәт чигә.
Уңганнар, булганнар,
миһербанлылар нигә
калын кесәләргә тез чүгә?

Кызык бу дөнья —
гаделләр нигә
гаделсезлектән яшь түгә?
Ач күзле яшь түрә
бүген хөкемдар үзенә күрә,
кеше язмышын хәл итә.
Дөнья менә нинди бит, ә!

## Бала чакның таяк аты

Бала чакның таяк аты
Уйнаклаган, дулаган,
Тыны бетеп туктамаган,
Күкрәк киереп сулаган.
Паровоз булып пошкырган,
Җир тетрәтеп кешнәгән,
Йөгәнләргә теләгәнгә
Йә типкән, йә тешләгән.
Ул һаман алга ыргылган,
Сөртенгән, егылмаган,
Тышауларга маташсалар,
Качкан, һич тоттырмаган.
Бала чакның таяк аты
Хуҗа иткән егетне,
Бик көчлене, гайрәтлене,
Ярсу йөрәкле, дәртлене,
Нәкъ шул үзе кебекне.
Бала чакның таяк аты
Тасырдаган, түзмәгән...
...Җайдагының чәче инде
Агарганын сизмәгән.

## Вакыт

Яшь егетләрне картайта,
Санламый солтаннарны,
Континентларны тетрәтә,
Санамый корбаннарны.

Хөкем итсә, гүзәл илләр
Айкала да таркала.
Дустан дошманга әйләнә
Башкалага башкала.

Йөзгә җыерчыклар сибә.
Диңгез кибә, елгалар,
Бормалы юлларын ташлап,
Бер аңа буйсыналар.

Хәсрәт-дәрьяга кешене
Җәлләми тотып сала.
Теләсә, йөрәк ярасын
Дәвалап, юып ала.

Бу нинди илаһи куәт,
Нинди гайрәт, ни дәрман?
...Шундый бөек көчкә ия
Вакыт дигән каһарман.

## Ул мине аңлар микән?

Үзе егылган еламас.
Мин дә түзәм. Тик йөрәк,
Йөрәк менә әрнеп тора —
Миңа ул гына кирәк.

Мәхәббәт — ләззәт ул, диләр,
Мәхәббәт бит ул — газап.
Йөрәкнең бит акылы юк,
Көтә минутлар санап.

Мин синә тиң түгел, дию
Зур хата булган икән.
Аңладым — мәхәббәт тиңли,
Ул мине аңлар микән?

## Шатланып әсир булдым

Тавышың — көмеш кыңгырау,
Күзләрең — язгы кояш.
Син — бәхетем чыганагы,
Гомерлек асыл юлдаш.

Урап алды йөрәгемне
Ефәк толым тылсымы.
Мин шатланып әсир булдым,
Сөюемә буйсынып.

# II
# Хикәяләр

## Сабыр төбе — сары сагыш

Төн уртасында күктә фәрештә очып узды.

*М. Ю. Лермонтов*

Хәят әниемнең изге рухына багышлыйм.

*Автор*

### I

Ферма кызлары, чыр-чу килеп, инешнең салкын суы белән кулларын, битләрен юдылар, көлешә-көлешә тәбәнәк кенә, ямь-яшел чирәм каплаган калкулыкка, урам якка күтәрелделәр. Күренеп тора, күңелләре күтәренке, йөзләре әнә кояштай балкый.

Ферма ферма инде, сәхнә түгел. Ә шулай да, кара син аларны, билләренең нечкәлеген әллә кайдан әйтеп торырлык итеп буып куйганнар. Аякларында ак оекбашлар, башларында кардай ак яулыклар. Их, яшьлек, яшьлек!

Сабира әби, капка төбендәге эскәмиягә утырып, бүген дә кызларны көтеп алды.

— Кызлар, кызлар, нихәлләр сез? Сөтбикәләрегез җылап калмадымы?

— Юк, юк, Сабирәттәй, сиңа сәлам, диделәр.

— Нихәл, Сабира әби?

— Бик эссе ләбаса, ник өеңә кереп ятып кына тормыйсың, ә?

— И, синең урында без булсакмы! Бирер идек ул йокы дигәннең кирәген.

— Әйе, чыбылдык эченә кереп, бер алты йөз минут!..

— Әй, җилбәзәкләр, күбәләкләр, минем урында булу авыр түгел лә ул. Хода гүмерләрегезне бирсә... Жук инде, кызлар, минем урында булмагыз әле сез. Кирәкми... Өлгерерсез. Ялгызлык бал белән чәй эчү түгел ул. Чәй дигәннән, мин бит сезне көтеп утырам. Әйдәгез, әйдә, самавыр ачуыннан пыр килеп утырадыр инде анда. Бер ташып, бер түгелә торган Кәримулла абзагыз шикелле.

Кызлар гөр килеп көлешеп алдылар. Авылда Кәримулла абзыйның бер дә юкка кызып китеп, шундук суынып өлгерүен кем генә белми.

— Рәхмәт инде, Сабира әби. — Кызлар беравыздан рәхмәт яудыра башладылар.

— Көн дә, көн дә уңайсыз бит. Борчып...

— Нинди борчу ди ул. Жук, жук. Аннары карт кешенең хәтере элеккеге лампы пыяласы инде ул. Гелән. Черт итәргә генә тора. Әйдәгез, дигәч, әйдәгез. Кабартм-а-ам шулхәтле уңды, урыгыз, әйдә, күрше Габдуллаҗан әйтмешли.

— Һи, шул ачык йөзең, Сабира әби. Сине ничек ташлап китәсең инде.

— Вәт, вәт. Әйдәгез әле, бары белән кунак итим әле үзегезне. Су чиләктә. Сабыны да шунда. Биткул жусагыз, диюем.

— Без инештә юынган идек инде. Суың бармы соң әле? Барып кайтыйкмы?

— Рәхмәт, рәхмәт. Кичә генә китердегез ич әле. Әйдә, хуш, керегез, кер.

Кызлар, Сабира әбигә ияреп, болдырга атладылар. Кырып юылган сап-сары идән такталары янында аяк киемнәрен салып эчкә үттеләр. Өй эчендә мул булып яңа пешкән кабартма исе таралган иде. Тәрәзәләрдә ап-ак челтәрле пәрдәләр. Түрдә пөхтә итеп җыелган урын-җир. Ә гөлләр? Хуҗа карчыкка рәхмәт укып шау чәчәктә утыралар.

— Шунысы әйбәт синдә, Сабирәттәй, чебен юк.

— Чебен минем дошман ул, кызлар. Бердәнбер дошманым. Тәрәзәләрне томалап, ишеккә кусаң, чыгып качалар. Калганнарына менә шапалак.

Кызлар өстәл тирәсенә тезелеп утыруга, өстенә тастымал япкан таба пәйда булды. Сабан туенда чабыштан кайткан ат сыман пошкырып, пар бөркеп утырган самавыр да үз урынын алды. Тастымалны алып куйгач:

— Җә, җитешегез, житеш. Мин чәйне яңартып алыйм әле, — дип, Сабира әби газ плитәсенә ут кабызды.

— Ник, бусы гына ярамас идемени? — Кызларның берсе аңа ярдәмгә ашыкты.

— Һәй, җанкисәкләрем, чәйне аны вшвежий килеш эчәргә кирәк. Югыйсә ул чәй түгел инде.

Әбинең «вшвежий»ны басым ясап әйтүенә кызлар дәррәү көлешеп алдылар.

— Җәгез, җитешегез, дим, менә кәҗә мае. Кабартмасы да майда гына йөзеп пеште. Кияү көткән бикәч кебек бит урталарын кызартып көтеп торалар.

— Ну, Сабира әби, сине телевизордан гына сөйләтеп торасые. Шагыйрә бит син, — диде кызларның берсе.

— Һи, анда кем сөйли дип беләсең, кызым. Күбесе «шәһәр» дип тә әйтә белми. Теге хәбәрләр укучыларның берсе «тәэсир» диясен «тәйсир» дип кенә җиббәрә. Менә тагын әллә кая киттем. Җә, ашагыз.

— Әче таңнан торып фермага йөгергәндә, бик ашыйсы килми шул. Аннары гына эчтә бүреләр улый башлый.

— Менә шул-шул. Җә, җә.

Кызлар тәмләп асты-өсте килгән, гөҗдердәп торган кабартмаларны ап-ак тешләре белән өзеп-өзеп капканда, Сабира әби аларга карап, елмаеп, рәхәтләнеп утыра. Кызларны менә шулай чакырып кертеп, хәзинәдә бары белән сыйлап чыгару аның өчен бик рәхәт шул. Яшьләрнең бер-берсенә төрткеле сүзләр әйтешеп, елмаеп-көлеп утыруларыннан ул зур ләззәт таба. Андый чакта аның күз алдына үзенең дә үкчәсеннән очкын чыгарып йөргән вакытлары, улы, килене килеп баса да, карчыкның йөзе кинәт искән җил сүндереп киткән учак ялкыны сыман сүрелеп тә өлгерә. Әй, язмыш.

Кызлар, бик тәмләп, Сабира әбине мактый-мактый, бал йә шикәр комы белән чәй эчәләр. Ә карчык алар арасында сүзгә саранланыбрак утырган, сирәк-мирәк кенә карашын тәрәзәгә ташлап, сиздермәскә тырышып көрсенгәләп куйган Хәбирәнең йөрәге кайнавын чамалый. Әтисез үскән бу чибәр кыз, әле күптән түгел генә күрше авылның ябалак шулпасы ярата торган бер егетенә кияүгә чыгып, бик тиз әйләнеп тә кайткан иде. Сабира әби, ябык казан ябык калсын, дип, моның сәбәбен сорарга уңайсызлана, ләкин яшь йөрәкнең ничек сызуын үзенең бик күпне кичергән, вакыт-вакыт кистереп, әрнеп аптыраткан йөрәге белән аңлый. Андый чакта аңа район табиблары дару кабарга киңәш итсәләр дә, Сабира әби яхшы белә: аның йөрәген авыр уй әрнетә бит, ә андый уйны баса торган дару тапмаганнар ич әле. Теләсә кайчан килә дә кисә, килә дә чәнчи бит ул йөрәкне. Сорап тормый. Даруыңны каптың ни дә, капмадың ни.

— Хәбирә кызым, синең ачуың килмәсен, кысылып утыра дип уйлама әле. Юнмаган таяк өчен җаның көймәсен. Бер сүзем бар сиңа. Син ашаудан калма әле. Аша әле, аша.

— Ашыйм ич инде, Сабира әби, ашыйм. Һи, синең ризык авызда эреп китә бит ул.

— Бисмилла әйтеп пешергәнгә ул, кызым. Ә син аша. Ашамыйсың ич, чемченәсең генә. Ходай Тәгалә безгә бөтен мидәт-куәтне ризык белән бирә. Аша син. Инде уй-хәсрәт баса башласа, кулың бармаса да, берәр эшкә тотын җә җырла. Кеше белән аралаш, кош-корт белән булса да сөйләш. Үтә ул, наным, үтә авыр көннәр. Наным, бу дөнья кешегә бер битен үптерә, бер артын үптерә. Көймә син, көлеп туймаслык, йөзеңнән кояш көнләшерлек матур көннәрең булыр әле. Шөкер, ятим-ялпы түгелсең.

Кызлар, гөр килеп, Сабира әби сүзләрен җөпләп утыралар. Бер шаяны, Гөлгенә исемлесе сикереп торып:

Бирегез әле гармун —
Телләре алтын булсын,
Кыз кадерен белмәгән
Егет бетсен, чукынсын, —

дип, Хәбирәне кытыкларга керешә. Кызлар ду киләләр.

— Чү, чү, Гөлгенә, табын янында алай килешми ул, — дип, Сабира әби аларны тыярга теләсә дә, Хәбирәнең кәефе үзгәрүенә шатлана.

— Син, Сабирәттәй, безгә әллә кайчан үз тормышыңны сөйләргә вәгъдә бирдең. Үзең һаман сөйләмисең, — ди йөзенә инде алсулык йөгергән Хәбирә.

— Соң... бит, наным, сезнең эшегез гел ашыгыч лабаса. Әле менә чәйгә керергә дә теләмәгән иегез. Беләм ич мин, өйләрегездә муеннан шөгыль көтә.

— Әй, Сабира әби, һаман эш тә эш дип... Ферма да өй, өй дә ферма. Качмас әле ул дөнья мәшәкатьләре. Шулай бит, кызлар. Әйдә, сөйләле, Сабира әби. — Кызлар, чынаякларны юып, сөртеп, тыңларга хәзерләнәләр.

Сабира әби белә: аларның һәркайсын өйләрендә кырыкка ярылырлык мәшәкать көтә. Авыл авыл шул ул. Монда көн күргән кеше аяк-кулы талса да, кәефе китеп, сузылып ятып хәл алырга бик теләсә дә, үз-үзен көчләп булса да бирешмәскә, күтәрелергә, торырга кирәклеген, буыннарына изрәргә ирек куярга ярамаганлыгын бала чактан ук белеп үсә.

— Җук, җук, кызлар, бүтән чакта инде, — ди карчык. — Кайтып эшегезне карагыз, җал итегез. Менә җәйге эш-кош бетәр, кышның озын төннәре җитәр. Шунда бер рәхәтләнеп кич утырырбыз. Бүгенгә кайтып торыгыз, күңелем булды инде. Әле тагын бер шатлыгым бар. Таңгөл оныгымнан хат алдым. Бәлки, кайтып килермен, дигән.

— Ашыйк та качыйк була түгелме соң инде бу, Сабирәттәй?

— Булмый, булмый. Сәриянең әнкәсе дә сырхаулап тора икән. Тик, мотри, эштән кайтышлый керми узмагыз. Әйтүем шушы. Без менә мыраубикә белән сезгә гел шат, иеме... Ә сөйләвен сөйләрмен, Алла боерса.

**II**

...Сөйләр әле ул башыннан үткәннәрне, сөйләр. Җаны өтелеп, өзгәләнеп, үткән гомер юлын яшьләргә гыйбрәт итеп сөйләр...

Ул сөеп, яратып кияүгә чыкты.

Сәлихҗан да аны өзелеп яратты. Әлегедәй хәтерендә — никах укылып, туй мәҗлесеннән соң аларның икәвен генә калдырып, әти-әниләре, туган-тумачалары таралып беткәч, алар Сәлихҗан белән алгы якка чыктылар да тып-тын калдылар. Сабира мичкә барып сөялде, Сәлихҗан урындык кырыена чүмәште. Алар, үпкәләшкән кешеләр сыман, бер-берсенә карарга уңайсызланып, шулай шактый сүзсез тордылар. Сабира, күтәрелеп карарга оялып, күлмәк җиңен бөтәрләде; Сәлихҗан, беренче күргәндәй, кулларына, тырнакларына текәлде.

Киеренкелекнең озакка китүен чамалап, кияү башын күтәргәч, аларның карашлары очрашты. Икесе дә көлеп җибәрделәр, күңелләре җиңеләеп китте. Сәлихҗан, очып килеп, Сабираны күтәреп алды, битләреннән, күзләреннән үбә-үбә, аны караватка, ап-ак җәймәләр, мендәрләр өстенә китереп салды...

Ире белән тәүге йокы урынын Сабира үзе хәзерләде. Оялмады, «ястык кызлары» эшен ул үзе эшләде. Ап-ак җәймәләрне үтүкләде, мамык мендәрләрне кабартты, тышларын үтүкләп киертте. Чигелгән кашагалар, сөлгеләр эленгән, пөхтә итеп җыештырылган өйдә, ап-ак чыбылдык эчендәге биек агач карават патша кызлары ятагыдай күпереп, бизәнеп, беркем аңлата алмаслык тәмле-ләззәтле, ялкынлы-канатлы, шикәрле-баллы, сихри мәхәббәт, сөю хисе белән өретелгән ике бәхетле җан-тәннең берегеп эрүен көтеп калды. Менә ул гомергә бер генә килә торган бөек, хәләл мизгел җитте.

Бу чәчәкле, хуш исле яз, май ахыры, бөтен тереклек гөж килеп торган, тугайдагы таллар арасында сандугачлар мәхәббәтләреннән шашынган май, 1941 елның гүзәл май төне иде.

Ә озакламый дөньяга коточкыч афәт килде, адәм аждаһасы кешеләр өстенә ыжгырып ябырылды, яшьләрнең баллы-ширбәтле көннәре дип тормады. Инде әллә кайда, еракта, бик еракта адашып калган ул көннәрне хәтеренә китерергә тырышса да, хәзер Сабирәттәй күз алдына һаман да бер генә манзара килеп баса. Әнә аның Сәлихҗаны җигүле арбага утырган да яшьле күзләрен яшь хатынына төбәгән... Әнә ул, күздән югалганчы кул изи-изи, калкулык астына төшеп югала. Сабирәттәй җанашы белән тулыр-тулмас бер ай гомеренең матур, күңелле мизгелләрен дә искә алырга тырыша. Тик алар биектә, зәңгәр күктәге каурый болытлар сыман беленер-беленмәс, сизелер-сизелмәс кенә каядыр шуалар да шуалар. Күз алдына тагын шул кузгалырга теләмәгәндәй таптанып торган ат, артка карап утырган иренең кул изи-изи китеп югалу күренеше пәйда була...

Аннары Сабирәттәй Сәлихҗан белән сөйләшә башлый:

— Сәлихҗан, Сәлихҗаным, күз нурым. Киттең дә югалдың. Фронттан, Мәскәү астыннан бер-ике генә хат салдың да суга төшкән сыман юк булдың. Изге сөякләрең кайда гына тилмереп ята икән? Син бит Сабираңның кайнар назын татып кына өлгердең. Син бит икебез бәгыреннән өзелеп төшкән улыбызның дөньяга килүен дә, тупырдап тәпи йөреп китүен, ай үсәсен көн үсеп, ни арада кул астына килеп керүен дә, минем таянычым булып китүен дә белмисең.

...Көтте, кышкы озын төннәрдә, җәйге озын көннәрдә, салкын яңгырлы көзләрдә көтте Сабира Сәлихҗанын. Язгы таңнарда елап, сагынып көтте бит ул сине. Син төшеп югалган калкулык өсләренә менеп, күзләре талганчы карап та, капка төбегездәге такта урындыкка утырып, язгы салкынча кичләрдә дә, яңгырлы өшеткеч көзге кичләрдә дә, эштә дә, ялда да, төштә дә, өндә дә туктаусыз көтте. Кайтыр, бер кайтыр, дип, күңеле белән ышанып көтте.

Кайчан кайтыр икән соң ул, аның кара-кучкыл чәчле, кара кашлы, яшел күзле, киң маңгайлы, елмайса, тирә-якка кояштай нур сипкән йөзле Сәлихҗаны. Яз кайтса, Сабира аны җиңел йон күлмәге өстеннән ап-ак алъяпкыч бәйләп, башына ак яулыгын арттан бәйләп каршы алыр иде.

Аның иренә генә хас тәмле әчкелтем тир исен тирән итеп, туйганчы иснәп, кочагына сеңеп, озак итеп басып торыр иде. Елар идеме икән? Юк, ярамый, еламас иде, янында улы булгач, аңа күз яше күрсәтү килешмәс иде. Сабыр гына карап, улын кулына күтәреп, әтисенә бирер иде дә, ике ирнең кочаклашып сөешүенә шатланып, бәхетле елмаеп, басып көтеп торыр иде. Аннары, Сәлихҗанының бер кулын үзе, икенче кулын улы тоткан килеш, алар авыл урамы буйлап өйләренә кайтырлар иде. Аннары...

Юк шул, кайтмый аның Сәлихҗаны, кайтмый.

Кыш кайтса, ире калкулыкка күтәрелүгә, аның сандык төбеннән әллә кайчан бәйләп куйган оекбашларын алып, каршына йөгерер иде дә, салкын битеннән үбеп, бәсләнгән мыегын чип-чиста кульяулыгы белән сөртер иде. Озак хәбәрсез югалып йөргәнгә, күңелендә мең кат борнап, мең дә бер кат эреп юкка

чыккан үпкәсен сиздермәс иде. Сиздерсә дә, аннары гына, Сәлихҗанның тимердәй нык, каты күкрәгенә башын салгач, иренең хәтерен саклап кына:

— Шулай бик сагындырып кына кайтырга булдыңмыни? — дияр иде. Аннары...

Юк шул, отыры кайтмый Сәлихҗан. Җәйге эссе көндә кайтса, кулына тәмле катыктан сап-салкын чишмә суына гына ясаган, Сәлихҗан ярата торган әйрәнне банкага салып, каршына йөгерер иде. Аның сусынын басканчы йотлыга-йотлыга әйрән эчүен карап торгач, Сәлихҗанның исен китереп:

— Карале, улың да монда чаба. Чистый егет булды бит инде. Печән чаба, бәрәңге утырта, утын кисә. Инде үзенә кызлар да күз сала башладылар. Син генә озак йөрдең. Инде көтә-көтә тәкатем калмады лабаса, Сәлихҗан. Әти-әни картайды. Сине көтә-көтә елап, әнинең күзләре тонды бит, — дияр иде. Аннары... аннары ул сап-салкын су белән Сәлихҗанның бит-кулын юдырыр иде, тиз-тиз чәй өлгертер иде. Аннары кайнар итеп мунча ягар иде. Аннары инде...

Юк шул, һаман кайтмый Сәлихҗаны. Шулай кайтмас булды микәнни инде. Аның бит үлем хәбәре килмәде. Димәк, исән.

Көз кайтса, алдан хәбәр дә бирсә, ул, Каратун станцасына алдан ук барып, поезд килгәнне көтеп алыр иде. Юк, юк, улы Рушан авыргалап торган олы яшьтәге әнисен ялгыз гына юлга чыгарып җибәрәме соң! Алар икәүләп Сәлихҗанны көтеп алырлар иде дә күрше Фәсах машинасына утыртып алып кайтырлар иде. Ә юлда сөйләшеп туйгач, Сәлихҗанын моннан соң бер генә сәгатькә дә аерылышмаска ант иттерер иде. Әй, оныта язган ич әле ул. Әтисе белән Рушанны таныштырганда әйтәсе сүзләрен дә уйлап куйган иде ич ул.

— Менә, Сәлихҗан, бу җегеткә карале син. Бу бит синең улың, минем күз нурым, — дияр иде. — Ул булмаса, мин сине сагынудан саргайган булыр идем. Әле дә җарый ул булды, — дияр иде. Аннары... аннары Сәлихҗанының агарган чәчләрен сыйпар иде, маңгаендагы, битендәге җыерчыкларын сыпырып үбәр иде.

Әгәр инде Сәлихҗан:

— Әй, Сабира, синең чәчләрең, кашларың агарган икән ич, — дисә, аптырамас иде.

— Чәчне аны хәзер буяп та җөриләр, җанкисәгем. Тик менә исәпсез-сансыз йокысыз төннәр, йөрәкне кыршаулаган кайгылы-хәсрәтле көннәр тулы узган гомерне, бер күрергә зар булып үткән гомерне ничек кире кайтарасың, — дияр иде.

Юк шул, кайтмый Сәлихҗан. Кайчан да бер кайтса, Сабирәттәй, күзлеген кат-кат сөртеп, бәрәңге басуының түренә үк чыгып каршылар, ике куллап күрешер иде.

— Кайттыңмы, җаным. Бик-бик көттек бит без сине. Көтә-көтә җелегебез корыды бит инде. Әтиәни гүр ияләре булдылар. Мин дә инде менә карчык булдым. Юк, син уйлама, мин сине әүвәлгечә үк җаратам. Исәнлегең-саулыгың ничек, авырмыйсыңмы? Син мине алай ук кысма әле. Билләрем, аякларым, буыннарым сызлап тора шул, — дияр иде. — Сез ирләр булмагач, бөтен авырлык безгә төште шул, җаным. Ватылдык, ватылдык. Ил йомышы белән күп йөгердек, күп.

— Йөрәкме? Чәнчешә шул, чәнчешә. Ничек чәнчешмәсен соң ул! Барына да түзгән, нәүмиз йөрәк бит, җаным. Инде улың да күптәннән кайтканы юк. Әфган дигән гыйфрит чыкты лабаса. Шунда инде ул, әфисәр бит ул, — дияр иде. — Ярар, бу хакта аннары сөйләшербез, җә, җә үзең сөйлә инде. Кайларда югалып йөрдең, ничек болай кайтасы иттең, мин бит картаеп бетеп барам ич инде, — дияр иде. Аннары инде, Сәлихҗанының күңеле кителмәсен дип, улларының, бер карасаң, күз явын алырлык егет булып үсеп җиткәнен, менә дигән чибәр, акыллы кызга өйләнеп җибәргәнен сөйләр иде. Үзләренең зөфаф төнендә Сәлихҗанның:

— Хур кызлары да мондый итеп урын җәя алмас. Мин синең уңганлыгыңны беләм. Ну бу хәтле үк дип башыма да килми иде, матурым, — дигән сүзләрен истә тотып, яшьләргә урын-җирне үзе җәйгәнен сөйләр иде. Сәлихҗанның мактау сүзләре аның колак төбендә гомере буе яңгырап торды лабаса.

Әйе, яшьләр дуслары белән зык кубып инеш буена төшеп киткәч, Сабирәттәй болай да пөхтә, матур итеп җыелган урын-җирне таратып ташлады. Дога укый-укый карават матрасын сыйпады, комодтан өр-яңа җәймәләр алып җәйде, каз мамыгыннан гына ясалган мендәрләрне кабат-кабат кабартты, иснәписнәп карады, чыбылдыкны алыштырды. Аннары, читкәрәк китеп, караватка карап торды да, елмаеп, эшеннән канәгать калып, бүлмәдән чыгып китте. Ана бүген әйтеп бетермәслек шат иде. Улы өйләнә бит, аның улы!

Ата күргә — ук юнар, ди халык. Ә аның улына ата тәрбиясе насыйп булмады шул, нишләтәсең. Рушан аның үз канаты астында үсте, сүз тыңлаучан бала булды. Тәмәке, хәмер дигән нәрсәләрне авызына якын да китермәде. Баш ярып, күз чыгарып йөрүчеләрне әйләнеп узды, колагына чөй тыкканнарны яратмады, аралашмады. Кешелекле, уңган, елмаеп кына торган егет булып җитеште. Кай арада булды соң әле бу? Йа Хода. Бәхетле ит баламны, изге теләкләремне кабул ит.

Киленебез Сәрия дә болай сабыр холыклы күренә, Сәлихҗан. Ихахай да михахайланып йөрүче кызга охшамаган, ачылып сөйләшә белә. Тәрбияле гаиләдән. Ә Рушаныбызга карап торулары! Иншалла, тәүфыйклы килен булыр. Күгәрченнәр күк гөрләшеп, тату, бәхетле гомер итә күрсеннәр инде, йа Рабби.

Әй, Сәлихҗан, җанкисәгем. Син бер генә дә күрмәгән, кулыңа алып сөймәгән улыңны синнән башка гына өйләндерәм бит. Син инде мине гафу ит. Үзең безнең белән булсаң, фатихаңны бирер идең микән? Бирмичә, бирер идең, бирер идең. Улың бөтен яктан да коеп куйган үзең бит. Их, шушы шатлыклы бәйрәм кичендә кайтып керсәң соң, Сәлихҗан! Сәлих-җа-а-ан!

...Инде бусын ничек итеп сөйлим икән сиңа, күз нурым. Мин хәзер тулы бер ятимә карчык бит, бәгърем. Рушаныбыз әфисәр, хәзер Әфганда әле менә, хаты да күптән килми шул, дип әйткән идем ич әле. Инде хәзер ул да юк, Сәлихҗаным.

Улыбызның кургашын табутка салган гәүдәсе генә кайтты шул, җаным. Ачып карарга да рөхсәт юк, диделәр. Инде мин, Сәлихҗан, бөтенләй ятимә. Син җук, Рушан җук. Сәрия, дисеңме? Ул да җук шул хәзер. Кияүгә чыкты бит ул. Рушанны ул да минем күк өзелеп көтте-көтте дә, табуты килгәч, үзен-үзе белештерми ничә айлар буе җылады. Мин инде, акылына зыян килмәсен дип, кара кайгыга баттым. Тора-бара игә килде инде аннары. Ничек чыдадың, дисеңме?

Әй, җаным... Минем җөрәгем урынында кара җанган кисәү башы гына калгандыр инде. Ачуланмасаң, бер сүз әйтим әле, Сәлихҗан. Нитикле авыр булмасын, Рушанымның кабере янына барсам, дога укысам, җанымны басып яткан авыр таш төшкән сыман тоела. Аның, ичмаса, зираты бар. Ә синең? Мин Рушан белән сөйләшәм, киңәшәм дә җаныма ял була.

Бер кеше башына шултиклем кайгы-хәсрәт килсен әле, ә?

Сәрия китте шул, китте. Рушанны күмгәннән соң ике еллап бергә яшәдек. Бик тату тордык. Тик яшь җан бит ул. Бермәлне күрше авылда укытучы булып эшләүче Хәниф атлы җегет килеп аягыма җыгылды.

— Сабирәттәй, җаным, мин бит гомерем буе Сәрияне яраттым. Рушанга чыккач та уйлаганым, яратканым ул булды. Зинһар өчен, гафу ит. Без сине ташламабыз, рөхсәт ит, бергә булыйк ла, — диде. Рәхмәт, Сәрия үзе:

— Әнкәй, син ничек әйтәсең, мин шулай итәм. Тик рәнҗемә генә, зинһар, — дигәч, мин кызым шикелле якын, үз иткән кешемә ничек итеп каршы торыйм ди. Үзәгем өзелсә өзелде... Фатиха бирдем. Син дә шулай итәр иең бит, Сәлихҗан, шулаймы?

И Сәлихҗан, канатым, күз нурым. Мин аларга үз кулым белән урын җәйдем бит, җаным. Һай, ул кичтәге хәлемне белсәң иде!

* * *

Әйе, Сабирәттәй, килененең ай-ваена карамый, бу юлы да яшьләргә үзе урын хәзерләде. Тыпырчынган йөрәген баса алды, бу көн берәүләрнең кадерле, матур никах көне иде бит. Караватка яңа мендәр-юрганнарын китереп өйде, бер бөртек тузан да калдырмыйча тәрәзә төпләрен сөртеп чыкты, гөлләргә су бөркеп, сөртеп хушландырды, бүлмә һавасын алыштырды. Бизәкле ак чыбылдык артында кияү ятагы, бизәнеп-ясанып, яшьләрне көтеп калды. Бу юлы инде теге агач карават түгел, ә көмеш шарлары ялтырап торган тимер карават иде...

Кунаклар яшьләргә бәхет-сәгадәт, ямьле тормыш теләп таралгач, Сабирәттәй дә, догаларын укып, ак келәткә җәйгән урынына кереп ауды. Бик арыган иде ул, бик арыган иде, тик күзенә йокы гына кермәде. Миен-йөрәген сызлавык сыман имеп торган авыр уйларыннан арыныр өчен кат-кат дога укып та карады, юк шул, йокы алмады.

Кая алсын соң ул, кая алсын! Бүген бит ул Рушаны ятагына кияү итеп бөтенләй чит кешене салды. Үз кулы белән урын җәйде. Йөзенә әз генә дә әрнү, үкенү, ризасызлык галәмәте чыгармады. Елмайды, сүзгә катнашты, кунаклар сыйлады, ә уе, йөрәге аның читтә иде. Ул күңеле белән барын да аңлый, үзе үк килененә ризалык биргәнгә, аңа берни дә әйтә алмады. Ә менә улы урынына (улы урынына!) чит кеше кереп ятуы аның аңын, зиһенен томалый, күкрәгенең әллә кай җиреннән борнап чыккан әрнү карчыкның йөрәгенә, башына үрмәли, бораулый, буа, тынын кыса иде. Мондый чакларда кайры корты сыман җанын-рухын кимергән, адәм күтәргесез газаптан гаҗиз булган Сабирәттәй Ходайга сыена иде.

Йөрәге тартышып-тартышып чәнчи башлагач, карчык торып утырды.

— Йа Ходаем, йа Раббым, шушы колыңа сабырлык бирсәнә! — диде ул. — Бу җан газабын үзең бирдең ләбаса. Ник кенә соң аның тегермән ташыдай авырлыгын җиңеләйтмисең, ә? Мин, Син кушканча, барына да разый булдым. Инде бу хәлләрнең дә газабын күтәрдем. Ник соң инде җөрәгемне баскан шул авырлыкны алып ташламыйсың, бер Ходаем?! Син бар, Син хак лабаса! Син минем кан җотып җөргәнемне күреп, белеп торасың ич. Күрә торып Син ник мине ташладың? Ник ташладың? Нинди гөнаһларым өчен? Гаделлегең кайда соң Синең, йа Раббым?

Әстәгъфирулла тәүбә! Бер Ходаем, үзең ярлыка күр. Гөнаһ сөйлим ләбаса. Әстәгъфирулла... Хак Тәгаләм, бу гөнаһлы сүзләр иң якыннарын югалткан, интеккән тол карчык авызыннан чыкканны үзең белеп торасың лабаса. Кодрәтең киң, җиңеләйт хәлемне...

Сабирәттәй күпме генә тырышса да йоклап китә алмады. Инде ай да, югары күтәрелеп, салкын нурларын йокыдан изрәгән гамьсез урамнарга, йортларга, урман-кырларга сибә иде. Келәт ишеге ярыгыннан төшкән яктылыкка карап утыра торгач, карчык урамга чыгарга ниятләде. Шыгырдатмаска тыры-

шып, капка келәсен күтәрде дә тышка атлады. Урындык янына килде, тик утырырга онытты. Тулган ай нурларында коенган җиһан аңа тирән көрсенгән сыман тоелды.

Юк, йөрәкнең сызлавы монда да басылмады, тартышып-тартышып әрнүен дәвам итте. Бу мәлне янына берәр кеше килеп чыкса, никадәр сабыр булмасын, карчык аның җилкәсенә башын салып әрнеп елар, бәлкем, йөрәге дә басылыр иде. Юк шул, урамда кем дә күренми, авыл тып-тын, изрәп йоклый иде.

Сабирәттәй шундый иксез-чиксез галәмдә үзен котылгысыз ятим итеп тойды. Карчык күңеленнән тулып ташыган үпкәле-рәнҗүле сүзләрен айга сөйли башлавын да абайламады.

— И якты ай, — диде бугай ул. Әллә әйтмәдеме икән? — Минем шултикле җөрәгемне талаган уй-хисләремә бер син генә шаһит лабаса. Шушы иксез-чиксез җиһанда, күпме кеше яшәгән дөньяда хәлемне сөйләрлек бер генә зат та юкмыни соң? Инде нишләргә, ни кылырга, ялгыз башымны кайларга куярга соң миңа? Җөрәгемнән өзелеп төшкән балам ятагында, үз кулым белән җәеп биргән ятакта, улымның хәләл җефете чит-ят кеше кочагында ята.

Гаеп итеп әйтмим. Ходай шулай язгандыр. Ул кешенең бер гаебе дә юк, үз бәхете үзенә. Мин күпсенмим. Тик менә минем улым соң, улым... И газиз улым, күңелем канаты! Сине җөрәк астымда җөрткәндә, инде җакты дөньяга килеп, тәпи җөри башлаганда, «әннә» дип тәүге сүзең әйткәндә, үсеп буйга тартылганда, җегет булып җитлеккәндә, бу хәлләр уема да кермәде. Менә бит, мәрхүмем, синең хатыныңны чит ир белән синең түшәгеңә салдым. Мәрхүмем, гафу кыл син мине, гөнаһлы анаңны гафу ит, бәгърем. Бәхилләшик инде.

Әтиең минем бу эшемне хуплар идеме икән, улым? Мин бит беркемгә начарлык эшләмәдем, күңелем-җаным гел изгелектә генә булды. Ник соң миңа шултикле авыр, иңнәремне изеп, сабыр канатларым, рухым сынарлык тау-тау газап өелә?..

Шулай әрнүле уйларына бирелеп озак басып торган бер мәлдә Сабирәттәй колагына каяндыр таныш җыр ишетелгән кук булды. Җыр, көчәя барып, аның бөтен күңелен биләп алды. Бу җыр аның үз җыры лабаса. Сагыш баскан саен ул шушы җырны авыз эченнән генә көйләп йөри иде:

Бәхет, диләр, бәхет, диләр,  
Бәхет кемгә төс икән?  
Чәчәк аткан язлар дисәм,  
Инде салкын көз икән.

Бу юлы да үзе чыгарган шушы җыр карчыкның күңеленнән, сагыштан йончыган, арыган йөрәгеннән тышка бәреп чыкты. Җыры беткәндә, йөрәге бераз урынына утыра төшкән Сабирәттәй инеш буасы янында басып тора иде. Яулыгын салып, якындагы куакка элде дә, карчык учлап-учлап битенә су сибә башлады. Тын буаның пыяладай шома суы өстендә, аны әллә кайларга чакырып, алтын ай юлы ялтырап ята иде...

## Соңарган бүләк

Капка баганалары юан, нык имән икән. Коймаларында да ник бер тишек күренсен. Буявы да яңартылып торадыр, төсен бераз кояш алса да, каушакланмаган, тигез...

Газизҗан абзый, аларның йортлары янына килеп туктагач, әнә шулай уйланып торды. Никтер артына борылып карады, кирәргәме-юкмы дип, тагын бераз таптанды. Ник дип килде соң әле ул монда, аңа биредә нәрсә калган. Үтәсе үткән, сүнәсе әллә кайчан сүнгән ич инде. Алай дисәң, 40–50 ел күрешмәгән Зөлфиягә күз салып, хәлен белеп, бурычын үтәп чыгуның ни гаебе бар?

Бергә җидееллык мәктәптә укыганнар, җиләккә, чикләвеккә йөргәннәр. Аннары... Һәй... Аннары... Хәл белеп чыгуның бер гаебе дә юк. Ире дә вафат, ялгыз яши, диләр. Ялгызлыктан да начар нәрсә югын ул үзе дә белә, яхшы татыды. Кереп чыгарга кирәк.

Газизҗан абзый чал мыегын сыпырып куйды, эшләпәсен рәтләбрәк киде, чалбарын өскәрәк тартып, күлмәк якаларын, галстугын төзәткәләде дә капка келәсенә басты. Сак кына этәреп капканы ачты. Аның күз алдында түбәсенә шифер ябылган таза каралты-кура пәйда булды.

— Ишегалды ничек итеп чиста себерелгән, аркылы яткан салам кисәге дә күрмәссең. Элеккечә үк, пөхтәлеген югалтмаган икән... Пөхтә, бик пөхтә иде шул ул, — дип уйлап алды кунак.

Тол хатын-кыз йортына сәлам бирми керү ярамаганга, Газизҗан абзый, беркемне күрмәсә дә:

— Әссаләмегаләйкем, хуҗалар өйдәләрме? — дип тавыш салды.

Өйалды ишеге ачылып китте, анда яулыгын артка бәйләгән олы яшьтәге хатын-кыз күренде.

— Кем бар, Ходайның нинди кунагы мактап йөри? Әйдүк, әйдүк, узыгыз, — диде хатын, әле генә элгечтән алган суган бәйләмен кире элә-элә. Аннары, танырга теләп, кунакның йөзенә текәлде:

— Сөбханалла... Әллә Газиз инде?.. Синме соң бу, Газиз?

Газизҗан абзый Зөлфияне тавышыннан гына таныды, ләкин гадәттән тыш гаҗәпләнүен яшерергә теләп тезеп китте:

— Ие, мин әле, мин, Зөлфия. Мин әле бу. Исәр әйтмешли, гомер күзе җитеп килгәндә кайткан идем әле менә. Туган-үскән якларны бер күреп килим дип... Менә сезгә дә кагылырга уйладым. Мин озакка түгел. Хәлеңне белим дип кенә. Ялгыз калгансың, дигәннәр иде. Нихәл яшисең? Бик авыр түгелме?

— Иһи-һи... Газиз диген, ә? Әйдә, әйдә, уз. Өйгә кер.

Хатын шулай дисә дә, үзе һаман болдыр ишеге төбендә кала бирде. Газизҗан абзый аның хәлен аңлады, ул үзе дә каушаган иде:

— Мин бит ни... Күреп чыгыйм дип кенә. Менә шул инде... Ничә еллардан соң...— дип кабатлады.

— Ярар, ярар... Менә рәхмәт. Әйтәм аны бүген күңел әллә ничек кузгалып торадырые. Көтү куганда, зыяраттан күке тавышы ишетелгәч, кылт итеп синең сүзең искә килеп төшкән ие. Күрешергә булган икән.

— Нинди сүз ул, Зөлфия?

— Күке бүтән кошларга әлимент түләргә тиеш, дигән идең ич бервакыт.

— Хи-хи-хи... Хәтер үзеңдә.

Хатын, кинәт айнып киткәндәй хәрәкәт ясап, кулларын җәеп җибәрде:

— Кара инде мин җүләрне, ә! Кер, әйдә, Газизҗан, кер. Мактап йөрисең икән. Самавырым кайнап тора. Майга гына төче коймак та әмәлләгән идем. Бик тәмле. Шундый кадерле кунакны ишек төбендә тотам бит. Күңелем нидер сизгән иде шул, сизгән иде.

«Кадерле» сүзен ишеткәч, Газизҗан абзый тетрәнеп китте. Бер мәлгә аңа узган еллар эреп юкка чыккан сыман тоелды. Әйе, гомерләре таңында алар бер-берсенә «сөям», «яратам» дип әйтергә оялалар иде. Газиз, Зөлфияне беренче мәртәбә чытырдатып күкрәгенә кыскач:

— Син миңа шулхәтле кадерле,— дигән иде.

Зөлфия дә:

— Син дә миңа, — диде.

Шуннан инде алар бер-берсенә, икәү генә калганда, гел «кадерлем» дип кенә эндәштеләр. Их, кайчан булган ул хәлләр... Әллә булмаган дамы?

— Ярар микән соң... Үзең генә булгач, диюем.

— Үзем генә түгел мин. Оныгым, кызымның кызы Казаннан кайтканые. Кичә телевизордан бик озак кино карап утырды да, әле булса да йоклап ята. Иркә чыпчык. Яңа сауган сөт ярата үзе. Уятып караган идем, тормады.

Зөлфиянең каушаганлыгы инде бетеп бара иде.

— Йә, уз инде. Чәй эчми китәргә рөхсәт юк. Шултикле еллардан соң бит, шултикле вакыттан соң. Ничек болай керәсе иттең, ә, Газизҗан? Рәхмәт яугыры, — диде ул.

— Иттем инде, иттем. Син сорама, мин әйтмим, дия идекме әле? Гомер үтте китте, ие. Актай суы сыман акты да китте. Итәк-чабуларны җыяр чаклар җитеп килә.

Туфлиләрне салып куйгач, Газизҗан абзый хатын артыннан алгы якка атлады. Бүлмә шәһәрчә матур, пөхтә итеп җиһазланган, җыештырылган. Стенада, идәндә келәмнәр. Тәрәзәдә кашагалар! Һай, ул авыл йортының тәрәзә кашагалары! Кайсы гына авыл егетенең күңел түрендә сакланмый икән алар. Шулар арасыннан кояштай елмаеп караган йөзне көтеп, кайсы гына егет авыл урамнарын таптамады икән!

— Хуш, бик хуш... Менә әле каралты-куралары гызны күргәч тә уйлап куйдым. Тормышыгыз таза булган, матур яшәгәнсез икән. Рәхмәт. Искәндәр ул уңган егет иде шул, мәрхүм.

— Ие, Газизҗан, дөнья бәясе кеше иде ул. Кулыннан килмәгән эше жук иде. Мич чыгару дисеңме, балта эше дисеңме... Чалгы таптатырга да бөтен авыл килә иде. Кулы җиңел иде...

Зөлфия, өстәл өстендәге эскәтерне сыпырып, тәлинкә өстендәге тастымалны алып куйды. Кунак борынына тәмле коймак исе килеп бәрелде. Хатын табын хәзерләп мәш килгәндә, Газизҗан абзый аның йөзенә, кулларына игътибар белән карап-карап алгалады.

Үзгәргән шул, үзгәргән, дип уйлады ул. Чәчләре, кашлары агарган... Күзләрендә әле һаман якты нурлар уйнап алса да, алар да элеккеге сихри зәңгәрлеген югалта төшкән. Маңгаенда җыерчыклар... Күз төпләре каралып киткән. Әй, еллар. Кая илтеп югалтасыз икән сез ул яшьлек гүзәллеген.

Кунак абзыйның башыннан кинәт кенә: «Ә үзең соң!» — дигән уй йөгереп үтте. Кая синең дулкындулкын чем-кара чәчләрең? Сип-сирәк калдылар лабаса. Сакалыңны кырып йөрмәсәң, Кыш бабай бит инде син. Ярый ла, кара кашың Брежнев бабайныкы сыман... Шулай уйлана-уйлана, Газизҗан абзый Зөлфияне күзәтеп утырды.

— Син, Газизҗан, әйдә, тартынма әле, чәй эчеп җибәр әле. Менә атланмайга гына пешергән коймагыннан авыз ит. Әйдә, җә инде, җә... Улларым, кызларым тәмле чәйдән өзмиләр. Менә әле оныгым тагын цэйлүн чәе апкайтты. Аның хуш исләре дисеңме, тәме дисеңме...

Кинәт түрдәге бүлмә ишеге ачылып китте. Аннан, яфраклар арасыннан очып чыккан кош сыман, 18 яшьләрдәге чибәр кыз килеп чыкты.

Зөлфия:

— Менә Гөлфия кызым да уянды. Бездә кунак абый бар, кызым. Безнең авылдан чыккан атаклы журналист Газизҗан абыең шушы инде ул, — дип таныштыра башлаган иде, чая кыз, бүлмәне яшьлек нуры белән балкытып, кояштай елмайды:

— Исәнмесез, Газизҗан абый! Сез менә нинди икәнсез. Ә мин сезне ишетеп кенә белә идем. Хәер, сезне республикада кем генә белми икән?

Гүзәл кыз әйтергәме-юкмы икән, дип уйланып торган кебек булды да:

— Сезнең турыда миңа дәү әти дә сөйләгәне бар иде, — дип юынырга йөгерде.

Кунак телсез калды. Сәлам кайтарырга да онытты. Чөнки кыз нәкъ менә яшь чагындагы Зөлфия иде. Картның йөрәге урыныннан купкандай булды. Сөбханалла! Шултикле дә дәү әнисенә охшар икән, билләһи. Туп-туры күзгә карап алулары, алсу битләре, матур колак яфраклары, аяз күк кебек зәңгәр күзләре, озын, бөгелеп торган керфекләре, аяк атлаулары... Йа Хода!

Кунак хәлен хуҗабикә дә аңлады бугай:

— Бусысы гел үзем инде, — дип куйды. — Аннары тагын кыстарга кереште: — Җәле, Газизҗан, ашап-эчеп утыр әле син... Менә бит, Ходай кушкач, кемне сыйларга насыйп булган икән. Менә яңа аерган каймагыннан да авыз ит инде. Бик тәмле, җәле, җә...

— Рәхмәт, бик рәхмәт. Олыгайгач тамак та кысыла төшә икән ул. Ә шулай да эчми булмас, ахрысы. И-и, чәең кәүсәр суы шикелле бик тә тәмле икән, — дип, кунак тәмләп чәй эчә башлады.

— Син элек-электән телгә маһир идең шул... Кәүсәр суы... Син эч әле, эч. «Чәй чәй урынына, икене эчсәң — мәй урынына», — дия иде Искәндәр. Авылда хәзер бөтен эшне мәй башкарса да, мин аны тотмыйм. Сиңа да куя алмыйм. Бөтен хуҗалык эшләремне улларым кайтып эшли бит.

— Һәй, нинди мәй ди ул. Нинди мәй. Ул эш күптәннән юк инде миндә. Яшь вакытымда да җенем сөймәде.

— Ишетеп белә идем анысы, белә идем. Җә, үзең ничек яшисең? Картаеп буламы? Балаларың ничек, ата итәләрме?

— Ходайга шөкер... Тик менә хатыным гына гүр иясе. Биш ел тула инде. Башта ялгыз яшәдем. Аннары инде менә улым, киленем белән. Бик илтифатлылар, сүз дә юк. Үзем менә күптәннән пенсиядә. Ара-тирә әле дә язгалыйм.

— Син язу-сызуга һәвәс идең шул. Журналист пенсиягә чыкмыйдыр ул. Бер-ике кат сине телевизордан да күрдем. Китапларыңны укып бардым... Тапканда. Мәкаләләреңне әле дә укыйм. Тик ятмыйсың үзең...

— Мин беркайчан да җил ауламадым анысы. Күңелләрне бушатасы килгәндә, әле дә ярый каләмем бар, Зөлфия.

— Әй, ул күңелләрне... Гел генә яшь кала икән лә ул. Синең дә шулаймы?

— Һәркемнең шулай ул, Зөлфия. Ие. Бөтен узган гомер күз алдында тора. Яшьләр берәр җиргә чыгып киткәндә, кулыма каләм алам да, күңелне давыл айкый башлый. Нишләп, мин әйтәм, гомер эчендә бер генә хәбәр дә салмады, дим. Дөньяда бер генә яшибез бит, дим. Бервакыт үлемнән калдым, шул чакта да. Ишетелми булмагандыр бит, дип уйлыйм... Күңел өчен бер...

— Ишеттем, Газизҗан, ишеттем. Мин бөтенесен дә беләм. Университетта укыганда исемең гөрләп торганын да... Беренче китабыңның кайчан чыкканын да, кызың, улың кайчан туганын да.

— Болар минем өчен зур яңалык бит әле, Зөлфия...

— Кызыңның тимераяк шуып дан алганын, хәтта квартирлы булгач, туганнарың килгәч, хатының тавыш чыгарганын да. Күңел өчен бер, дигәнгә әйтүем. Кузгатмыйк без аларны, Газизҗан. Тирәнгә кермик. Күкрәкләр күп сызылган инде. Кеше җаны тутыкмый лабаса, тимер түгел бит ул.

— Син үпкәли күрмә, Зөлфия. Мин сине тормыш эзеңнән чыгарырга килмәдем. Әй каймагы да каймагы... Тансыклаганмын икән авыл каймагын... Карале, менә нинди уй килде бит әле: безнең менә шулай чәй эчүебез гомердә беренче кат икән бит, әй!

— Әйтмә инде... Мәктәп елларында ипи кисәген бүлгәләп ашаганны санамасаң ...

— Әйе, андый шәп, тай-тулак чаклар да бар иде шул. Бар иде алар.

Карале, Зөлфия, син ачуланма да, үпкәләмә дә. Бу дөньяда тагын очрашабызмы-юкмы, бер сорау бирим әле. Менә бит, ачык чыраеңны күргәч, батыраеп киттем бит әле. Ничек шулай килеп чыкты соң ул безнең, ә? Шундый матур итеп, өметләнеп йөрдек тә... икебез ике якка... Кош балалары сыман, дип җырлый идек бит. Ә?

— И-и... Үткәннәргә кагылсаң...

— Зинһар, ачуланма... Әнә агарып та киттең... Мин бу сорауны үзем-үзем гомер буе биреп йөрдем. Җавабын гына таба алмадым.

— Язмыш, күрәсең, Газизҗан. Уртак булмаган ул безнең. Син педучилищега барып кердең. Ә мин керә алмадым. Урыс теленнән имтиханда «өчле» куйдылар. Инде мин сиңа тиң түгел, дип уйладым, күрәсең.

— Әй! Кешеләрне бит мәхәббәт тиңли, ә үлем тигезли, Зөлфия.

— Яшь чак — юләр чак, дип юкка әйтмиләрдер инде. Ул чакта кем белә инде аны, мәхәббәтме ул, юкмы...

— Менә, менә... Ә күңел? Күңел? Аны кая куясың? Җиденче классны бетергәндә, миңа кулъяулык бүләк иткәнең исеңдәме соң?

— Менәтерә...

— Парлы уенда, кулга-кул тотынышып басып торганда, сизәм, кулларыбыз арасында нидер бар. Аннары син аны минем кулга төрттең дә йөгереп киттең. Кулъяулык! Кайткач карасам!

Кадерлем!
Кулъяулык бүләк итәм,
Нурлы йөзең сөртерсең,
Аерылсак та, кавышсак та,
Төсем итеп йөртерсең, —

дип чиккән идең.

Ул сүзләрне укыгач... үлдем мин. Үлдем. Ничек инде ул аерылышу турында башына уй китерә ала, дип ут йоттым.

— Әй, яшьлек, яшьлек. Мин кыек-мыек сөйли белмим, Газизҗан. Син үзең дә артык кыюсыз идең шул. Чәчемне сыйпарга ояла идең. Ә Искәндәр алды да түшәгенә дә салды. Авыр туфрагы җиңел булсын.

— Кулъяулыкка чиккән әнә шул «аерылсак та» дигән сүзләрең миннән кап-кара кисәү башы ясады... Ашый-эчә алмадым. Училищеда атнаны уздыра алмый җәфа чигә идем. Дәресләр бетәр-бетмәс, шимбә көнне авылга йөгерә идем. 30 чакрым... Урамда очратмаммы, кызлар кич утырган җирдә булмасмы дип. Юк шул. Кызлар, егетләр аша биргән хатларыма да җавап язмадың. Йөз суымны түгеп, аларны аптыратып бетерә идем.

Беләсеңме, рәнҗеп әйтүем түгел. Мин шул чактан бирле еш кына төшемдә кара шомырт ашаганымны күрәм. Ашыйм да, авыз бөрешә. Син каршыма киләсең, ә мин берни әйтә алмыйм.

Ялга кайткан саен, очрамасмы дип, яңгырмы, кармы, урамыгызны кат-кат әйләнә идем. Өметем бик озак өзелмәде. Аннары инде... син кияүгә чыккач... Әле менә кичә дә сезнең урамнан уздым. Йортыгыз янында уйга талганмын. Аны ташлагансыз икән. Тәрәзә капкачлары кагылган, сеңгән, беткән.

— Ие шул. Мин кияүгә чыккач, әтиләр вафат булгач, аның бөтенләй рәте китте... Гомер үтә торды... Искәндәргә кат-кат әйттем, сүтеп ал, утынга булса да ярар әле, дип.

— Ник сүтмәде соң?

— Син туып үскән йортны сүтәргә кулым бармый, дия иде.

— Димәк, ул да сине бик яраткан икән.

— Булгандыр инде. Ә син тальяныңны ташламадыңмы соң?

— Һи... Юк. Ул минем изге сердәшем. Дөньяда моңсыз яшәп буламыни? Әле дә ул бар.

— Ә мин, урамнан син гармун уйнап узганда, үрсәләнеп елап кала идем.

— Шунда йөгереп чыксаң нәрсә булыр иде?

— Әти-әни дә тезгенне кыска тоттылар, күрәсең. Кыюлыгым да җитмәгәндер, язмыш кочагы да кысан булгандыр инде. Урык-сурык кына очрашып йөрүне дә теләмәгәнмендер, күрәсең.

— Менә кичә шул сезнең өегез янында басып торганда, сине күрмичә китмим дигән уйга килдем мин.

— Искәндәр зыяратына барганда, мин дә сезнең урамнан узам, Газизҗан. Анда хәзер бер-ике генә йорт утырып калды шул. Урамыгыз тешләре сынган тарак диярсең. Таралды халык, таралды. Сезнең өйнең эзе дә юк. Кычыткан, кычыткан... Иске нигезләрдә ник кычыткан үсә икән дә, ник гөлләр үсми икән ул, ә? Миннән торса...

— Гөл бит ул мәхәббәт кебек. Кадерләгәнне ярата. Әйе, безнең өй теге чакта ук иске иде ул. Сезнеке әле яңа иде. Йә, ярар, чәең бик тәмле булды. Рәхмәт, кадерлем. Ачуланма инде, яме...

Күңеленең әллә нинди почмагында сакланып, кинәт тернәкләнеп киткән сүз бәгырьгә барып кагылгангамы, әллә башка сәбәптәнме, дымлы пәрдә каплаган күзләрен яшерергә тырышып, Зөлфия читкә борылды:

— Кая китте соң әле бу бала? Юынырга чыккан иде ләбаса. Тавышы килә түгелме? Әйе, ул шул. Кайтып килә. Авыл кызлары да ияргән димме?

Ул арада ишек ачылып китте. Аннан, шау-гөр килеп, бүлмәгә әллә нинди хуш исләр тутырып, ике авыл кызы белән Гөлфия кайтып керде. Алардан аңкыган яшьлек, балкып торган көләч йөзләрен күргәч, Газизҗан да, Зөлфия дә елмаеп куйдылар.

— Әйтәм бит, кызлар, Газизҗан абый ул, дип, сезнең, безнең авылның атаклы журналисты. Менә үзе. Китапларын, мәкаләләрен укыганыбыз бар, үзен күргәнебез юк, диләр. Болар минем дус кызларым, Газизҗан абый. Менә, кызлар, күрегез инде.

— Исәнмесез, Газизҗан абый, исәнмесез! Сез китмисезме әле? Без сезне авыл яшьләре белән очрашырга чакырырга килгән идек, — дип, бит урталарында чокырчыклары уйнап торган авыл кызы да сүзгә кушылды.

Икенче кыз матур хәрәкәт белән озын кара толымнарын артка чөеп ташлады да:

— Сез бит язучылар, рәссамнар, композиторлар, артистлар белән аралашып яшисез. Алар турында язасыз. Чит илләргә дә чыгып йөргәнегезне беләбез. Шул турыда безгә сөйләмәссезме икән? — дип өстәде.

Газизҗан абзый:

— Менә бит, юктан гына кодагый булып куйдым әле, — дисә дә, ризалыгын белдереп баш какты.

Олылар бер-берсенә карашып, яшьләргә сокланып торганда, Гөлфия тагын элеп алды:

— Ә мин сәнгать академиясендә укыйм, Газизҗан абый. Җырларга, биергә өйрәнәм. Рәсем дә ясыйм, фотога да төшерәм. Әһә, менә хәзер мин сезне фотога төшерим әле, истәлеккә булыр, — дип, кыз күрше бүлмәгә йөгерде. Аннан ялт итеп фотоаппарат алып чыкты.

— Төсле сурәт була бу. Ягез әле, дәү әни, Газизҗан абый, якынрак утырыгыз әле.

Олылар каршы килеп маташтылар, тик бу хис өермәсен туктатып булмасын тиз төшенделәр.

— Ягез, ягез, якынрак килегез инде. Мин беләм бит, сез бер-берегезне яратып йөргәнсез. Тик бергә була алмагансыз гына. Беләм, беләм, дәү әни, ачуланма. Бу рәсем икегезгә дә истәлеккә булыр. Мин аны «Таһир-Зөһрә» газетасына да бирермен.

Ниһаять, Зөлфия оныгының сүзен бүлдерә алды:

— Кызым, дәү этиең рухын рәнҗетәсең бит, алай ярамый...

— Дәү әнием, дәү эти акыллы кеше иде бит. Сезнең мәхәббәтегез турында да ул миңа матур итеп үзе сөйләгән иде. Нишләп рәнҗесен икән ул? Мәхәббәт өчен рәнҗиләрмени, — дип, Гөлфия каршы килде.

Кыз олыларны янәшә утырырга мәҗбүр итте, фотоаппаратын черт-черт иттереп, аларны рәсемгә дә төшереп алды. Аннары:

— Әйдәгез, кызлар, кыярларга су сибәбез, — дип, иптәшләре белән чыр-чу килеп чыгып китте.

Бераз Зөлфиягә төбәлеп карап торганнан соң, Газизҗан абзый:

— Сезгә килүемнең төп сәбәбен мин сиңа әйтмәдем бит әле, Зөлфиякәй, — диде. — Мин бит өстемдәге бурычымны үтәргә дип килдем.

— Нинди бурыч ул, Газизҗан? Һич аңламыйм.

— Мин бит теге чакта синең бүләгеңә каршы берни дә бүләк итә алмадым.

— Җә инде, Газизҗан. Син ни сөйлисең инде, ә... Онытылып беткән нәрсәләрне искә төшереп, кыйналып утырасың. Кызлар егетләргә яулык бирү — ул матур гадәт иде бит.

— Онытылып беткән, дисеңме? Юк, онытыла торган нәрсә түгел ул. Онытыламы соң! Мин аны гомер буе хәтердә сакладым. Соң булса да — уң булсын. Ачуланма. Менә сиңа дип алтын алкалар алып кайттым. Ничә дистә елдан соң... Рәнҗешмик, ал әле шуны. Җаным тыныч булсын әле.

— Газизҗан дип юкка гына кушмаганнардыр шул сиңа, кадерлем. Җук, җук, кирәкми. Җукка гына расхутлангансың.

— Ул чакта мин сиңа берни дә бүләк итә алмый идем шул. Өстемдәге йөкне төшерик инде, яме. Кире какма, зинһар.

— Йа Алла... Гаҗәп кеше син. Шундый йөк тә буламыни соң?

— Була икән шул. Тора-бара син миннән фәкыйрьлегем аркасында йөз чөердең, дип уйлап йөрдем бит. Менә хәзер икебез дә тигез — әнә нинди уллар, кызлар, оныклар үстердек. Саулыгыбыз да зур байлык...

— Дөрес инде анысы, Ходайга шөкер. Тик менә бу алкаларың. Ни дип әйтергә дә белмим. Кирәкмәс иде.

— Алайса, әйдә, без аларны Гөлфиягә бирик. Синең төсең итеп тагып йөрсен. Әйдә, ә?

— Шулай дисеңме? Җулын да таптың, рәхмәт яусын. Безнең... борнап та ачыла алмаган яшьлек хисебез төсе булсын ул. Изге яшьлек төсебез. Искәндәр рухы да рәнҗемәс.

— Менә рәхмәт, хак сүз.

Зөлфия оныгын чакырып кертте.

— Кызым, Газизҗан абыең бик кадерле бүләк алып кайткан икән. Ничек кенә дип әйтим... Аны без сиңа бирергә булдык. Дәү этиең сөйләгән иде, дисең ич. Алайса, барын да беләсең син. Бу алкалар сиңа булсын, — диде ул.

Кунак та аңа кушылды:

— Әйе, Гөлфия кызым, безнең тәүге хисебез төсе булсын. Менә бит, театрдагы шикелле килеп чыкты бит әле бу... Куллар да калтырап китте. Ал инде, мә, ал.

Кыз, көтмәгән хәлдән тәэсирләнеп, әле Зөлфияне, әле Газизҗанны кочаклады.

— Нинди матур алкалар! Рәхмәт сезгә, икегезгә дә, — диде ул. — Рөхсәт итсәгез, мин, сездән барын да сорашып, мәхәббәтегез турында пьеса язармын, яме. Үзегез дә театрдагы шикелле булды бу, дисез ич.

— Риза, кызым, риза. Булдыра алсаң, карарсың.

Газизҗан абзыйның дулкынланган йөзендә елмаю уйный иде.

— Ярар, мин китим инде, — диде ул. Бераз сүзсез торганнан соң гафу үтенгәндәй өстәп куйды: — Озак еллардан соң матур күрешү булды әле бу. Бик көтеп алган күрешү. Бәхет басып, Гөлфия кызымны да күреп китәм. Күз генә тимәсен сиңа, кызым. Сиңа мин бәхетле, мәхәббәтле тормыш телим. Сәламәт яшәгез. Фотосурәтең әзер булгач, миңа да берсен җибәрерсең. Менә визиткам. Йә, хуш иттек.

Зөлфия белән оныгы кунакны озата чыктылар. Газизҗан абзый аларның кулларын кысты да урам буйлап китеп барды. Борылып карамады, йөрәге кысып-кысып алса да туктамады. Бу минутта аның күңелендә капма-каршы ике хис көрәшә иде. Бер яктан — гомере буе җанын телгәләп торган бурычын үтәүдән туган тынычлык булса, икенче яктан — аны яшьлеге, тәүге хыяллары белән бәйләп торган җепләрне үзе үк өзүдән туган әрнү хисе иде.

...Газизҗан абзый авылның кунак йортына кайтып җиткәндә, күршедәге алма бакчасында сандугачлар әле дә, шаша-шаша, бер-берсенә мәхәббәтләрен җырлый иде.

# Нәгыйм-Нәгыймә имәне

Нәгыймә әбинең урманда вафат булу хәбәре мине бик нык тетрәндерде. Күз алдыма аның аксыл йөзе, нур чәчеп, йөрәкнең әллә кайсы җирләренә үтеп керә торган карашы, балаларча самими кеткелдәп көлүе килеп басты. Яшүсмер чагымда аның миңа гына сөйләгән сере хәтеремдә яңарды.

Нәгыймә әби җәен-кышын урманга йөрергә ярата иде. Олыларга ияреп, без аңа апа дисәк тә, ул инде шактый карт иде. Аның тамак төбе белән «khe-khe!» дип йөткергәләп узганын ишеткәч, әни:

— Нәгыймә апай тагын урманга китеп бара, — дип, түбән өй тәрәзәсеннән карап кала иде. — Аңа урман җене кагылгандыр, дип юкка гына әйтмиләрдер, күрәсең. Һаман урман юлында.

Җәй булса, ул тимер көпчәкле тәбәнәк арба, кыш булса, табаны әз генә алга бөгелгән иске чана сөйрәр иде. Аны сибәләп торган яңгыр да, кышкы зәмһәрир суык та куркытмый иде.

Вафаты да урманда булган икән мәрхүмәнең. Әллә ничә еллар буена сандыкта яткан бала итәкле күлмәген киеп барган, учында нинди дер бакыр балдак та булган, имеш. Бик юан, мәһабәт, ябалдашлы имән төбенә сузылып яткан да, инде нуры киткән күзләрен зәңгәр күккә төбәп, дөнья куйган.

Беләм бит мин ул имәнне! Беләм! Нәгыймә әбинең ни өчен ул имән төбенә барганын да чамалыйм.

Исән чагында аңа еш кына:

— Нәгыймә әби, гомерең буе урманнан кайтмадың, җитеп тормас микән? Туксанга җитәсең бит инде. Анда ниең калган? Утының да каралтың тулы. Машина белән китереп, турап, ярып та куйдык. Йөрмә инде. Хәлең китеп егылып ятсаң, эзләп табуы да читен булыр, — дип әйтеп тә караганнар. Моңа каршы карчык, карашын еракка төбәп, үзалдына гына елмаеп, тыныч кына, берни дәшми китеп бара икән. Тик бер генә мәртәбә:

— Урман ул, оланнар, минем өчен оҗмах. Күзем күргәндә, аяк-кулым йөргәндә барам әле, барам! — дигән икән.

Ул бездән ике йорт аша гына япа-ялгыз яши иде. Дөрес, аның кемедер булган, тик ул фаҗигале үлгән, дип сөйлиләр иде сөйләвен. Ачык йөзле, киң күңелле, аз сүзле иде Нәгыймә әби. Юлында очраган баланың башыннан сыйпамый үтмәс иде. Сугыш елларында моңа мохтаҗ балалар аз идеме? Балан, миләш, чикләвек, җиләк, әллә нинди үләннәр җыяр, аларны юмарт өләшер иде.

Бу урында, укучыдан гафу үтенеп, бераз түземлек сорыйм, чөнки кечкенә генә чигенеш ясамый булмый икән. Сәбәбен укучы соңрак аңлар…

Без үскәндә, авыл тормышын утынсыз күз алдына да китереп булмый иде. Без ул утынны урманнан кышын кечкенә чанага, җәен «уфалла»га төяп сөйри идек. Аның ни икәнен әйтеп тормыйм, аты корысын. Яшьрәк укучыларга моны олылардан сорарга калдырам. Алар аңлатыр. Менә шул «уфалла»ны 3—4 чакрым җиргә сөйрәп барасың, коры-сары җыеп, күпме урман әйләнәсең, аннары тапканнарны, телеңне урталай тешләп, тартып кайтасың. Таба алсаң йә урман каравылчысы тотып, утыныңны бушаттырып калмаса.

Без, яшүсмер малайлар, коры утын юнәтүнең бер җаен таптык. Коры агач ботагы күрсәк, балтаны билдәге киндерәгә кыстырабыз да өскә үрмәлибез. Кыен, билгеле. Әмма шатырдап торган коры ботаклар төяп кайткач, әнинең рәхмәтен ишетү ни тора. Хәзер генә ул кая карама газ да газ. Оҗмах мисалы! Ә без үскәндә…

Авылыбызның кече урман дип аталган урманы уртасында бик зур, бик биек имән бар иде. Үзе әллә кайлардан күренеп тора. Аның яшен олылар да белми, без яшүсмерләр кызыксына калсак:

— Аны хәвефле, диләр, янына барып йөрмәгез. Сезгә урманда коры-сары беткәнмени! — дип, күңелгә шом салалар иде.

Бервакыт миндә шул имәнне янына ук барып күрү теләге туды. Үстем, күрәсең. Ул мәһабәт имән урман юлыннан шактый читтә, эчтә иде. Әмма яшүсмер күңелендә туган теләкне ничек басып була соң? Кыскасы, мин, арбамны юлда калдырып, имән янына барып бастым. Ул шулхәтле биек, миңа аның башы күккә тигән кебек тоелды. Ә юанлыгы! Кайрысы бүрек-бүрек бүлтәеп чыккан, үзе ниндидер серле шаулап тора. Юан-юан коры аскы ботаклары шактый биектә, аларның кайрысы коелып беткән, инде каралҗым-көрән төскә кергән. Мин беләм, мондый ботаклар сөяк кебек каты була. Балта белән кисүе дә бик авыр, чык-чык бәреп бик озак маташасың. Килгән-килгән, бу ботакларны калдырып китеп булмый ич инде. Барын да киссәң, бер ат олавы чыгарлык…

Имәнгә менә алмыйча мин озак маташтым. Нечкәрәк агачка менү ансат, колачларга кул җитә. Ә моңа! Шулай да берничә кат егылып төшеп, кулларымны сыдырып бетерсәм дә, кайры кисәкләренә, кайчандыр сындырылган ботак калдыкларына ябыша-ябыша, мин беренче ботакка менеп атландым. Аннары инде агачның очына таба үрмәләдем. Кинәт миңа арттан кемдер кыштырдаган һәм карап торган кебек тоелды. Әкрен генә башымны борып артыма караган идем, куркудан тыным кысылды, аркамнан ниндидер кайнар дулкын узып китте, кулларым чытырдап агачка ябышты. Яфраклар арасыннан миңа бик зур күзләр текәлгән иде. Ул күзләр бер дә йомылмый, караганнар да катып калганнар. Мин ихтыярсыз:

— Әни! — дип кычкырып җибәрдем. Күзләргә җан керде, алар тирә-якка карап алды. Җиңелчә генә җил исеп куйды. Яфраклар җилфердәп алгач кына, мин янымдагы ботакта мәче башлы ябалак утырганын абайладым. Куркуым бераз басыла төшкәч, ботакларны селкетеп, көш-көш дип, ябалакны куа башладым. Аның артык исе китмәде, инде мин батыраеп каты итеп кычкыра башлагач кына, канатларын авыр җилпеп, күршедәге бер агачка барып кунды.

Йөрәгемнең дөпелдәве басылганчы, мин әле шактый вакыт ботак өстендә утырдым, аннары гына өскәрәк үрмәләдем дә урман өстенә күз салдым. Их, шул чакта мин кичергән хисләрне белсәгез икән! Югарыдан, биектән урман уч төбендәге кебек күренә. Эссе кояш нурларына коенып, әлсерәп, үзенә генә хас меңләгән тавышлар белән гөжелдәгән урман, өстән караганда, искиткеч матур икән ләбаса. Без урманны астан гына күрәбез бит, агачлар арасыннан гына. Ә менә өстән! Ул нинди гүзәл икән ич! Шул чактагы урман күренеше минем күңелемә мәңгегә сеңеп калды. Их, тагын бер генә мизгелгә шул елларга әйләнеп кайтасы иде дә, шул юан имәнгә менеп:

— Әй, урман, урманым! Исәнме, кадерлем, гүзәлем! Мин кайттым! Өзелеп сагынып, сине күрергә кайттым! Бер генә минутка теге, мин яшүсмер чактагы урманым бул әле! — дип кычкырасы иде.

Ул чакта да мин соклануымнан, дөньяда мәңге яшисе килү теләгеннән, бөтен күңелемне илаһи өметләр биләп алудан, биеклек тудырган олы канатлану хисеннән, күрәсең, кычкырып урман белән исәнләштем, җанлы нәрсә белән сөйләшкән кебек сөйләштем.

Урманга гашыйк булып шактый утыргач, аскарак төшеп, бер юан коры ботакны кисәргә хәзерләндем. Балта белән бер-ике генә суккан идем, кинәт астан хатын-кыз тавышы яңгырады:

— Кирәкми, кисмә!

Мин, сискәнеп, аска карадым. Анда Нәгыймә апа басып тора иде.

— Әнвәр, синме ул, наным?

— Мин, Нәгыймә апа, мин. Син дә мондамыни? Килгәнеңне сизми дә калганмын.

— Кисмә, улым, бозма имәнне!

— Бозмыйм мин аны, Нәгыймә апа. Коры ботакларын гына кисәм.

— Корысын да кисмә, наным. Тыңла сүземне. Көз җиткәч, мин сиңа күп итеп чикләвек җыеп бирермен. Кисмә, ярамый.

Нәгыймә апаның тавышы ничектер калтырап чыга иде.

—Һи-и, Нәгыймә апа. Үзем дә җыям мин аны… Ярар инде, ботаклары бик шәп, коры иде.

Шулай дип, мин шуыша-шуыша агачтан төшеп киттем.

— Игелекле бала син, наным. Олылар сүзен тыңлаган өчен Ходай Тәгалә тәүфыйклы итсен, бәхетле итсен. Дөнья-ахирәт игелек күр, — диде Нәгыймә апа.

— Мин аңламадым, Нәгыймә апа. Ул ботакларны ник кисәргә ярамый икән соң?

Шулай дип, мин аның янына килгән идем, аптырап киттем. Апаем, җиргә тезләнеп, нидер пышылдый, ә карашы югарыга, имән очына төбәлгән иде. Ә күзләреннән мөлдер-мөлдер яшь ага. Гаҗәпләнеп, мин аңа шактый озак карап тордым. Ә Нәгыймә апа, минем барлыгымны да онытып, дога укый иде. Укып бетергәч, ул, ике кулы белән битен сыпырып, миңа күз салды, аннары, күлмәк итәген астына кыстырып, җиргә утырды. Башын иеп, тагын уйга калды. Минем баштан бер уй йөгереп узды: авырый микән әллә?

Мин, якынрак килеп, кыяр-кыймас кына:

— Әллә кәефең киттеме, Нәгыймә апа? — дип сорадым. — Әйдә, кайтарып куйыйм үзеңне.

Нәгыймә апа яшьле күзләре белән карап торды да авыр итеп көрсенде:

— Гомере буе берьялгыз хезмәттә ватылган хатын-кызның кәефсез чагы да булыр инде аның, олан, — диде ул. Аннары: — Сиңа ничә яшь инде, Әнвәр улым? — дип сорады.

— Ундүрт. Унбишенче китте.

— Һәй, алтын чаклар. Әйтәм аны, урман белән сөйләшәсең… Минем дә синең шикелле чагым бар иде бит.Узды инде, узды гомерләр.

Нәгыймә апа тагын көрсенеп куйды. Аның тынычлана төшкәнен күреп, мин тагын кызыксына башладым:

— Кисәргә ярамый, дидең, Нәгыймә апа. Ә үзең ник икәнен әйтмәдең.

Нәгыймә апа тезенә кадалып торган чыбыкны сындырып ташлады, иплэбрәк утырды.

— Мин бит гел шулай битен җыерчык баскан карчык түгел идем, улым, — диде ул. — Бу имән яшьлегем истәлеге. Миңа уналты тулган гына иде. Янгын чыгып, урамыбызның өч-дүрт өе көл булды. Безнеке дә. Бәлагә тарган кешеләргә урман кисеп, йорт салырга рөхсәт бирделәр. Без дә этигә ияреп урманга килдек. Нәкъ менә шушы урында, шушы имән төбендә, балтасын агачка чабарга җыенган бер җегет басып тора ие. Якын тирәдә ул кискән агачлар инде шактый ие. Чибәр җегет ие ул. Иңнәре киң, беләкләре юан. Озын буйлы. Ә күзләре… Әле менә шул күзләр яфраклар арасыннан күренгән сыман булды.

Нәгыймә апа, авыр сулап, тынып калды. Аннары:

— Нәгыйм атлы җегет ие ул, — дип дәвам итте. — Бездән ерак түгел генә торалар ие. Бик гайрәтле, бик йөрәкле, уңган җегет ие.

— Шундый матур имәнгә кулың ничек күтәрелә, ә, Нәгыйм? — дидем мин. Ничек телем баргандыр инде. Әти миңа коры гына карап куйды, җегеткә сүз кушуны ошатмады бугай.

Җегет, елмаеп:

— Калсын алайса. Үсә бирсен, иеме. Бигрәк төз, матур шул, — диде.

Без киттек, ул бик озак артыбыздан карап калды. Бу имән, без кире кайтканда, вак агачлар уртасында, матурлыгы белән сокландырып, берүзе утырып торае. Мин шатлыгымнан нишләргә дә белмәдем. Тыңлады бит җегет сүземне, тыңлады… Тора-бара без аның белән качып кына очраша башладык... сөешеп киттек. Шулай килеп чыкты инде, олан. Шушы имән кавыштырды безне. Нәгыйм имәне. Бер-ике кат шушы имән янына да килеп чыктык әле. Ул бу имәнне «Нәгыймә имәне» дип атаган ие. Кисмә, дигәнгәдер инде... Ярата ие шул ул мине, бик ярата ие.

— Ә син үзең, Нәгыймә апа? Үзең?

— Үзем дә инде. Һи, ул чаклар… Язгы ташу булып килеп керде ул минем тормышыма… Бермәлне мин авырып киттем, янына бара алмый тордым. Ул мине сагынып җыр чыгарган.

— Җыр?

— Ие. Миңа да өйрәтте.

Биектәгенәй тауның, һәй, түбәсе,
Ат чаптырып кына менәсе.
Җанкай-җанаш бик нык сагындыра,
Сагынуга ничек түзәсе.

Биектәгенәй тауның башларына
Колмак утырттым ла, үрләсен.
Кавыша алмабыз, дию еңне оныт,
Сүзең кабул була күрмәсен.

Биектәгенәй тауның, һәй, чишмәсе,
Агадыр ла көмеш сулары.
Төшләремдә китеп югаласың,
Үзәк өзә менә шулары.

Шундый сагышлы-моңлы җыр ие ул. Йа Ходa, җыры калды, имәне калды, үзе юк булды.

— Юк булды?

— Үтерделәр аны… Калхуз кора башлагач, ул да әйдәп йөрде. Аның гайрәте, аның йөрәге беләнме… Һи! Арба кендеге белән башына сукканнар. Төнлә, сагалап торып. Шуннан игә килә алмады инде ул… Минем җылаганнарым ул чакта… Мине дә үзең белән алып кит, дип. Җир тырнап җыладым. Күгем ишелде… шулай итеп… Ул китте, истәлеге итеп менә урман калды, шушы имән калды, наным.

* * *

Нәгыймә әби белән урманда шул очрашудан соң күпме сулар аккан, күпме гомер узган инде. Ул үзе дә менә гүр иясе булган. Авыр туфрагы җиңел булсын мәрхүмәнең. Теге очрашудан соң ул миңа гел июльдә үк саргаеп киткән яфракны хәтерләтә иде. Була бит шулай. Табигатьтә яшел җәй гөрли. Ә агачта бер-ике яфрак бите саргаеп, моңаеп утыра.

Аның хакында, нишләп шундый киң күңелле, тыныч холыклы кеше башлы-күзле булмады икән, гомерен ялгыз уздыра икән, дип сөйләгәннәре хәтеремдә. Ә мин аның серен белә идем.

Сугыштан соң кайсы елныдыр Нәгыймә әбигә күрше авылдан Мостафа абзый килеп сүз каткан, дигәннәр иде.

— Ялгызлык бик авыр икән, Нәгыймә. Менә берүзем калдым, — дигән, имеш.— Хатыным дөнья куйды бит әле. Балаларымның икесе фронтта үлеп калды, кызларым, очар кошлар таралып бетте. Хуҗалыгым начар түгел. Үзем эчмим, тартмыйм. Әллә, мәйтәм, ояларны кушыйкмы? Арканы аркага терәп, җылынып ятырга да кешегә кеше кирәк ләбаса.

Нәгыймә әби Мостафа абзыйны, өенә алып кереп, мәтрүшкәле чәй белән сыйлаган, аннары алар бик озак сөйләшеп утырганнар. Агайның эше пеште, дип, елмаешып торган яшь җилбәзәкләр, кунакның җил капканы җентекләп ябып китеп баруын күргәч:

— Нәрсә, Мостафа агай, әллә килен туйга хәтле кайтып торырга куштымы? — дип, авызларын ерырга теләгәннәр икән дә, агайның гаять дулкынланган йөзен күргәч, урынсыз шаяруларыннан тынганнар.

Мостафа абзый:

— Әй, оланнар, саескан бүтәкәсе санап җөрим икән лә мин. Яшьли биргән антымны гомергә бозмадым, хәзер инде бигрәк тә, диде. Ачуланма, диде… Менә шундый хәлләр, — дип, болай да төзлеген югалта төшкән җилкәләрен авыр кыймылдатып, авылына кайтып киткән. Димәк, Нәгыймә әби серен аңа да чишкән икән…

Әйе, яшьлек мәхәббәтенә тугры калган, берне генә сөйгәннәр азмыни бу дөньяда! Һәм моның өчен кем кемне гаепли ала? Урман Нәгыймә әбигә яшәргә көч биргән, изге ябалдаш имән аңа Нәгыйме белән кавышу урыны булган лабаса! Олы мәхәббәтеңә тугры калган өчен зур рәхмәт сиңа, Нәгыймә әби! Учыңдагы бакыр балдагың кем истәлеге икәнен мин беләм инде хәзер. Урының оҗмахта булсын!

# Шундый улың булгач

Ул! Бу дөньяда әле бернинди гаме булмаган кызгылт җан иясен күпме көтте Нәфыйк. Туенының икенче көнендә үк, чем-кара мыегын бөтерә-бөтерә, Сәлимәсенә әйтеп куйды:

— Син, матурым, миңа башта малай табып бирерсең инде, җәме.

Сәлимә көттермәде, вакыты җитү белән тапты. Кыз бала. Малай түгел. Бала табу йортыннан кайтканда, ул, башын түбән иеп:

— Без көткән ир бала булмады бит, ачуланма инде, — диде.

Нәфыйк хатынының яулыгы кебек ак, сулыгып калган йөзенә карап торды-торды да, кытыршы куллары белән битләреннән сөеп, шап иттереп үбеп алды. Күңелендә кинәт наз дулкыны йөгереп узгангамыдыр, аның йөрәге кысылып куйды.

— Дөньяга яңа кеше килде, җаныкаем. Үз бәхете белән. Ә син... ачуланма, дисең. Бәйрәм ич бу. Малай да булыр әле. Башлыйбыз гына. Үзеңне-үзең ашама әле син, — диде ул.

Сәлимә, татар хатыннарына хас гүзәл, табигый тыйнаклык белән:

— Җә инде, кеше күрер, — дип, тирә-ягына каранып алды, ә үзе шулай да башын иренең иңенә салды. Кеше гомерендә бик сирәк була торган, аеруча бәхетле, һәр күзәнәгеңне сулкылдатып, барча дөнья мәшәкатьләрен оныттыра торган изге, бик рәхәт мизгел иде бу.

Башлаган эш дәвам итте. Тупырдап бер-бер артлы дөньяга кызлар килә торды, үсә торды. Беренчесе, Галия, мәктәпкә дә барып керде. Тугыз класс белем алып, күрше авылдагы урта мәктәптә дә укый башлады. Аның артыннан башкалары да тартылды. Тик менә малай һаман юк та юк иде. Барган саен, бала табу йортыннан Сәлимә, иренә күтәрелеп карарга оялып, әллә нинди гаепле кеше кебек кайтты. Аңа әкренләп ир уртасы булып җитешкән Нәфыйк белән күпме өметләнеп йөргән көннәре тагын бушка, әрәмгә киткән кебек тоела иде. Ул күңеленнән Нәфыйгы суынып китмәсен дип тә шикләнә иде. Әнә ич беркөнне тегесе:

— Әллә син, Сәлимә, ни... ята белмисеңме? — дип ычкындырды. — Кыз да кыз...

Сәлимә тыгыз, мул күкрәкләре белән Нәфыйкның кочагына тагын да кысылыбрак керде дә:

— Ничек ятсаң да, аның урыны бер инде, — дип куйды...

Ниһаять! Зарыгып көткән ир бала! Аның улы! Улы!

Малай, апалары сыман нәзберекләнеп, җәйге матур көннәр җитсен дип тормады, 30 градус салкын гыйнвар иртәсендә дөньяга көр аваз салды. Әнисенең бала табу йортына баруын да көтеп маташмады.

Ул көнне Нәфыйк, кендек әбиенә мул итеп «әҗерен» биргәч, чатлама суык булуга карамастан, йомыш табып, авылның үзидарә бинасына яланбаш барды. Юлда очраган авылдашларының аптырашлы сорауларына җавабы да кыска булды:

— Бүрекне киеп, малай урамга чаңгы шуарга чыгып киткән лә!

Нәфыйкның түбәсе күккә тиде, Сәлимә дә бик нык шатланды, кызлары гөр килде. Әти кеше хатыны малай тапса, бүләк итәрмен дип, әллә кайчан алып куйган, кат-кат кәгазьгә төреп, печәнлектәге коргак-

сып таралырга торган мичкәдә, иске-москы аяк киемнәре астына яшереп тоткан бәрхет күлмәклекне китереп тоттыргач, Сәлимә шатлыгыннан елап та алды.

Туган-тумача, күрше-күлән:

— Ну, абзыкай, тәки булдыргансың икән! Малаең нәкъ үзең инде менә, өзелгән дә төшкән! — дип мактаган саен, Нәфыйкның авызы колакка җитә иде. Йөзендә язгы кояш балкыган ата атна буе бәйрәм итте. Малае белән котлаган дус-ишләрен, котламаган кешеләрне дә, хәтта аңа ни өчендер үпкәләп, тырт та пырт сөйләшеп йөргән салпык авызлы, үпкәчән Гыйбадулланы да өенә өстерәп керде.

— Әйдә, миннән булсын яхшылык. Абыстайский, минем егетнең тәпиен юып алыйк әле, — диде ул.

— Менә син, Нәфыйк, үзең олы кеше бит инде. Шулай да, балалар шикелле, кушамат белән дәшәсең, — дип, тегесе шунда ук үпкәләп өлгерде. — Соң син мине уважайт итәсеңме?

— Гыйбадулла, җаныкаем. Ул кушаматны мин кушмадым лабаса. Син бигрәк тә гарьчән инде. Кушкан кеше синдә хатын-кыз чалымнарын тапкандыр, күрәсең. Әйдә, ярар, күтәреп җибәр тагын берне минем егетнең исәнлегенә, — диде Нәфыйк.

— Бәхеттә коенсын! Хуш.

Гыйбадулла тозлы кыярны шулхәтле шекерт-шекерт тәмле иттереп чәйнәде, Нәфыйк, түзә алмыйча, авыз суларын йотып, тагын бер чәшке утлы суны чиратсыз гына каплап куйды.

— Рәхмәт, малай, шәп булды әле бу, — диде кунак, — буыннарга ук таралды. Әйдә, булмаса, тагын берне кой әле. Әнә анда минем хатын да чамалап йөри. Кыз бала көтә бугай. Бәлкем, кодалар булып куярбыз, Ходай кушса, дим. Әйе...

— Юк елганың юк тегермәнен тарттырып утырма әле, җәме, кем, Абыстайский!

— Менә тагын кушамат.

— Минем малай синең булачак кызыңа өйләнсә, бетте инде аннары. Гел үпкәләшеп йөрергә кала. Синең кыз минем малайга борынын сузмасын инде, җәме. Безнең пәриләребез туры килми.

Эчке тун җылысыннан шактый җылынып өлгергән Гыйбадулла, бу сүзләрдән шактый гына сыны катып торгач, нидер әйтергә авыз ачкан иде, кинәт урамнан хатынының: “Кая олакты бу Гыйбат. Өйдә кырык эш кырыкка ярылып ята!” — дигәнен ишетүгә, син күр дә мин күр, тиз-тиз генә чыгып йөгерде. Нәфыйк, моның чөе бушады, дип көлеп калды.

Менә шулай улының тәпиен юып аргач, Нәфыйк пыяла самавырга бүтән кагылмаска булды. Тәмәкесен дә ташлады. Дус-иш көлештергәндә, ул, ара-тирә ак бөртекләр төшкәләгән матур мыегын сыпыргалап, бер генә җавап бирә иде:

— Шундый улың булгач... Күреп калуы бар... Ярамый, парин.

Әти-әнисен күргәч, бишектә «ыггы-ыгы» дип сөйләшеп яткан кызлар очына-очына елмая иде. Малай алай вакланып тормады, тик кенә уйланып ята бирде.

Сәлимә бермәлне:

— Нәфыйк, карале, бусысы ник елмаюга бик саран икән, ә? — дип сорады.

— Яланбашның языгы юк, диләрме әле? Егет кеше юк-барга тешсез авызын ерып тормас ул, шулаймы, улым? — диде Нәфыйк. — Тилемсә түгел ич ул. — Аннары бик озак итеп бала арбасы янында улының йөзенә текәлеп торды. Малайның чокырланып торган битләренә, ал иреннәренә, алга бүлтәеп чыккан үзсүзле иягенә карап торганда, атаның йөзендә үзенә бертөрле ләззәтле, бәхетле хисләр нуры уйный иде.

— Аһ, шельма. Җокың да сандугач җокысы гына. Рәхәтләнеп җоклыйсы урында, әллә нәрсә уйланып ятасың бит, ә! — дип, улын ачулангандай итте.

...Нәфыйк тансык улын, кая бармасын, нишләмәсен, үзенә ияртергә тырышты. Улы үсә төшкәч, мунчага да аның белән керә башлады. Бер мәртәбә Сәлимәсе:

— Син нишләп болай итәсең әле!.. Арканы җуарга кирәкми башладыммы әллә? — дип сүз кушкан иде, ире:

— Шундый улың булгандамы?! — дип кенә җавап бирде.

Салихҗан ай үсәсен көн үсте, таза, төз гәүдәле, әтисе кебек, сирәк кенә елмайганда җанны эретә торган яшүсмер булып өлгерде. Кулыннан эш килүе тагын. Утын кисү, терлек-туар карау дисеңме, идән юу, табак-савыт тазарту кебек хатын-кыз эшеннән дә йөз чөймәде. Әтисенә ияреп, трактор сүтепҗыярга өйрәнде.

Бердәнбер улына Нәфыйк абзый юмарт булды. Салихҗан, авыл малайларының күзен кыздырып, вилсәпидтә, матайда йөрде. Алтынчы сыйныфта укыганда ук кызлар озатып йөри башлады.

Ә чаңгыда йөрүен күрсәң иде!

Бервакыт, мәктәпнең иң яхшы чаңгычысы буларак, аны бер-ике укучы белән район үзәгенә ярышка җибәрделәр. Яшьтәшләрен бик күп артта калдырып, Салихҗан яшь боландай алга чапты. Һич көтмәгәндә районның беренче чаңгычысы исемен алып кайтты. Өйдә аны сабан туе батырын каршы алгандай каршыладылар. Кичен аш артында Сәлимә улына сөеп карап, тел очында бөтерелгән сүзен ычкындырды:

— Үсеп җиттең бит, улым. Без инде кирегә китә башладык. Әнә этиеңнең мыегы ап-ак булды. Картайган көнебездә ышаныч синдә инде, Алла боерса, — диде ул.

Нәфыйк абзый улының җавабын көтеп тормады, горур гына:

— Һәй, юкка борчыласың, энисе. Шундый улың булгандамы! — дип, хатыны сүзенә нокта куйды.

Салихҗан урта мәктәпне алтын медаль белән бетерде. Чыгарылыш кичәсеннән кайткан иртәдә этиэнисенә:

— Мин Казанга мәдәният институтына укырга китәм. Анда артистлар да хәзерлиләр, — дип шаккатырды.

— Судья буласың дип, кат-кат сөйләштек ич, улым. Бу тормышта хәзер гаделлек яклаучы кешеләр кирәк, — диде Нәфыйк абзый.

— Юк, артист булам. Мин моны хәл иттем инде, — дип, Салихҗан сүзне өзәргә кирәк тапты.

— Бу хәтле дә үзсүзле булырсың икән, — диде энисе. — Син үзең бозып бетердең аны, Нәфыйк, үзең, үзең. Һаман бер сүздән тәм таптың: шундый улың булганда, шундый улың булганда... Менә хәзер...

Салихҗан озак та тормый, имтиханнарын әйбәт кенә биреп, мәдәният институтына кереп кайтты. Аннары китеп тә барды. Әйбәт укыды. Телевидениегә барып, шигырьләр сөйләде, спектакльләрендә төп рольләрне уйнарга да өлгерде. Акча кирәгендә, кайтып, матур гына таләп итәргә дә өйрәнеп китте.

Баштарак улы сайлаган һөнәрне өнәп бетермәсә дә, Нәфыйк абзый тора-бара, улын телевизордан күргәндә яки берәрсе: “Салихҗан телевизордан сөйләде. Ай-һай, оста!” — дип мактый калса:

— Шундый инде ул, шундый, — дип кенә җибәрә иде.

Вакыт үтә торды. Салихҗанның институтны бетерер вакыты да якынлашты. Акчага дип кайткан көннәрнең берсендә этисе аңа:

— Улым, син инде олы юлга басарга торасың, — диде. — Ни бит... Безгә энкәң белән синең хозурга калырга вакыт җитеп килә. Башлы-күзле булу хакында кайгыртырга ие. Апаларың әнә, Ходайга шөкер...

Салихҗан этисенең сүзен тыңлап та бетермәде:

— Борчылма, эти. Мин өйләндем инде, — дип ярып салды. — Малаем да бар. Тик без бергә тормыйбыз. Ташладым мин ул хатынны. Уңмадым мин аңардан.

Нәфыйк абзыйның гомерендә беренче кат йөрәген утлы без чәнчеп алды. Авырту басыла төшкәч, кинәт хәлсезләнеп киткән аякларын сөйрәп өйгә кереп китте.

Иртәгесен ул, беркемгә берни әйтми, шәһәргә китеп барды. Ике көн буена Сәлимә апа аны көтә-көтә көт булды. Кулына эш бармаса да, әле шыкыр-шыкыр таба кырды, чыпырдатып су түгә-түгә, идән юды, кер үтүкләргә тотынгач, кулын пешерде. Ялгыш аягына басып, мәчене чыелдатты, шикәр комы урынына тоз кабып, чәй эчте. Әнә шулай ут йотып йөргән икенче көнне, кояш баер алдыннан гына, капкадан арыган-талчыккан Нәфыйгы кайтып керде.

— Йә, йә, сөйлә тизрәк! Кайда йөрдең? — дип каршы алды Сәлимә түти. — Синең арттан ук Салихҗан да китеп барды. Аны очраттыңмы? Бу ни хәл инде?! Бу ни галәмәт? Картаеп барган көнеңдә, ә, атасы! Рисвай итте бит бу, үзсүзле нәстә. Әбәү, синең чәчең артык агарып киткән түгелме соң?

Нәфыйк абзый, кулын селтәп:

— Әй, улың шундый булганда, — дип кенә җавап кайтарды да, өйгә кереп, караватка ауды. Утлы без аның йөрәген янә тишеп керде, ялкыны бөтен күкрәккә таралды. Күз алдында Салихҗанның сурәте бер яктырып, бер караңгыланып, шадраланып торды да аннары, мең кисәккә таралып, әллә кая сибелде.

Нәфыйкны район үзәгендәге шифаханәгә салып кайткач, Сәлимә түти иренең пинҗәген шкафка элеп куйган чакта, аның күкрәк кесәсеннән бер фоторәсем килеп төште. Аннан шомырттай кара, тумраеп торган зур күзләре белән, дөньяга исе китеп, ике-өч яшьлек ир бала карап тора иде. Ә рәсем артына хатын-кыз кулы белән алга атлыгып, бер-берсен узарга ашыгып торган йөгерек хәрефләр белән:

— Дәү этием белән дәү әниемә улыгыз Ринаттан, — дип язылган иде.

# Гөнаһ шомлыгы

— Көш, чукынган Галимәләр тавыгы!

Әх, шушы сүз әйтелмәгән булса! Әйтелде шул, Мәрфуга әбинең теленнән ычкынды. Ычкынды да гомерлек дуслыкны, ямьле тормышны чәлпәрәмә китерде. Ни өченме? Чөнки моны бит күршесе Галимә карчык үз колагы белән ишетте. Кеше әйтсә, ышанмас та иде. Ишегалдына чыккан җиреннән яңа уган кер тутырган табагы тузанга төшеп капланды. Ашарга өметләнеп аягы тирәсенә йөгереп килгән тавык-чеби куркып тирә-якка сибелде. Болдырда язгы кояшта изрәп яткан мәче, картлыгын да онытып, чыелдап, баганага сикерде.

Үз колагына үзе ышанмыйча, сыны катып, тораташтай шактый озак басып торгач, Галимә әби күзләреннән мөлдер-мөлдер яшь акканын тойды. Аның колагында күрше Мәрфуга тавышы һаман яңгырап тора иде.

— Көш, чукынган Галимәләр тавыгы!

Әйе, әйе, гомер буе чөкердәшеп кенә яшәгән күршесе Мәрфуга түти ул хәерсез көнне нәкъ шулай диде шул: чукынган Галимә, диде. Чукынган! Белә Галимә түти чукынуның нәрсә икәнен, белә. Урыс авылларыннан үткәндә, марҗаларның чиркәү түбәләрендәге теге нәрсәләргә карап ни кыланганын күп күргәне бар. Тик ул менә үзенә, биш вакыт намаз калдырмаган кешегә, шулай чукынган диюгә ничек түзсен!

Шул көннән Галимә түти күршесенә бик суынды. Үпкәләде, хәтта рәнҗеде ул аңа. Рәнҗетерлек тә шул! Чукынган, имеш. Кешене шулай рисвай итәргә ничек теле әйләнде икән ул Мәрфуганың. Ни йөзе белән очраган саен хәл сорашкан була. Әле чәйгә дә дәшеп маташа. Имеш, каладагы кызы бик тәмле сәйлүн чәе җибәргән. Кипкән кавын, әфлисун, лимон... Юк инде, моннан соңмы! Моннан соң Галимә түти ул Мәрфугалар ягына ике аягының берсен дә атламаячак. Сәйлүн чәе димәгәе! Әнә ләбаса, аның да калада уллары-кызлары бар. Ике атнаның берендә кайтып-килеп, бал-маен, прәннек-кәнфитен ташып кына торалар. Тавыгын, йомыркасын ул үзе дә мул биреп җибәрә. Шәһәрнекеләр аңа яз көне үк инкубатордан чебешләр алып кайталар, ә Галимә түти аларны үстерә тора, суйдырып биреп җибәрә тора. Кибет тавыгы түгел шул, үзең үстергән тавык ашын авызыңа капсаң, телең йотарсың. Яңа суйган тавык итен тешең белән кыскач, аның сутының тәмлелекләре, аның хуш исләре!

Әле менә бүген дә аның улы Фәтхетдин машинасын гөрелдәтеп кайтып төште. Әнисен кочаклап битеннән үпте. Оныгы Роберт әнә виноград, әлү кагы, өрек җимеше, вак җимеш, тагын әллә нәрсәләр тутырылган ничәмә-ничә пакет күтәреп керде. Тәмле кала ризыклары белән бөтен өстәл тулды.

— Әйдә әле, әни, самавырыңны куеп җибәр. Самавыр чәе бик эчәсе килә! — дип, улы ап-ак күмәчләр, булкалар, печеньеләр дә бушатып куйды. — Нихәл соң, әни? Ару гына тордыңмы? Күрше Мәрфуга әби нихәл? Авырмыймы?

Менә шундый инде аның балалары. Кайткан саен, барын да сорашып кына торалар. Күрше-күләнне дә күчтәнәчсез калдырмыйлар.

— Әни, Мәрфуга әбине Роберт чәйгә чакырып чыксын әле, әйеме? Роберт, бар, улым!

Моны ишеткәч, Галимә әбинең йөзе зыярат ягыннан килә торган болыттай караңгыланып китте.

— Җук инде, улым, җук, — диде ул. — Гомер гафу кылмаслык рәнҗетте ул мине. — Мәңге ризабәхил түгел мин аңа.

— Тукта әле, әни, нәрсә булды? — Фәтхетдин аптырап калды.

— Миңа, чукынган, диде бит ул. Әлгаязе билләһи.

— Әни, аңлатып бир әле. Әллә берәр хәл булып ачуланыштыгызмы? Гомердә булмаганны? Ә?

— Көш, чукынган Галимәләр тавыгы, дип разбуй салды. Мине чукынган дияргә! Өемә урыс атлап кергәне җук. Үземнең дә урыс бусагасын атлап кергәнем җук. Шушы яшемә җитеп...

— Керсәң нәрсә булган ди. Аның ни гаебе бар? Әни, аңлат әле, зинһар.

— Суң, минем почмагымда сын тормый лабаса. Мине чукынган дияргә!

— Һәй сезне, картларны. Көш, чукынган, Галимәләр тавыгы, дигәндә, ул сүзне өтер куеп әйттеме?

— Нинди өтер, нинди өтер! Чукынган чукынган бит инде ул.

— Соң, өтер куеп әйткән булса, сиңа әйтмәгән була ич ул. Тавыкны ачуланып әйткән була.

— Ничек алай?

— Шулай инде. Тавыкка ачуы килгән, димәк.

— Тавыкка дип. Һе...

Фәтхетдин, әнисенең шикләнеп калганын күргәч, көлмәскә тырышып, ишекле-түрле йөрде дә, күрше Мәрфуга әбиләргә кереп китте.

...Парларын пошкырып утырган самавыр янында көлешә-көлешә кала ризыклары белән чәй эчкәндә, Мәрфуга түти күршесеннән кабат-кабат гафу үтенде.

— Сиңа әйтәмме соң инде мин шул сүзне, Галимә, ә? — диде ул. — Тавыкларың чөгендер чәчкән түтәлемне аркылыга-буйлыга тырнап бетергәннәр ие. Менә бит, гөнаһ шомлыгы. Телемә кырмавык шикелле ябышкан шул тәмсез сүздән һич котыла алмадым инде. Моннан соң... телем корысын шул чукынган сүзне әйтә калсам! Ә-ә? Әстәгъфирулла тәүбә, әстәгъфирулла тәүбә! Тагын ычкынды. Ходаем, үзең ярлыка...

# Яңабаштан

(*Юмористик хикәя*)

Гатаулла абзыйның, ни генә сөйләмәсен, әллә каян «яңабаштан» дип китереп кыстыра торган гадәте бар. Аптырады инде, үләт еккыры, шул кирәкмәгән чүп сүз аркасында. Бөтенләй көтелмәгән урынга шул «яңабаштан» килеп кысылгач, тыңлаучылар кычкырып көлеп җибәрә.

— Еллар уза, без картаябыз, энем, яшьләр үсә, яңабаштан. Менә күрше Гыйльметдин кызы әле кайчан гына яланаяк тәпили иде, хәзер, күрәсең, үзенең дә баласы туган, яңабаштан. Бәхете белән тусын инде, яңабаштан.

Моны ишеткән яшьләр көлми ничек түзсен ди инде.

Үзенең тагын теге сүзне кыстыруын чамалагач, Гатаулла абзый кинәт туктап кала, аның чал кашлары бергә килеп кушыла, аннан ул, көрсенеп, тамырлары бүртеп торган кулын селтәп, сүзен дәвам итә.

Тора-бара Гатаулла абзыйның теленә терлек йонына кырмавык кебек ябышкан бу сүзенә авыл халкы ияләшеп тә бетте. Ә менә чит кеше…

Бер мәртәбә болай булды. Гатаулла абзый күптән инде йортны яңартырга йөри иде. Күмәк хуҗалык аңа менә дигән юан-юан нарат бүрәнәләр дә, түбә ябарга өр-яңа шифер плитәләр дә кайтартты, ә менә балта осталарын бушата алмады. Инде барысы да әзер, эш башларга кирәк дигәндә генә, балта осталары ашыгыч төстә амбар сала башладылар. Күмәк хуҗалык рәисе Шәфәгат Сәлимов:

— Бераз көт, Гатаулла абзый, амбардан соң синең йортыңа тотынырбыз, — дисә дә, Гатаулла абзый риза булмады. Җәйнең матур көннәре санаулы гына калып килә дип, күрше авылдан балта осталары эзләргә китте.

Берничә көннән иске йортның тузанын җил тузгытып ташлады, нарат бүрәнәләр чутланып яшел чирәм өстенә сузылып яттылар. Эш шулай уңай гына барганда, беркөнне Гатаулла абзыйлар янына Сәлимов машинасы килеп туктады.

— Оят булса да сине борчырга туры килә инде, Гатаулла абзый, — диде ул. — Ындыр табагында эшләүче Нәфикъ авырып китте бит. Алыштырырга кеше юк. Ул терелгәнче генә булышып тормыйсыңмы?

Шундый үтенеп сорагач, олы кешенең сүзен ничек кире кагасың инде. Сәлимов үзе бит. Аның авылдашларына эшләгән яхшылыгын әйтеп бетерерлек түгел. Бер генә кешене дә кире борып җибәрми. Кыскасы, Гатаулла абзый риза булды. Осталар да каршы килмәделәр.

— Менә тагы, кирәк икән, бар, үзебез генә дә булдырырбыз, — диделәр.

Гатаулла абзый, салына башлаган йорт эшләрен ташлап, ындыр табагына йөри башлады. Аннан ул, төш җиткәч, капкалап алырга гына кайта иде.

Кайткан арада осталар янына килеп, аларның хәлләре белән кызыксына. Тегеләр аңа эшләгән эшләрен күрсәтеп йөргәндә, Гатаулла абзый:

— Тәрәзә төпләрегез яхшы булган, яңакларын да шулай матур эшләсәгез, яңабаштан, — дип кыстырып куя.

Мондый сүзләрдән соң ул осталарның йөзләре нигәдер караңгыланып киткәнен тойгалады. Элек-электән сәер бу халык, дип уйлады ул эчтән генә, син аларны мактыйсың, ә аларга бу нигәдер ошамый. Үзләре сүзгә дә саран, җитмәсә.

Иртәгесен осталар тәрәзә яңакларын көзгедәй шомартып бетергәндә, төш җитә. Гатаулла абзый аларның эшләреннән бик канәгать кала.

— Менә булган. Түшәм такталарын да шулай тигез, матур итеп шомартсагыз, яңабаштан.

Кичкә кадәр осталарның бөтен вакыты түшәм такталарын кабат шомартырга китә.

Тора-бара алар Гатаулла абзый белән бөтенләй сөйләшмәс булдылар. Моңа кадәр осталарның һәрнәрсәне җентекләп, кат-кат эшләгәннәренә шатланып йөргән Гатаулла абзый аптырап калды.

Бер кичне келәттә йокларга яткач:

— Әллә син аш-суыңны кысан тотасыңмы, яңабаштан, кеше тиктомалдан шулай итенмәс иде, — дип, хатыны Галимәгә бәйләнде.

— Ату син мине белмисең. Гомер-гомергә кешегә дәүләтемнән берни жәлләмәгәнне, бүген генә саранланып торырга… Теге утлы савытларыңны азсыналармы икән әллә? Әйттем мин сиңа, алларына яшшиге белән куй, дип. Бөтен районда мәсхәрәгә каласың килде, күрәсең. Авылларына кайткач, кырмыска Гатаулласыннан да карун кеше юк икән, дип сөйләп йөрүләре дә бар әле.

Таякның юан башы үзенә төшүен күргәч, Гатаулла абзый ярсып ук китте:

— Юкны лыгырдап ятмале, яңабаштан. Ничек келәделәр, шулай куям. Мине районда белмиләрдер шул. Кырмыска Гатаулласы, диләр аны. Тукта әле, мин бүген төшкән килен түгел ләбаса. Тел яшереп торырга, — диде ул. Һәм дәфгатән торып эчке күлмәк-ыштаннан гына күршеләренә кереп китте. Балта осталарына ятакны алар күрше Сәгыйтьләрнең өйалдына түшиләр иде.

Галимә түти:

— Башта киен, ичмаса, — дип, артыннан кычкырып калса да, әллә ишетте, әллә ишетмәде.

Хатын: «И Ходаем, тавыш-гауга чыга күрмәсен тагын», — дип, урыннан торып, күлмәген киеп маташкан арада, Гатаулла абзый әйләнеп тә кайтты. Аның аптыраган йөзенә күз салгач, Галимә түти бөтенләй шомлана калды.

— Нәрсә булды? Иртән өлгермәс идеңме? Арып йокыга киткән кешеләрне бимазалап йөрмәсәң? — диде ул.

Гатаулла абзый, актан-карадан берни дәшмичә, акрын гына урынына барып ятты.

— Ник эндәшмисең? Әллә телеңне йоттыңмы?

Гатаулла абзый, бик озак дәшми яткач, хатынының аптыратуыннан туеп:

— Киткәннәр алар, яңабаштан, — дип, юрганын аяк астына тартып китерде. Аннан кинәт сикереп торып, мендәрдән нидер эзли башлады. Ниһаять, мендәр тышына кадалган кечкенә генә, нечкә генә бер йомычка табып, аны бөтен көченә селтәнеп, ачу белән читкә ыргыткач, борылып ятты да күзен йомып уйга талды. Күрше Сәгыйтькә осталарның: «Мондый бәйләнчек кешене беренче очратабыз. Бөтен эшне кат-кат эшләтә», — дип зарланганын ул хатынына әйтмәде.

…Иртәгесен кояш чыгып килгәндә, ул күрше авылда иде инде.

…Балта осталары шаркылдап көлә-көлә, аның йортын бик тиз өлгерттеләр.

Гатаулла абзый яңа йорт болдырында аларны:

— Кулыгыз алтын икән. Рәхмәт яусын сезгә, яңабаштан, — дип озатып калды.

# Туган көн

Ул бүлмәгә ике кулы белән дә биленә таянып килеп керде. Кунаклар белән кул биреп күрешкәндә дә, аның сул кулы билендә калды.

Күрешеп бетергәч, сәгатенә күз төшереп алды да:

— Утырабыз, зар-интизар булып көтәбез, дисез инде. Көтегез, сүнекләнеп, көтегез, — диде ул, шарык-шарык көлеп. — Мин үзем эшне сузарга яратмыйм, гаепләмәссез. Шуңа да миңа реаль карашлы Раил, диләр, — дип, өстәлдәге ризыклар өстенә ябылган зур тастымалны ачып җибәрде.

— Oho-ho-ho! Бар монда хәлләр!

Егет, кыска бармаклы кулларын угалап, өстәлдәге нигъмәтләргә тагын бер кат күз йөртеп чыкты да турап куйган кызыл балыкның зур бер кисәген алып авызына капты. Кунакларның күбесе моны уенга санадылар бугай, көлешеп алдылар. Авызындагы балыкны чап-чоп чәйнәп йоткач, ул сүзен дәвам итте:

— Менә, ә сез көтеп утырасыз…

Аннары, әллә кайчангы таныш сыман, миңа күз кысты да бик җитди кыяфәт белән аңлатырга кереште:

— День рождениега, реаль күзлектән караганда, гел соң җыелалар. Эш көнендә бигрәк тә. Көтеп утырмас өчен, мин үзем, алтыга чакырсалар, җидегә барам. И еш кына как разга туры килә. Соңга калган булсаң, шәпләп «штрафнойны» әйләндерәсең дә бүтәннәрне куып җитәсең. Вакытны бушка әрәм итү — безнең заманда эшлексезләр фигыле, картларча әйтсәк.

— Раил кемне шулай эшлексезлектә гаепли?

Моны кухнядан килеп чыккан хуҗабикә Гөлнара әйтте. Ә Раил туктамастан сүзне аңа борды:

— Менә синең Инсафыңны ачуланып торам әле. Тапкан вакыт туарга, понимаешь. Атна уртасында, эш көнендә тумаса, шимбә, якшәмбе ярамаганмыни?

Кунаклар елмаешып Инсафка карадылар, ә ул, уңайсызланып, кызарып китте. Гөлнара исә аптырамады, шундый ук тонда:

— Әй, туар алдыннан синең белән киңәш иткән булса бит, — дип көлеп җибәрде.

— Беләм инде, беләм, син Инсафыңа тел-теш тидермисең. Синең өчен ул күз өстендәге каш булды, понимаешь. Әле унынчы класста ук мин синең артыңнан ничек чаптым, якын да җибәрмәдең, — диде Раил. — Ә Инсаф бит башта минем булачак хатыным артыннан йөгерде.

— Минме? Булмаганны… Син әллә моны төшеңдә күрдеңме? — Инсаф, аптырап, тирәсендәге кунакларга карап алды.

— Йә инде, шаярам гына ич. Уен күтәрмисең син. Һаман элеккечә калдың, — диде Раил.

…Ниһаять, мәҗлес башланып китте.

Туган көне белән котлап, Инсафка матур-матур теләкләр әйтелде. Раил, һәр кеше сүзенә үзенекен — «иң кирәген» өстәп, мәҗлеснең күрке булырга тырышты. Рюмкасын да бик оста тотты, кыстатмады. Иреннәре янына гына китерә дә, башын артка ташлап, каплый да куя. Еллар буе өйрәнсәң дә булдыра алмассың.

Юбилярны күптәннән белгәнгә, дустымны котлап, теләкләремне әйтү нияте белән мин дә торып баскан идем, эшем кешесенең тагын бер тормышчан тәкъдиме туып өлгерде.

— Ашап-эчеп кенә утырмыйк әле, ял итеп алырга да кирәктер, — диде ул.

Минем сүз өзелде, кунакларга ияреп, Инсаф белән мин дә һавага чыгып киттек. Безне күргәч, башкаларга нидер сөйләп торган Раил безнең янга килеп басты.

— Менә шуны сөйләп тора идем әле. Вчю-таки, егетләр, день рождение уздыру — мәшәкатьле эш. Бүгенге кыйммәтле заманда бигрәк тә. Ә хатын-кызга хезмәте тагын.

Мин моңа каршы:

— Яраткан кешесе өчен кем мәшәкать дип тора инде, — дидем.

Болай да кысык күзен тагын да кыса төшеп, Раил, башын янтайтып, миңа төбәлде.

— Димәк, синең бәйрәм уздырганың юк икән, дус кеше, — диде ул.— Менә шушындый мәҗлестән соң савыт-саба юып кара әле син. Юк, егетләр, юк. Рәтең булып, день рождение уздырам дисәң, аны ресторанда эшләргә кирәк. Мин шундый фикергә килдем. Мәшәкате аз. Оркестры тагын. Магнитофон акырту йә гармунчыга ялыну түгел инде. Заказ яса да тыпырдый бир. Аннан соң — иркенлеге, парин. Биергә, мин әйтәм. Инсаф, син ачуланма, мин тормышка реаль карыйм, дип әйттем ич.

Инсаф, юк-юк, дисә дә, мин аның кәефе шактый кырылганын сиздем.

— Соңгы вакытта день рождениега төрле йорт кирәк-ярагы бүләк итү модага әйләнде, җитмәсә, — дип лыклыка сатуын дәвам итте Раил. — Әнә сиңа да кемдер кофе чәйнеге алып килгән. Реаль карaганда, сиңа аның ни пычагыма кирәге бар, шулай бит, парин?

Бу сүздән мин аптырап киттем, чөнки ул чәйнекне үзем алып килгән идем. Безнең тирәгә җыелган кунакларның берсе:

— Ник? — дип сүз кушарга ниятләгән иде, Раил аның авызын тиз томалады:

— Соң, егетләр, кибетләрдә хәзер ирләргә яраклы әйбер беткәнмени? Менә шушы Инсафка, кемдер алып килгән арзанлы люстра урынына, йә булмаса, кыек-мыек агачлар ясалган картина урынына импортный күлмәк бүләк итсәң, бу аның эчен тишәр идеме, ә? Ярар, Инсаф, ул күлмәк миннән булыр, яме. Минем бүген вакытым булмады. Иртәгә кертеп чыгармын мин аны. Мин сүземне җилгә очырганым юк әле. Киләсе туган көнеңдә өстәл башында мондый гади күлмәктән утырмассың.

Инсаф, сүзне уенга борырга теләп, нидер әйтергә омтылса да, уңайсызлануын яшерә алмады. Ул арада Раил сүзе кинәт икенче борылыш ясады.

— В убщем, парин, тагын бер айдан, 25 июльдә, белеп торыгыз, якшәмбе көнне сәгать кичке алтыда «Нәүрүз» ресторанына рәхим итегез. Мондый кысанда түгел, минем день рождениены шунда, иркендә уздырыйк әле. Барыгызны да чакырам, егетләр. Анда урын киң. Инсаф, син Илдарларны да калдырма. Ризамы, Илдар?

Тәкъдим капылт кына ясалганга, мин:

— Әлбәттә, барырбыз, — дип әйтми булдыра алмадым.

…Билгеләнгән көн тиз килеп җитте. Тик һич кенә дә аяк тартмый бит, барасы килми. Җиде ят ич инде ул безгә, дип, хатыным Разия дә шактый киреләнде. Бармасаң да ярамый, теге чакта ашыгычлык белән ризалык биреп ташладым. Бүләгеннән куркып килми калды, дип уйлавы бар. Сыртны җиргә тидерәсе килми. Нинди бүләк алырга дип борчылып йөрүләремне әйтеп тормыйм, ничек булса булды, хатыным белән без Раилнең туган көненә киттек.

«Нәүрүз» ресторaны төбендә безне чыраена сукыр лампа кабызып элгән Раил үзе каршылады.

— Ну, парин, болай килешми бит инде, көтә-көтә көт булам бит инде, бигрәк начар җыеласыз, — диде ул. Сәламебезгә дә җавап бирмәде. Мин кулымдагы «Харьков» электр бритвасын Раилгә тоттырдым. Ул аны әйләндереп-әйләндереп карады да:

— Рәхмәт. Вообще-то зря алгансыз, минем бар иде. Беләсезме, хәзер иң яхшы электробритва «Юбилейный» санала икән, — дип куйды.

Мин тагын юньсез эш эшләвемне абайлап, үз-үземне тиргәргә тотындым. Сатучыдан: «Хәзер бритваларның кайсы иң яхшы?» — дип сорарга башыңа килмәсен инде.

Кунаклар җыелып беткәндә, сәгать сигез тулды. Раил безне кат-кат санап йөрде дә әллә кая китеп югалды. Ә бераздан мин аны хатыны белән икәүләп, ике зур хуҗалык сумкасы күтәреп, баскычтан менеп килүләрен күрдем. Өстәл артына утыргач, ул, сагаеп, тирә-ягына каранып кына, сумкаларыннан зур кәстрүл, эчемлек шешәләре алып аяк арасына идәнгә куйды. Аннары Инсафка:

— Әйдә, парин, эшләп аша әле! — дип, өстәл өстендәге тәлинкәләрне бер тирәгәрәк җыярга кушты. Тәлинкәләр килеп тезелгәч, Раил аларга кашык белән кәстрүлдән салат бүләргә кереште.

Кунакларының гаҗәпләнүләрен күргәч, аңлатырга кирәк тапты бугай:

— Швейцар белән тарткалашып алдым әле, — диде ул. — Үзең белән берни дә алып керергә ярамый, ди, парин. Ни кабымлыгын, ни аракысын. Монда бары да бар, янәсе. Бар, кәничне. Биш бәясенә. Җитмәсә, тәмсез. Помидор-кыярның килосы базарда 20 сум торганда, монда бер-ике кашык әйберләре өчен 30 сум каерып яталар. Чуртан койрыгыннан акмый бит ул акча.

Хатыны аңа:

— Раил, син… — дип, нидер әйтә башлаган иде, тегесе аңа ирек бирмәде.

— Второй заказать иттем. Третийга чәй. Җимеш белән. Әйбәт ич инде. Без тормышка реаль карыйбыз, әйдә, ашагыз, дуслар, — дия-дия, тәлинкәләргә салат тутыруын белде.

Зур, озын өстәлдә буш тәлинкәләр янында 2—3 кенә шешә эчемлек күргәч, мин керүгә үк гаҗәпләнгән идем. Аның да җаен тапкан икән Раил. Өстәлдәге шешәләрдән рюмкаларга әз-мәз эчемлек салгач, аларны өстәл астындагы шешәләрдән тутыра башлады. Аннары:

— Йә, дуслар, беренче сүзне кемгә бирик? — дип, кунакларга мөрәҗәгать итте. Тик кунаклар, башларын аска иеп, бер-берсенә карарга уңайсызланып утыралар иде.

— Аңлыйм, ашыйсыгыз килә, озакка китте шул. Болай, иптәшләр… — дип, Раил яңадан сүзен башлаган иде, яныбызда гына утырган оркестр дөбер-дөбер музыка уйнап җибәрде. Раилнең бер генә сүзе дә ишетелмәс булды. Ул, аптырап, нидер сөйләп маташты да, безнең берни ишетми утыруыбызны күргәч, рюмкасын өстәлгә куеп, музыка беткәнен көтә башлады. Тик кая ул!

Безнең өстәлләр тирәсендә битен-күзен җитмеш җиде төскә буяган кызлар, майлы чәчләре җилкәләренә салынып төшкән аксыл йөзле малайлар боргалануларын белделәр. Моның очы-кырые күренмәгәч, Раил торып басты, кулы белән ияк астына чиертеп, тост күтәрергә ишарә ясады.

Шундый бер-ике тосттан соң безнең өстәл артындагы кунаклар да, берәм-берәм торып, биючеләргә барып кушылдылар. Гел тик утырмассың ич инде. Мин дә Разиямне ияртеп биергә чыктым. Бераздан күземә өстәлебез чалынган иде, аптыравымнан туктап ук калдым. Теге зур кәстрүл өстәл өстенә чыгып утырган һәм аның бер як тоткасыннан Раил, икенче ягыннан официант тотып тарткалашып торалар иде.

Раилнең бер яңагы тавык йомыркасы кадәр бүлтәеп чыккан — ул буш кулы белән авызына ашык-пошык салат тутыра, ә хатыны, битен куллары белән каплап, урындыкта утыра иде.

# Ялган түгел

(*Балыкчы зары*)

— Исәнмесез, егетләр! Чиртәме? Һе, шәп алайса. Ә мин берни тота алмадым. Ә? Нишлисең инде. Башыңа төшкәч… Балык сатучыгыз юкмы? Бик кирәк иде. Мәчебез бар безнең. Шуңа дип соравым. Свежий балык кына ашый. Бик нәзберек нәрсә. Кызым тапты инде аны, кызым. Телевизордан пеләш профессорлар, табигатьне яратыгыз, үсемлекләр, хайваннар дөньясыннан аерылмагыз, дип сөйләгәнне мин генә тыңламыйм шул, аны хатын да, кыз да ишетә. Көзен беркөнне кызым бәйләнә башлады:

— Әти (ул мине папа дип йөртә, берәр әйбер сорыйсы булганда гына әти ди), син миңа эт алып бир әле, ди.

— Кызым, — мин әйтәм, — без эш кешесе бит. Син дәресеңнән бушамыйсың. Кем карар соң аны? Урамда кем йөртер. Аны ашатырга, эчертергә кирәкме? Чистартып, юып торырга тагын!

— Син әнә ишегалдына күз сал. Бөтен кеше эт белән йөри. Урамга үзем алып чыгармын. Ашатуы, эчертүе — әнигә. Чистартуы синең эш булыр инде, — ди бу.

— Ай-һай, син, — дип каршы килергә теләгән идем, хатын авызымны бик тиз томалады.

— Син, папасы, — ди, — радиодан «Өлкәннәргә балалар турында» дигән тапшыруларны юкка гына тыңлыйсыңмыни? Кичә генә: «Балаларыгыз белән арагызны бозасыгыз килмәсә, сез, аларның үтенечен кире какканчы, башта уйлап карагыз», — диделәрме? Диделәр. Менә син уйлый тор, без Садрыйларга кереп чыгабыз. Аларның Джульбарслары балалаган икән.

Менә бит ничек кабыргасы белән куйдылар мәсьәләне. Нишләргә? Уйлана торгач, башка бер шәп уй йөгерде. Эт түгел, мәче баласы алырга кирәк. Мәче мәче бит инде ул. Үзе чыгып китә, үзе кайтып керә. Артыннан йөрисе юк. Үзең ашаганны ашый. Хәзерге этләр кебек нәзберек түгел. Кызыма шушыларны кат-кат сөйләп арып беткәч, тәки күндердем тегене. Мәче баласы алырга риза булды. Әнисе дә каршы килмәде. Тик гади мәче түгел, сиамский булсын, диләр. Югыйсә эт…

— Ярар, ярар, — мин әйтәм. Эчтән уйлыйм: аны тапканчы, гайрәтең кайтачак әле синең. Онытачаксың. Оныттырырсың, бар. Тапты бит. Ике көн дә үтмәде, кәкре койрыклы, кызыл-зәңгәр күзле, ала-кола бер мәче баласы алып кайтты да минем алга китереп салды.

— Әти, — ди, — бу гади мәче баласы түгел. Сиамскийныкы. Күрше подъездда торучы Людмила апаларның мәчеләре балалаган. Бәбиләрен саталар. Менә бусын мин сайлап алдым. 250 сум тора, диделәр.

— Ә?! Шушы әкәм-төкәмме? 250 сум! Кайсы юньсезе шулай алдый?! Бала дигәч тә!

Шулай дип пырылдап киткән идем, кызга тагын хатын кушылды:

— Беркем алдамый. Аның үз бәясе шулай. Кызың мәрхәмәтле, шәфкатьле булып үссен дисәң, аласың инде, — ди.

— Ата булса, риза, — дим. — Әнкә булса, кирәкми.

— Ник?— диләр болар.

— Соң, — дим, — эт асраган кешеләргә кергәч, авыр ис сизәсезме? Эт исе бит инде ул. Балалагач, аны чыгарып ыргытып булмый лабаса. Квартира эт оясына әйләнә. Мәчесе дә шул инде аның. Ә ата эт, ата мәче балаламый ул.

Шулай дигәч, кызымның гына түгел, хатынның да хәтере калды. Алар бер-ике көн салкынаеп, икәү генә сөйләшеп йөргәч, мәче баласының бәясен түләми чара калмады. Инде Ходайдан сорап йөрим —

ана гына була күрмәсен, мин әйтәм. Балалап ята башласа… Мәче баласын әйләндереп-тулгандырып карадым, аптырап беттем. Чебеш хәтле генә нәрсәнең атамы-анамы икәнен каян беләсең? Бермәл башыма бер уй килде. Мәче баласын саткан хатын beләдер, мөгаен. Кызым аны безгә чакырып чыкты. Килеп кергәч, күрше хатын башта кычкырып көлде.

— Шуны да белмәгәч, сез нинди ир кеше соң инде? Ата бу, — ди. — Менә карагыз. Шушыннан «әә» итәр. Менә монысыннан пес итәр. Күзәтегез.

Шатлыгымнан кунак хатынны шампан белән сыйлап чыгардым. Тик иртәрәк шатланганмын икән шул. Бераздан мәче баласының песе дә, кәкәе дә бер тирәдәнрәк чыга башлады. Кыскасы, ана мәче. Күрше хатынны эчтән генә тиргәп тындым. Нихәл итәсең? Акчасы түләнгән. Хатын белән кызым әнә ничек ияләшеп өлгерделәр. Итне дә ит тарткычтан гына чыгарып ашаталар бит үзенә, мур кыргырының. Баштарак, ата дип ышанып йөргәндә, Тихон дип атаган идек, ана икәнен белгәч, Ласкага әйләнде. Буталыш китте, тегеләр Ласка диләр, мин Тихон дим. Тормышның яме югалды. Кызым тегене, күтәреп кенә алып чыгып, куенында гына тотып, һава сулатып керә. Хатын әллә нинди боткалар пешереп ашата. Миңа исә… Әй, үзегез беләсез, сөйләсәң көлке инде. Беренче көннән үк яман эшкә ияләште, элгечтән минем эшләпәнең идәнгә төшкәнен көтеп кенә тора. Аны тазга, ком өстенә йөрергә өйрәтү минем өскә төште. Өйрәтүен өйрәттем анысы, һич ялган түгел, тик көн саен юеш комын түгеп, яңа комны табада кыздырып йөрүләре… Эх! Менә гарьлек кайда. Йөзе кара, ризыкны ничек талымлый! Әй үсте, әй тазарды.

Март тирәләрендә җенгә әйләнде бит бу. Аның чинаулары, аның диванны тырнаулары! Аннары үзебезгә бәйләнә башлады. Йөгереп килеп аякка ябышуы, тәрәзә пәрдәсенә асылынуы! Йокы да бетте, йокласаң, өскә сикереп уята. Мин төшендем моның хәлен. Хатын-кыз абайламый әле. Бик аптыраткач, кызым моны күтәреп, нәрсә булды икән, әллә авырый микән, дип, теге күршеләргә кереп китте. Бераздан күзләрен ялтыратып чыкты, әнисе белән пыш-пыш сөйләшәләр болар. Бераздан мәче тынуын тынды, тик корсагы кабара башлады. Ашавы тагын да нәзберекләнде. Свежий балык кына ашый. Тагын миңа бәла.

Хатын:

— Сиамский мәче мондый чагында свежий балык кына ярата икән ул. Кеше ирләре әнә балыкка йөри. Акчага сатып алып кая төткәзәсең моңа. Барып карар идең, кат-кат әйттем бит инде, — ди.

Аңа кыз да кушыла:

— Безнең папа телевизор карап ятудан бүтәнне белми шул. Балык тоту җиңел эш түгел икән ул. Кичә генә укытучы апа безгә бер пословица яздырды: «Без труда не вынешь и рыбку из пруда».

Гарьлек, валлаһи. Болайга киткәч, нинди ир йөрәге түзсен. Кирәк-ярак булдырып, әче салкын көннәрдә балыкка йөри башладым. Балыгы эләксә диген, ичмаса. Юк бит, юк. Көн буена кукраеп боз өстендә утыр да бармак буе бер балык эләктерә алмый кайт. Өйдә хи-хи да ха-ха. Аптырагач, теге сәгать кесәсенә маяга салган акчага балык сатып ала башладым бит, егетләр. Сырага дигән сумнарга. Шахмат уйнау бетте, сыра эчү бетте хәзер. Бөтен тынычлыгымны шул мәче баласы ашады бит, каһәр. Әй, очрасын иде юлымда теге пеләш профессор, очрасын иде. Хайваннарны яратыгыз, имеш. Менә нинди эт көненә калдым бит мин. Мәчесе дә югалмый, ичмаса. Әйдә, егетләр, менә шушы актык унбиш тәңкәгә балык бирегез дә, кайтып китим инде мин. Белмисезме, ул мәче халкы ничә бала китерә икән? Ә сезгә мәче баласы кирәкмиме соң, ә?

# Ач кешенең ачуы яман

(*Юмореска*)

Бермәлне хатынга төбәбрәк караган идем, аһ иттем. Кай арада шулкадәр уңган камыр кебек күпереп киткән соң әле бу минем бәгырькәем. Әле кайчан гына үкчәсе тигән җирдән очкыннар чәчрәткән Саимәм күлмәкләренең әле берсен, әле икенчесен киеп карый да: «Тагын яңа күлмәк тектерәсе була инде», — дип, диванга барып ава. Аяк киемнәре хакында әйтеп тә торасы юк: кайсы кыса, кайсының борыны тар, үкчәсе сыек. Үзе дә интегә, минем кесәне дә интектерә. Өстәвенә йә авыргалап китә, йә акчасыз ялга чыга. Шулай да чыдыйм. Эчтән тынам. Акчадамыни хикмәт, кешенең үзендә ләбаса! Саимәмдә. Әнә бит елмаюын оныта башлады.

— Кара әле, — дим, — Саимә, ни… син әз генә тазарып киттең бит әле, матурым. Күбрәк хәрәкәтләнергә, йөгерергә кирәк түгелме икән? Әллә бераз гына ашавыңны кысасыңмы? Газета-журналларда да ашаудан тыела белүне хуп күрәләр. Ябыктыру дарулары да хәзер бик күп, диләр.

— Бердәнбер хатыныңны ашаудан тыя башладыңмы? — дип күтәрелеп бәрелер дип көткән идем, юк, алай итмәде Саимәм. Тыныч кына:

— Үзем дә әллә кайчаннан сизеп йөрим, — диде. — Ризыкны сайлап кына ашарга кала инде.

Минем шатлыгым эчемә сыймады, кысыла башлады бит Саимәм. Итле-сөтле ризыклардан тыелды, каймак-кабартма өстәлгә бәйрәм көннәрендә генә менә торган булды. Өчпочмак-бәлешләрне төшләремдә күреп уянгаласам да, түздем. Пешер, дип бәйләнмәдем. Тора-бара токмач, пилмән кебек нәрсәләр дә юкка чыкты. Аның каравы алма, апельсин, мандарин, лимон, җиләк-җимеш табыннан төшми башлады. Җаен-кышын, язын-көзен. Мин күршеләр белән дуслашып киттем. Әҗәткә акча сорап кергәндә борып чыгармагач, ничек дус итмисең инде үзләрен. Саимәм күзгә күренеп ыспайланды. Бер-ике апельсин ашый да шалт итеп үлчәүгә менеп баса.

Ябыкты бит тәки. Бодай кумәче шикелле тулы битеннән бер кыерчык кына калды. Терсәк сөякләре яңадан калкып чыкты. Ул йөрешләрен әйтер идем, спортчы диярсең. Ирешүен ирештем мин максатка, тик Саимәмнең теле дә ябыкты димме, бик үткенләнеп китте. Әче әрем! Гомерендә тавышын күтәрмәгән хәләл җефетем утлы табага бастыра бит, әй! Тыпырдата гына! Җиләк-җимеше, апельсин-мандарины бетә башладымы, элеп ала, селкеп сала:

— Син, — ди, — мәнсез, саран, минем ашарыма ризык беткәнне күрмисеңмени?!

Мондый пешекләүләр күпкә киткәч, беркөнне түзмәдем, әйтә куйдым:

— Син, Саимә, — дим, — болай әче телле түгел идең. Әллә яратмый башладыңмы?

Әйтүен әйттем, тик ник әйткәнемә үкендем. Китте күз яше, китте тавыш. Зилзиләң бер якта торсын. Урамга чыгып ычкындым да, инде нишләргә дип, баш ватып йөрим. Шундый матур тормышыбыз нишләп болай бозылып китте соң, дип җаным йолкына. Уйлый торгач, таптым бит сәбәбен: ач кешенең ачуы яман, дигән бик тә мәгънәле сүзне онытып җибәргәнмен ләбаса! Җиләк-җимеш ашап кына торып кара, бар. Шул көннән соң мин әкрен генә Саимәмнән пәрәмәч, кыстыбый кебек нәрсәләрне яңадан пешертә башладым. Үзем ашыйм, үзем мактыйм:

— Авыз итеп кенә кара әле, — мин әйтәм. — Кулың алтын бит синең…

Әкренләп авыз итә башлады бит бәгыркәчем. Хәзер хатынымның күмәч кебек түгәрәк йөзендә яңадан елмаю балкый, өйдә шылт иткән тавыш юк. Менә бит, хикмәти Хода.

# Рәхмәт сезгә, егетләр

(«*Комсомольская правда*»*га рәхмәт хаты*)

Хөрмәтле редакция хезмәткәрләре! Исәнмесез, саумысыз! Сезгә бу хатны әлегә ялгыз яшәүче бер татар егете яза. Үземә 35 яшь әле тулды гына. Миңа сезнең «Су коену костюмы» дигән конкурсыгыз бик ошый. Мин әллә кайчаннан бирле, әле СССР яшәгән чактан ук, илнең бөтен почмакларын айкап, яшь кызларның фотосурәтләреннән берәр альбом төзәргә хыяллана идем. Хәзер СССР юк, минем дә андый сәяхәткә чыгарга шымытырым да юк. Аның каравы, рәхмәт, сез бар.

Хәзер мин «Комсомолка»ны сатып алам да тизрәк өйгә, диванга ашыгам. Һәй, рәхмәт инде сезгә! Нинди генә кызлар рәсемнәрен чыгармыйсыз! Ак тәнлесеме, кара-тутлысымы, озын аяклысымы, кыска бәдәнлесеме… Һәм барысы да ялангач. Ә теге трусик дигәннәре! Тасма гына булып калган ич.

Элегрәк алай түгел иде. Биш хатынны үзем аердым, унбере үзләре чыгып качты, шуңа күрә хатын-кыз трусигының нинди икәнен беләм дип уйлый идем. Ялгышканмын икән. Менә хөррият икән хәзер. Ул трусикларны салдырырга хыялланып торасы да юк икән ләбаса. Кызларның әллә кай җирләренә батып торганга, андагы бөтен «хыял» күз алдында бит. Рәхмәт, егетләр!

Мин сездән, редакция хезмәткәрләреннән көнләшеп тә куям. Сез бит ул рәсемнәрне беренче күрәсез. Беренче беренче инде ул. Аннары әнә үзегез дә язасыз бит, килгән сурәтләрнең барын да газета битләренә чыгарып булмый, дип. Димәк ки, чыкмаганнары да байтак. Әллә, мин әйтәм, мине эшкә аласызмы, ә? Шуларны сортларга аерып торырга… Хезмәт хакына акчагыз булмаса, мин бушлай эшләргә дә риза. Чыкмый калган сурәтләрне ишәйтеп сатарга рөхсәт итсәгез. Кызларның адреслары белән.

Хәер, сез миңа болай да бурычлы әле. Ник дисезме? Мин ул фотосурәтләрне кисеп алып, җыеп барам. Без берничә дустым белән телевизордан сыра рекламасын караганда, шул сурәтләр белән сокланып утырабыз да аннары ир-ат халкына күрсәтергә урамга чыгып китәбез. Караган-күргән кеше газетага язылырга йөгерә. Сезгә файда!

Минем сезгә бер-ике киңәшем дә бар әле, хөрмәтле редакция. Карагыз әле, нишләп сез теге күкрәкчә дигәннәрен салып төшкән кызлар рәсемнәрен әз чыгарасыз, ә? Бигрәк тә эре планда. Безнең Россия кызларының күкрәкләре пытыр-пытыр килеп торган силикон туп түгел ләбаса! Натуральный ими бит ул. Аларны бит карап туеп булмый… Карыйсың-карыйсың да тотып карыйсың килә башлый. Әллә бу татарлык микән? Татар бит тотып карамый ышанмый.

Икенче киңәшем. Сезгә нишләптер ул рәсемнәрне кызларның йә әниләре, йә әбиләре, йә дус кызлары җибәрә. Үзләре бик тыйнак булгангадыр инде. Шарт итеп куегыз әле, үзләре, йә әтиләре җибәрсен иде. Әтиләре җибәрсә, әйбәтрәк тә әле. Рәсем астына бер генә сүз язып. Ихлас күңелдән, дип әйтүем.

Тагын бер киңәшем бар икән әле. Сез бит бу игелекле эшегезне тагын да киңәйтә аласыз. Әйтик, нишләп мунчаның хатын-кызлар классыннан фоторепортажлар эшләмәскә! Мин моны үзем дә булдыра алыр идем. Минемчә, менә шунда инде материал байлыгы. Ышанмасагыз, Василий дәдәйдән сезгә хат салдырам. Ул мунчада слесарь булып эшли. Мунча җене кагылган аңа. Унсигез яшендә шунда кергән булган, инде менә сиксәнен тутырып килә, әле һаман пенсиягә китәргә исәбе юк. Көне-төне шунда. Нинди тазалык, диген, ә? Шварценегер! Мунча Шварценегеры!

Хатын-кызлар классы янәшәсендә генә су коену костюмнары тегү ательесы ачып җибәрергә була. Эше читен түгел, тасма гына кисәсе бит.

Хөрмәтле редакция! Күптән түгел мин бер ачыш ясадым әле. Үзем эшли торган завод ишегенә сезнең газетаны ябыштырып тора идем. Күкрәкчәсез генә рәсемгә төшкән кызлы санын. Машинасыннан директор килеп төште. Нишлисең, ди. Мин әйтәм, менә заводыбызның ир-ат халкын кайгыртып йөрим. Ә ул — ничек-ничек? Алар бит моны күргәч, эш турында уйламаячаклар, ди. Башларында гел бер уй бөтереләчәк, ди.

Менә шунда мин кинәт ачыш ясадым да инде. Менә, мин әйтәм, иптәш директор, үзегез дә беләсез икән, дим. Алар бит хәзер мөмкин хәтле тизрәк өйләренә кайтырга ашыгачаклар. Өйләнгәннәре. Эшләрен тизрәк төгәлләп. Өйләнмәгәннәре — өйләнергә. Шулай булып чыкты да. Ир-ат халкы көнлек эшләрен төшкә хәтле үк бетереп куя башлады. Хезмәт җитештерүчәнлеге бермә-бер артты. Эш сәгате бетәрбетмәс, ир-ат акны-караны күрмичә өенә йөгерә башлады. Мин сез чыгарган сурәтләрне алыштыра торам. Директор да бик шат. Миңа премия бирергә приказ чыгарды. Өч ел буена җыелган бурычны түләп бетергәч.

Шәһәребездә туйлар гөрли. Җомга җиткәнне дә көтеп тормый башладылар. Әле менә бала тудыру йорты төзергә җыеналар, диләр. Ике урында. Кыскасы, тормыш рәтләнә. Сезнең ярдәм белән.

Онытa язганмын, тагын бер үтенечем бар икән әле, хөрмәтле редакция. Берәр төрле челтәрле ирләр плавкиена да конкурс уздырыгыз әле. Тормышыбыз тагын да яхшырыбрак китмәсме, дим.

Ярый, сәламәт булыгыз, сез халыкка бик кирәк, Некрасов әйтмешли, сез бит народные заступники.

# Бигайбә

(*Юмореска*)

Туктагыз әле! Нишләп чаң кагасыз, ә? Нинди ыгы-зыгы бу? Нишләп демократия бетсен ди. Теләсә кем теләсә ни эшли алгандамы? Регион җитәкчеләрен дә халык сайламаячак, Путин билгеләп куячак икән, дисезме? Кемне тели, шуны куя, ничек инде бу демократия булмасын? Хәзер демократиянең чәчәк аткан чагы лабаса!..

Соң, сез урамга гына чыгып карагыз. Машиналар, җәяүлеләр каян тели, шуннан йөриме? Йөри. Урамнар машиналар белән тулымы? Тулы. Машинаңны кая куясың килә, шунда куясыңмы? Куясың. Шәхси «стоянка». Әнә хәзер милиция дә «стоянкалар» ясау эшенә керешкән диләр. Дөрес, ул «стоянкаларның» кайберләреннән атна саен бер машина югала икән. Соң, балигъ булмаган сыек буынлы малайлар, йә карт-коры үгездәй машина каракларына ничек каршы тора алсын инде. Хәер, ул малайларны эш белән мәшгуль диярге була инде анысы. Трай тибеп йөрмиләр, рәхәтләнеп сыра чөмереп тик утыралар. Аннары кайчан һәм кайда тели, шунда пес итә. Демократия!

Телевидение журналистларын күрегез әнә! Җаннары ни тели, шуны сөйлиләр. Билгеле, көлкеле тапшыруларны алар бик хуп күрә. Әнә ич «Кривое зеркало», «Шутка за шуткой», «Аншлаг», тагын әллә нинди нәрсәләр уйлап табалар. Теләсәң, беренче каналны, аны теләмәсәң, икенчесен, өченчесен, дүртенчесен ачасың. Кайда да шул ук М.Жванецкий, М.Задорнов, Е.Петросян, М.Галкин, К.Новикова, Л.Измайлов димәгез. Соң, демократия шул лабаса! Теләсәң кайсын тыңлап, шаркылдап утырасың. Тозсыз юмор? Алайса, әнә А.Хәмзин концертларына бар. Йә Кристина Орбакайтеның җырлаганын, биегәнен карап утыр. Кайсы программада? Кайсысын карыйсың — шунда.

Хәзер совет заманы түгел, кысучы юк, ирек... Шуңа күрә көн саен юбилей. Телевидениедә дә, концерт залларында да хәзер атлаган саен юбилей концертлары. Яшь кенә җырчы альбомының бер айлык юбилеемы, беренче концертының өч айлык юбилеемы! Де-мо-кратия! Йолдызлар хәзер микрофонны кулына тотып та, авызына кабып та, башына киеп тә, күкрәгенә тагып та гыжлый, гафу-гафу, чыжлый. Шушы бит инде ул үзгәртеп кору биргән «полный ирек».

Артист халкы хәзер демократияне теләсә ничек җигә. Тели икән — сөйли, тели икән — аты-юлы белән тамашачыны ерак-еракка озатырга да күп алмый. Филя Киркоров — молодчина! Бер олуг шоуменыбыз да әнә хәзер, бүтән җырламыйм, сөйләмгә генә күчәм, алай шәбрәк, ди икән. Күчәр дә шул, ник күчмәсен. Халык телен яраткач. Әнә бит бер концертта хатын-кыз затыннан булган бер коллегасы-

на: «Син розетка, мин штепсель», — дигәч, залдагы халык дәррәү күтәрелде, эче катканчы көлде. Менә ичмасам тапкырлык!

Юк, егетләр, сез демократия бетә дип бушка хафаланмагыз. Без демократиянең гөрләп чәчәк аткан чорында яшибез. Тәк что, бигайбә, иң элек аны күрә, ишетә белергә өйрәнегез!

# Авылдашларым

Авылдашларым... Мин әле бала, яшүсмер чакта ук алар минем хәтеремә якты йолдыз сыман уелып калган. Хәзер аларның бик күбесе Ходай каршында хисап бирә булыр. Кайберләре әле дә исән. Инде бик бетеренгәннәр. Мин сирәк кенә кайткангамы, авылым урамына килеп керүгә, иң элек каршыга очраган кеше үлем-китем турында хәбәр итә. Нишләп очрашу шатлыгын шулай эретеп юкка чыгаралар икән дип уйлаган чакларым булды. Аннары төшендем. Бу дөньяга кеше мәңгегә килмәгән бит. Мәңгелек анда, карт каеннар, юкәләр, йөз еллык имәннәр астында. Димәк, туган-үскән җиреңә аяк баскач, син иң элек мәңгелек турында хәтерлә, шуны онытма. Анда синең ата-бабаң, анда синең туганнарың, авылдашларың. Синең кебек үк дөнья куган, яраткан-сөйгән, арган-талган, гөнаһ кылган, соңгы сулышын алганда Ходайдан ярлыкауны сораган авылдашларың. Уңганы, ялкавы, уен-көлке белән тормыш авырлыкларын җиңәргә өйрәнгәннәре, шып итсә дә шылучылары, тыныч холыклылары, кайнар канлылары, җитезләре, авыр сөякләре — барысы да анда...

Авыл кешесе көне-төне хезмәттә. Кәеф-сафа кору аңа бик сирәк эләгә. Ә шулай да ул «миен җилләтеп» алыр өчен җай эзли. Һәм таба да...

# «Бәхет чокыры»

Безнең авылның әллә кайчаннардан калган таш кибете бар. Аннан ерак түгел инде исемен картлар да хәтерләми торган бер авылдашымның йорт нигезе чокырланып ята. Нигез күптән ишелгән, аны инде әрсез чирәм баскан. Авылымның бу чокыры әллә кайчан ирләрнең үзенә күрә бер җыен урынына әйләнгән. Алар монда буш чакларында, буш булмаган чакларында да, аякларын аскарак сузып, тыныч кына, тәмләп әңгәмә коралар, бәхәсләшәләр. Монда «кеше арасына керү» бөтен кешегә тәтеми. Бәхетлеләргә генә. Ә бәхетлеләр — кибеттә теге «йөзе кара» булганда, шуның белән әз-әзләп кеше сыйлап, үзе дә сыйланып утыручылар. Стаканны чиратлап йөртеп, ашыкмый гына йоткалап, мендәр конфет суырып, дөньяда яшәүнең рәхәтен тоя белүчеләр. Менә ни өчен бу чокыр «бәхет чокыры» дип атала. Хатын-кыз, берәр йомышы төшеп иренең кирәге чыкса, улына-кызына:

— Бар, җәһәт кенә «бәхет чокыры»на йөгер. Әтиеңне алып кайт! — дип куалый.

Иренә ачуы чыгып, бер-бер хатын-кыз «бәхет чокыры» янына килсә, ирен оялта, кычкырына башласа, аңа монда илтифат итүче юк. Бойкот. Ире дә дәшми. Башка чак, башка урын булса, ул:

— Өйгә генә кайтыйм. Сүтеп җыям әле мин сине! — дияр иде. Хатыны кайнарлыгын суытуның, бәлкем, бүтән юлын да табар иде.

Кыскасы, монда хатын-кыз әллә бар, әллә юк. Шуңа күрә алар үзләре дә бу тирәгә күптән аяк басмый. Ире кайткач теләсен телсә дә. Ә монда аларга «табу», монда «бәхет чокыры», монда кеше үзен бәхетле хис итә. Чөнки монда, көн саен булмаса да, теге «йөзе кара» нәрсә акмаса да, тама. Таммаса да, иркенләп дөнья хәлләрен сөйләшеп утыру үзе ни тора.

Авылның кайбер ирләре «бәхет чокыры»нда аеруча ихтирамга лаек. Алар кулларына теге «йөзе кара» кергәндә, аны өйләреннән монда алып килеп кабудан тәм табучылар. Менә алар почетта! «Бәхет чокыры»ң булганда, рестораннарың, кафеларың, ашханәләрең бер читтә торсын. Папирос, «кәҗә тәпие» төпчеген чытырдатып суыргач, җилкә аша гына читкә кайда тондыра аласың? Яисә бераз башына киткәне тавышлана башласа: «Ягез әле, алай итенмәгез әле», — диюгә, кайда гына моменты белән тынычлык урнаша? Монда, «Бәхет чокыры»нда. Монда аның үз законнары хакимлек итә. Берәрсе артыграк төшереп тәмсез телләнә калса, «бәхет чокыры» бер-ике көнгә «ябыла». Аннары инде ул бәндә «кеше арасына» керә алмый азаплана. Аңа да бойкот.

«Бәхет чокыры»нда еллар буена беркем игълан итмәгән конкурс бара. Монда барысына да күптән таныш булган хәлләргә бермә-бер яңалык өстәп, «авторлаштырып» сөйләүчеләр аерым почетта. Андыйлардан дөнья хәлләрен кабат сөйләвен үтенәләр. Чөнки тегеләр «кушып» сөйләргә бик «мачтыр». «Авторлаштыру» бик чамасыз артыкка киткәндә генә, тыңлаучылар:

— Вафа абзый борчагы артыграк кызмадымы? — дип кыстырып өлгерәләр. Без соңрак «Вафа абзый борчагы» турында аерым сөйләрбез әле. Әлегә шуның белән канәгатьләнеп торыйк.

Инде моннан соң да борчак чәчү чиксезгә киткәндә, берәрсе:

— Бу конкурскамы? — дип сорый. Шул чакта кибет янында тузанда коенучы чыпчыклар шаркылдап көлүдән куркып, пырылдап дәррәү очып китсә, сүз остасы җиңүче булып кала. Табигый, гадел жюри! Бер-ике җор теллесе җиңүчеләргә «Вафич» дигән мактаулы исем бирергә тәкъдим дә керткән, имеш.

## Вафа абзый «борчак сибә»

Вафа абзыйның «борчак сибәргә» осталыгы турында әйтеп киткән идем инде. Бу киң җилкәле, озын буйлы, аксыл чырайлы абзый — дөньяны күп күргән кеше. Сүзгә кыстатмый, берәр сорау бирүче булса, бик тәфсилләп, тәмләп сөйли белә торган иде. Әллә нинди чигенешләр ясап, матур итеп сөйли башласа, авызына гына каратып тота. Инде зур дикъкать белән тыңлап торганны күргәч, теленә «борчак» эләккәнен үзе дә сизми кала.

Минем әти белән алар кышкы озын кичләрдә, әллә кайчангыларны искә төшереп, озак-озак сөйләшеп утыралар.

Бервакыт Вафа абзый үзенең кайчандыр Урта Азияләрдә мулла булып никах укып йөргәнен сөйләп утыра. Анда аны — галим кешене өрмәгән урынга да утыртмаганнар, имеш. Ул шулхәтле «почетта» булган, җирле ир-ат көнләшүдән үлә язган. Әти шунда Вафа абыйдан кинәт кенә сорап куйды:

— Кара әле, Вафа абый, син бит мәдрәсәләрдә укымагансың. Догаларны да ярты-йорты гына беләсең шикелле. Ничек соң ул алай андагы халык сине «тәкъсир», «хәзрәт» дип кенә йөртте?

— Соң бит, Хәсән, мин ярты-йорты гына белсәм, алар анда үзләре чирек-чорты гына белә ләбаса.

Икесе тиң сәке такталарын шыгырдатып, кычкырып көлүдән, түшәмгә эленгән җиделе лампа калтырана башлый.

Вафа абый «борчакны» чамасыз кыздыра башлагач, әтинең йөзенә елмаю куна. Юк, ул аны бүлдерми, җай чыкканын көтә. Әти белә, Вафа абыйның бер гадәте бар. Ул сөйли-сөйли дә тыңлаучыга мөрәҗәгать итә:

— Дөресме, Хәсән?

Әти көттерми, ярып сала:

— Яртысы дөрес.

Икесе дә күзләреннән яшь килгәнче көләләр дә, сүз янә дәвам итә.

## Авылдашлар хоббие

Олы яшьтәге авылдашлар, «бәхет чокыры» янында тезелеп, кәефләнеп утырганда, әле дә булса күршебез Габдулла абыйны искә алалар. Аның гадәтләрен, җор сүзләрен, алтын кулларын искә төшереп көрсенәләр, сагыналар.

Габдулла абый, күкрәгенә орден-медальләр тагып сугыштан кайткач, тимерче булып эшкә урнашты. Аның кулыннан нәрсә генә килми иде. Күршебезнең хоббие да — яраткан шөгыле дә бар, ул чыра пычагы ясарга маһир иде. Аның кулында теләсә нинди тимер кисәге чыныккан, ялтырап торган үткен, матур агач саплы, утын пүләнен шатырдатып яра ала торган пычакка әверелә иде. Ул ясаган чыра пычаклары, авылга газ кергәнче, дистәләрчә еллар буена хуҗабикәләргә хезмәт итте. Алар аны әле дә булса рәхмәт хисе белән искә алалар. Авыр туфрагы җиңел булсын мәрхүмнең.

Габдулла абыйның тагын бер хоббие бар иде. Ул үзен мотоциклга утыртып йөрүне ярата иде. Тимерчелектә эшен бетереп өенә кайтырга чыкса, аяклары аны гел генә «бәхет чокыры»на тарта иде. Чокыр өенә караганда шактый ук ерак булса да, ул шунда юнәлә. Рәте булганда, үзе алып, булмаганда, башкаларга кушылып, хозурлана. «Байлар чырае» кергәч, «матайлы» берәр яшьтән үзен өенә илтеп куярга сорый. Шөкер, ул исән чакта ук авылда «матайлы» яшьләр шактый булганга, кош-кортны пыр туздырып, урам буйлап шатор-шотыр итеп, аны өенә илтеп куялар иде. Ә ул үзе, рульдәге егетне биленнән кочаклап:

Алмаларын алыйм дип,
Басып тибрәнәм талларга,
Яннарыңа барыйм дип, —

дип, үзе белгән бер җырын кат-кат кабатлап, җырлап кайтырга ярата иде.

Кайтып җиткәч, капкадан керми, хатыны Гаян апа чыгып алып кергәнне көтә. Эше тыгыз булып тегесе чыкмаса, Габдулла абый кире «бәхет чокыры» янына тәпили иде. Һәй, туган авылымның эчкерсез, гади, киң күңелле, бердәм кешеләре! Кайда икәнсез хәзер сез, кадерле авылдашларым! Изге җаннарыгыз кайларда гизә икән?

«Бәхет чокыры» тирәсендә «матайлы» яшьләр очрамаса, ул башын түбән иеп, җырламый-нитми акрын гына өенә юнәлә. Кайтып җитәргә бер-ике генә йорт калгач, шуны гына көткән шаян яшьләр, матайларына утырып, аның каршына очалар. Моны күргәч, абзый туктап кала, килеп җиткәннәрен көтә.

Тегеләр аның белән тигезләнгәч, туктата да өенә чаклы илтергә куша. Кайсы, аның сүзен тыңлап, шунда ук илтеп тә куя. Ә шаянраклары: «Габдулла абзый, мин бик ашыгам, фәлән-фәлән эшем бар. Шунда ашыгам. Син «бәхет чокыры» янына бар, кайтышлый утыртып китереп куярмын! Озак торма, вакытым тар», — дип китеп бара. Бу эш еш кабатланса да, Габдулла абзый, моны ишеткәч, рәхмәт әйтә-әйтә, яшен дә онытып, кире теге данлыклы чокыр янына йөгерә. Бераздан инде урамда тагын таныш җыр яңгырый:

Басып тибрәнәм талларга-а-а,
Яннарыңа барыйм ди-и-п.

Мондый кәефле чагында абзыебыз, хатыны күренмәсә, капкадан кермичә, кычкырыбрак кат-кат җырын кабатлый:

Алмаларын алыйм ди-и-ип...
Яннарыңа барыйм ди-и-ип,
Басып тибрәнәм таллар-га-а-а!

Эшләр моңа җиткәч, Гаян апа, кырык эшен кырык якка ташлап, капка төбенә ашыга:

— Кайттыңмыни, Габдуллаҗан, күрми-ишетми дә торам. Әйдә, кер, юынып ал да ашарга утыр, әйдә. Токмачым күпереп кенә чыккан ие. Әйдә, — дип, хәләл җефетен җитәкли.

Бу вакытта урамда берәр кеше булса, Габдулла абый зур җиңүгә ирешкән кыяфәттә, борылып карый-карый, хатынына үзен алып керергә булыша.

...Әнә шул алма яраткангамы, әллә талларга басып тибрәнергә яраткангамы, мин авылда яшәгән елларда ук күршем гаиләсендә тупырдап, алма кебек бер малай, өч кыз дөньяга килде.

# Газиз абзыйның шәһәрдә күргәннәре

«Бәхет чокыры» тирәсенә еш кына Газиз абзый да килеп чыга. Яше белән ул шактый олы, әмма аны яшьрәкләр үз итәләр, илтифат күрсәтеп, урын бирәләр. Сәбәбе дә бар — саран түгел.

— Рәтең юкмы, Газизҗан абзый? — дип сораганда, карчыгыннан әллә кайларга яшергән бөгәрләнеп беткән акчасын сыйпаштыргалап чыгарып бирә. Шуңа күрә кибеттән «утлы су» алып чыккан мәлләрдә иң беренче өлеш аңа тия.

«Печтек кенә» кабып алгач, ул кайтырга җыена башлый.

— Җарар, оланнар, сезнең эш беткән. Менә мине анда... Фәхрия җиңгәгез көтә торгандыр, зар-интизар булып.

Чокыр тирәсендәгеләр белә — аның бер дә китәсе килми. Үтә күренмәле булса да, нәни генә хәйлә бу. Ул игътибар көтә. Яшьләр моны белә, шунда ук күтәреп ала.

— Җә инде, Газизҗан абзый, бу юлы безгә бернинди дә гыйбрәтле хәл сөйләми китәргә җыенасыңмыни? — дип кыстарга керешәләр.

— Минем биштәр бушады лабаса, җегетләр. Аннары, сез бит инде минем баштан үткәннәрнең барын да беләсез, — ди абзый.

— Кем белә, кем юк. Менә монда Илгизәр шикелле малакусуслар да бар бит әле. Алар белми. Ә без сине кат-кат тыңларга да риза.

Газизҗан абзый утыра. Тамырлары кызарып торган күз карашын мәчет күле янындагы өянкеләргә юнәлтеп, тынып кала. Аннары:

— Дөнья сезнеке хәзер. Үзегез әйтмешли, малакусусларныкы. Бездән узды, узды инде, — дип кыстатып торган була.

— Йә инде, Газизҗан абзый, йә инде. Теге, Казанда сыйланып йөргәнеңне сөйлә инде.

Яшьләр ул хәлләрне белә, белә. Тик «Казан хәлләрен» кабат сөйләтәселәре килә, чөнки...

— Һәй, сезгә көләргә генә булсын, ерык авызлар. — Абзый сөйләргә риза, тик әле «мотор кабынмый» тора.

Менә шунда инде берәрсе:

— Мә әле, Газизҗан абзый, тагын берәрне йотып куй әле, сөйли башлаганчы, — дип, стакан суза.

Газизҗан абзый ашыкмый, шатырдап торган ике-өч көнлек сакалын саргайган куллары белән сыпырып, күзләрен дә учлары белән угалагач кына, стаканны алып, эчемлекне йотып куя. Аннары прәннекме, печеньемы сындырып каба.

— Сез менә сөйлә, сөйлә, дисез, — дип куя. — Ә менә тозлы балык ашагач, салкын су эчәргә ярамаганны беләсезме? Белмисез шул. Ә ул эш ярамый. Кавын ашагач та, минирал су, кайнамаган су эчмә икән.

— Һе!

— Һе, шул. Ахыры начар бетә аның. Мин моны үз башымнан узгач кына белдем.

— Теге, Казанда инде ул?

— Суң. Улым чакырып аптыраткач, бардым бер елны. Аның хәзер бик шәп йорты бар — кәтиж, диләр. Шәһәр читендә. Әй сыйлады, әй сыйлады. Хәзер үзегез беләсез, Казанның кибетләрендә генә түгел, урамнарында да юк нәрсә юк. Мәхшәр.

Минем кавын яратканны белә бу. Менә дигән, хуш исле зурдан-зур кавын алып кайткан. Ун гына кило булмас. Тирестә үскән кабак хәтле бардыр. Җыктым мин моны ашап. Бермәлне бик эчәсе килеп китте. Теге зур шешәдән минирал суны рәхәтләнеп эчтем дә малайга әйтәм:

— Мин чыгып керим әле. Трамвай белән апаңнарга барып килим, — дим.

— Үзем машина белән генә озатып куям, — ди малай. — Трамвайда нинди такыр-токыр йөрү ул.

Шәһәргә баргач, мин җә трамвайга, җә троллейбуска утырып, урам карап йөрергә яратам. Күчеп утыра-утыра, шәһәрне әйләнеп кайтам. Әй, андагы үзгәрешләр, андагы төзелеш хәзер.

Менә шулай чыгып киттем. Трамвайга утырдым, карап барам. Казанның яртысы хәзер өр-яңа икән, ә яртысын кырык бишенче елгы Берлин диярсең. Җимереп баралар, төзеп баралар. Барам шулай гаҗәпләнеп, тик берзаман сизәм, минем эчтә хәрәкәт башланды. Бүлк-бүлк итә дә тына, бүлк-бүлк итә дә бетә.

Шул чакта төшеп калып, борылып кайтасы гына бит кана! Бара торгач сизәм, минем эчтә Үктәбер эрволюсиясе башлана бит, җегетләр. Кыса бит бу, кыса. Әһә... Анда да төшеп калмыйм әле, барам. Берзаман шундый итеп китереп кысты, күздән утлар күренде. Китте тир, китте тир. Ике калак сөяге уртасыннан елга булып ага. Әһә... Нишләргә, малай. Инде аңладым, төшәргә кирәк. Берәр җаен табарга кирәк.

Ярар, ничек кирәк алай төштем төшүен. Тик атларга бирми генә бит, каһәре. Бераз кысмый торган була, шул арада мин кеше-кара күрмәслек урын эзлим.

— Шәһәр уртасында!

— Суң! Тик аны каян табасың. Кая карама кеше — олысы, кечесе. Урам тулы. Киче дә бик җылы, ял итәләр. Каян шулхәтле халык килә бу шәһәргә, дип ачуым да чыкты. Менә кайчан ул авылның кычыткан баскан почмакларын сагынасың икән... Әһә... Атлап куям да бик кысылгач туктам торам. Бермәлне каршыга очраган кешеләрнең миңа борылып карый башлаганын абайладым. Мин, кып-кызыл булып кызарып-пешеп, ташбака шикелле генә сөйрәләм икән ләбаса. Тизрәк барырга — Үктәбер кыса. Тиктомалдан гына туктап калганны күргәч, кешеләр гаҗәпләнәләр бугай. Ә минем үз хәлем хәл. Алар игътибар иткәндә, мин бер күккә, бер йортларга карап сызгыргалап торам. Эшем юк, ял итеп йөрим, янәсе.

Бермәлне бөтенләй аяк атлап булмаслык хәлгә килдем. Атладыңмы, менә ычкынам, менә ычкынам, дип тора, каһәре. Нишләргә соң инде! Эш харап бит. Гел генә басып торыр идең, урам уртасы димәс идең, тик күпме түзәргә була! Теге дөньялар күзгә күренә башлагач, башка җиңелрәк уй килеп китте:

— Монда мине кем белә...

Алай да әле түзәм. Кояшы да бит баемый аның. Эчтән генә:

— Әй, кояш, баюын да баерсың. Тик мин үлгәчтен баерсың, күрәсең, — дим.

Инде, кысылып басып тора-тора, аяклар тимергә әйләнде, атлый алмас хәлгә килде. Тәки теге уй җиңде:

— Мине монда кем белә...

Бик каты бер атакадан соң, түзәр хәл беткәч:

— Китсәң кит инде, — дидем дә ирек куйдым каһәргә... Әй, малайлар... Чалбар балакларының хәлен күрсәгез... Инде хәзер башка ничек кайтырга дигән уй төште. Бу хәлеңдә трамвайга ничек утырасың? Киттем җәяү. Барам-барам да... Кыскасы, хәлдән таеп, караңгы капкач кына, кешесез урамнар гына эзләп кайтып кердем.

Кердем, — дип. Звановкларына баскач, ишекне килен килеп ачты.

— Кит, — мин әйтәм, — үз бүлмәгезгә кереп, ишегегезне яп, дим.

— Нәрсә булды? — ди бу.

— Аннары, аннары. Зинһар, кит кенә.

— Анда да бетмәгән икән әле, каһәре. Ванныйларына кереп, чишеним дигәндә, тагын ычкынды. Ишекне бикләп, идәннәрен җуарга дисәм, идән чүпрәкләрен таба алмыйм! Майкам белән идәннәрен генә түгел, стеналарын да җуып чыгардым.

Улым үзенең күлмәк-ыштанын китереп биргәч тә, ванныйларыннан чыгарга оялып тордым. Алар һаман кызыксына: нәрсә булды, нәрсә булды?

Аңлатмый булмады инде. Китте көлеш, китте көлеш. Үзем дә елый-елый көлдем. Ходай моны явыз дошманыңа да күрсәтмәсен. Шуннан бирле ул кавын дигәннәренә әйләнеп тә карамыйм. Минирал суларын әйтмим дә инде. Чәй эчәргә кирәк, җегетләр, чәй эчәргә. Җә, ярап торыр бүгенгә. Фәхрия җиңгәгезнең сөмсере коелуы бар... Җыеп бетереп булмас. Khe...

# Эчтәлек

**I**

Минем сандугачларым (*Поэма*)........................................................................

**Шигырьләр**

Вөжданым — корыч калкан................................................................................
Әдипне сагыну ....................................................................................................
Алиш авазы ........................................................................................................
Асылым ...............................................................................................................
Гомер агышы.......................................................................................................
Чын хакыйкать....................................................................................................
Дога кирәк ...........................................................................................................
Истәлеккә әрнү калган.........................................................................................
Фани дөнья ..........................................................................................................
Яңа каза ..............................................................................................................
Менә сиңа мә! .....................................................................................................
Көз.........................................................................................................................
Күңеленә биклә ..................................................................................................
Сары май .............................................................................................................
Сабак....................................................................................................................
Бәхет канаты.......................................................................................................
Яшьтәшләр .........................................................................................................
Тормыш ...............................................................................................................
Замана ..................................................................................................................
Күнегәбез түгелме?............................................................................................
Нишләдек без? ...................................................................................................
Зәңгәр экран ничек түзә…..................................................................................
Яңа бай ................................................................................................................
Шик.......................................................................................................................
Пар ат....................................................................................................................
Ялгыш ..................................................................................................................
Яз килгәнне көтим микән…................................................................................
Милли идея..........................................................................................................
Кызык бу дөнья...................................................................................................
Бала чакның таяк аты .........................................................................................
Вакыт ...................................................................................................................
Ул мине аңлар микән?........................................................................................
Шатланып әсир булдым .....................................................................................

**II**

**Хикәяләр**

Сабыр төбе — сары сагыш.................................................................................
Соңарган бүләк ...................................................................................................
Нәгыйм-Нәгыймә имәне......................................................................................
Шундый улың булгач .........................................................................................
Гөнаһ шомлыгы ..................................................................................................
Яңабаштан...........................................................................................................
Туган көн .............................................................................................................
Ялган түгел..........................................................................................................
Ач кешенең ачуы яман .......................................................................................
Рәхмәт сезгә, егетләр .........................................................................................
Бигайбә ................................................................................................................
Авылдашларым (*Парчалар*) ...............................................................................

Литературно-художественное издание

*Хасанов Анас Хасанович*

# Мои соловьи

(*на татарском языке*)

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Рәссамы *Г.Җ.Хисмәтуллина*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *В.А.Савельева*
Корректоры *Г.Х.Сундукова*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия 2001 елның
6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 1.06.2005.
Форматы 70x108 $^{1}/_{32}$. Офсет кәгазе. Офсет басма. Шартлы басма табагы 6,30 + форз. 0,18.
Шартлы буяу-оттиск 7,18. Нәшер-хисап табагы 5,86 + форз. 0,29. Тиражы 2000. Заказ А-404.

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.
**http://www.tatarstan.ru/books/**
**E-mail: tki@books.kazan.ru**

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.